Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 49 (1414) 16 декабрь 2022 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

2

Баланың туган телен белеп үсүендә, аны яратуында иң беренче чиратта ана кешенең фикере һәм үз теленә мөнәсәбәте мөһим роль уйный.

12

Башкортстанның Нуриман районы үзәге Кызылъярның да, якын-тирәдәге башка күп кенә авылларның да тарихы Актаныш төбәге белән бәйле.



14

Рәссам буларак та танылган очучы-космонавт Владимир Джанибеков Юрий Гагаринны каршылаган татар гаиләсен сурәткә төшерә.

Һәр сынауда һәрбер сылудан да Милләт кызы булу сорала!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыевны «Әл-Фәхр» ордены белән бүләкләде.
- XXII «Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесендә Гран-прине Балтач районыннан Гөлназ Әхмәдиева яулады.
- Башкортстан Республикасы Милли симфоник оркестры Кышкы фестиваль кысаларында Татарстанда өч концерт куйды.
- Казанда Советлар Союзы Герое, очучы Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова бюст куелды.
- «Себер татар теле көнне Төмән шәһәренең татар мәдәнияте үзәгендә кала тарихына багышланган түгәрәк өстәл узды.
- Казанның «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә «Апуш» татар балалар театр студиясенең икенче спектакле – «Зоопарк-әлифба» тамашасы күрсәтелде.
- Республикакүләм «Татар кызы-2022» бәйгесендә Актаныш районы вәкиле, «Татар-информ» һәм «Интертат» журналисты Энҗе Габдуллина Гран-при иясе булды.
- Апас урта мәктәбе базасында мәгариф хезмәткәрләренең «Җамал Вәлиди укулары» II төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды.
- Бүген «Эрмитаж-Казан» үзәгендә «Алтын гасыр курчаклары» дип аталган Яңа ел күргәзмәсе ачыла.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Олег КИНҖӘГУЛОВ, Чаллы дәүләт драма театрының сәнгать җитәкчесе:

«Милли театр ул – классик әсәрләрнең гыйффәтле чишелеше. Проблеманың актуальлеге, чөнки татар сәхнәсендә һичшиксез проблема яңгырарга тиеш. Телнең моңы булырга тиеш. Әйтик, актер төп рольдә уйный, ә телендә моң юк. Аллага шөкер, өлкән артистларыбыз бар, алар яшьләргә киңәш итә. Кайсы сүзгә ничек басым ясарга кирәген әйтә. Милли театрны тоярга кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

18 декабрьгә чана юлы төшә; бу көнне торбадан чыккан төтен өскә күтәрелсә – салкыннар башлана, аска төшсә – кар ява ● 19 декабрьдә көн нинди булса, 22 майда да шундый була ● 22 декабрьдә агачларны бәс сарса, киләсе елга иген уңа ● Йолдызлар ачык күренсә – көн яхшыра, тонык күренсә – кар ява.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 07 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 10 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 03 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **3 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **23 декабрьдә 7 сәгать 00 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

16 декабрь – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Әхмәт Фазыл улы Ерикәйнең (Ерикиев) тууына 120 ел (1902–1967).

19 декабрь – шагыйрә, прозаик, драматург Гөлүсә Рәшит кызы Батталовага 40 яшь (1982).

20 декабрь – язучы, публицист, драматург, шагыйрь Фәтхулла Абдулла улы Абдуллинга 85 яшь (1937).

21 декабрь – прозаик, драматург, публицист Мәхмүт Максуд улы Хәсәновның тууына 95 ел (1927–1990).

22 декабрь – шагыйрь, тел галиме, филология фәннәре кандидаты Мостафа Ногман улы Ногмановның тууына 110 ел (1912–1976).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Декабрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 22 декабрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(16-23 декабрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җөмәдел әүвәл аеның 22 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Айгөл ГАНИЕВА

МИЛЛИ ЗАТЛЫЛЫК – АНАДАН

Галимнәрнең этносоциологик тикшеренүләренә караганда, татарлар – бүген гаилә ихтыяҗларын беренче планга куеп, матди җитешлектә яшәргә омтылучы халык. Ниндидер мисаллар китереп торасы юк, татар йортлары әллә кайдан балкып тора. Монда, әлбәттә, ирләр белән иңгә-иң куеп, кайвакыт аннан арттырып, алны-ялны белми дөнья куган заман хатын-кызының роле зур. Хөкүмәт эшендә дә эшләп, йортын-хуҗалыгын да ялт итеп алып бара ул. Табыны һәрвакыт мул, өе тәртиптә, үзе пөхтә. Гаиләдә бала тәрбияләүдә татар хатыны дилбегәне бүген үз кулында тота – аналык вазыйфасын беренчел бурычы саный. Баласының сәламәтлеген кайгырта, аның тәрбияле, акыллы, дәрәҗәле кеше булып үсүе өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Өч яки аннан артыграк бала табучылар да татарларда күбрәк. Дин саклый, күрәсең, хәмергә бирелүчеләр бездә аз, тормышны башкалардан калышмыйм, дип алып бару аңа тормышта этәргеч бирә. Дус, туган, күрше белән яхшы мөнәсәбәтләрен саклап, матур итеп яшәп яткан көне. Болар барысы да куанычлы күренешләр. Әмма социологик тикшерүләр татарларның, руслар белән чагыштырганда, бүгенге көндә рухи якны кайгыртмаулары күрсәтә. Бу бераз сәер тоела, чөнки карап торышка татар халкы аң-белемгә омтыла, милли үзенчәлеген – йолаларын, гореф-гадәтләрен сакларга тырышып яши кебек. Монда хикмәт татарның үз киләчәген уйлый белмәвендә, күрәсең. Безнең бүгенге унган-булган, заман белән бергә атлап баручы татар анасы берничә дистә елдан нәсел дәвамчыларының нинди милләт вәкиле булачагын күз алдына китерәме?

Шәһәрдә дә, авылда да бүгенге көндә иң зур проблемаларның берсе – балаларның русча сөйләшеп үсүе. Дөньяны актив танып белү һәм сөйләме формалашу чорында кулларында телефон, гаджетлар булу, туктаусыз русча уеннар, мультфильмнар карау һәм ата-аналарның моңа игътибарсызлыгы соңгы елларда яшь буынның фикерләү телләре рус телендә калыплаша баруына китерә. Кайберәүләр баласын татарча аңлый, сөйләшми генә, ди. Әни кешеләргә әйтәсе килә: баланың татарча аңлавы гына татар булып үсүен тәэмин итми. Үсеп, гаилә коргач, бу баланың баласы инде аңламаячак та бит, чөнки сөйләшүче булмаячак. Шулай итеп, без үз нәселебезне, дәвамчыларыбызны карап торып, милләте кем дип тә әйтеп булмаслык бәндәләргә әверелдерәбез.

Хәзер кайбер галимнәр милли үзбилгеләнүдә тел факторы мөһим, әмма бердәнбер түгел, дип саный. Алар фикеренчә, телдән башка тагын алты компонент бар: торган җир берлеге, туганлык берлеге, буынара бәйләнеш, уртак тарихи язмыш, уртак мәдәният һәм гореф-гадәтләр, уртак милли аң. Ягъни, әлеге факторлардан чыгып, кеше үзен нинди милләт вәкиле итеп тойса, үзен шулай атый ала. Әмма әлеге шомабашлар милләтнең үз теле булмаса, әлеге факторларның берниндиэһәмияте дә калмаячагын аңлый микән? Бу аерым шәхеснең үз милләтен билгеләгәндә генә эшли, анда да йөз кешегә бер булганда. Гомуммилләткә килгәндә, тел – бердәнбер күрсәткеч. Телдән башка әдәбият та, мәдәният тә, гореф-гадәтләр дә, милли аң да була алмый. Башка телдә яңгыраганда, алар башка мәгънә ала. Тел – гади сүзләр җыелмасы гына түгел, ул гасырлар дәвамында халыкның дөньяны кабул итүе белән бәйле формалашкан аң гәүдәләнеше. Шуңа күп очракта тел белән милләт арасында тигезлек куела. Тел яшәсә – милләт яши.

Күптән түгел бер танышым татар теле дәресләге катлаулы, дип улын рус төркеменә күчерүен әйтте. Сүз яңа дәреслекләр турында бара. Моны ничек аңларга? Бәлки, безгә дәреслекләрне түгел, үзебезнең башыбыздагы фикерләрне башка якка борырга вакыттыр? Бу үзеңне, телеңне, халкыңны яратмаудан түгелме? «Менә инглиз теле дәреслекләре укырга кызыклы, безнеке андый түгел», – ди. Әйе, инглиз дәреслекләрен безгә үрнәк итеп файдалану кирәктер анысы, әмма без алар дәрәҗәсендә эшләп җиткермәскә дә мөмкин бит, дим. Чөнки кайбер әйберләр финанс белән дә бәйле. Әти-әнине матур, йә бай булганы өчен түгел, ә үзебезнеке булганы өчен яратабыз. Дәреслеккә, татар теле дәресенә, укытучыга мөнәсәбәт – безнең туган телебезгә булган мөнәсәбәтне күрсәтә. Кавказ халыкларына әйтеп кара теленә-милләтенә бер кыек сүз – исән калдырганына рәхмәт әйтәчәксең. Бу – каннан килә, үзеңнеке дигәнне яратудан. Мисал өчен, хәзерге укучылар «бессоюзное сложносочинённое предложение» дигәнне нормаль кабул итә, «теркәгечсез тезмә кушма җөмлә» дисәң, күзләре акая – әллә нинди катлаулы нәрсә кебек кабул итәләр. Башка телне, фәннәрне өйрәнүгә, хәтта кытай телен укытуга каршы сүз юк, татар телен генә өйрәнәсе килми безнекеләрнең. Әлбәттә, монда әлеге күңелсезлекләрнең тарихи сәбәбе – гасырлар буе халыкта махсус милли кимсенү тәрбияләү турында язарга мөмкин булыр иде. Әмма татар анасының булган мөмкинлекләрдән файдалана белмәве, матди дөньяны кайгыртудан ары китә алмавы, дигән хафа да бар бит әле.

Татар телен укытуга мөнәсәбәтле авыл белән шәһәр арасындагы аермалык хәзер дә яшәп килә. Бу шәһәрләрдә күбрәк рус мохите булу, татар авылларында әлегә милли үзенчәлекләр, тел саклану белән бәйле. Шәһәр татары бүген үз теленә карата коточкыч дәрәҗәдә битараф. Ун проценты телне укыту яки укытмауга үз мөнәсәбәтен белдерсә, калган туксан процентына барыбер. Укытыла икән, ярар, димәк, шулай тиеш. Укытылмый икән – тагын да әйбәтрәк, дәрес хәзерлисе юк, бала башын катырмыйлар. Ә авылда башкачарак. Анда татар мәктәпләре азмы-күпме саклanып килә, ләкин ата-аналарның күбесе балаларының туган телдә белем алуларына сөенәсе урында, татарча укып, тормышта үз урыннарын тапмаслар, уңышка ирешә алмаслар, дип курка. Тик юкка борчылалар. Бердән, хәзер БДИ тапшырасы булгач, рус теле укытуга таләпләр югары куела. Икенчедән, баланы чолгап алган виртуаль дөнья рус телендә. Ул берничек бу телне белми кала алмый. Ә уңыш мәсьәләсендә, бу инде телгә түгел, ә баланың үз шәхси мөмкинлекләренә бәйле.

Ана – мәктәп – дәүләт – шушы өчлек бәйләнеше даими эшләгәндә генә милләтнең киләчәге булырга мөмкин. Монда иң мөһим рольне ана башкара. Тел ана сөте белән кермәсә, телгә хөрмәтне дә, мәхәббәтне дә ана тәрбияләмәсә, башка беркем тәрбияли алмый. Кешелек барлыкка килгәннән бирле ана үз телен, үз гореф-гадәтләрен баласына күчерә килгән. Бу һәр халыкта, һәр кавемдә шулай. Шуңа да ул ана теле дип атала, ата теле дә, башка тел дип тә түгел. Мәктәп – белем бирүче оешма. Дөрес җәмгыятьтә бала мәктәпкә туган телен белеп килергә, анда әдәби телдә дөрес язарга, сөйләшергә өйрәнергә тиеш, безнең шәһәр мәктәпләрендәгечә, чит тел өйрәнгән кебек, сүзләр өйрәнеп утырырга түгел. Дәүләт исә ана һәм бала хокукларын якларга, туган телдә белем алуга, үз милләте белән горурланып үсәрлек шартлар тудырырга бурычлы. Бүгенге көндә, күргәнебезчә, үзгәрешне нәкъ менә анадан башларга кирәклеге аңлашыла.

Һәр ана үз газизен өзелеп ярата. Әмма әлеге ярату хисе адәм баласында гына түгел, киек-җанварлар да баласы хакына җаннарын бирергә әзер. Аллаһ Тәгалә адәм баласына акыл биргән, тәмле ашатып, матур киендереп, яратып-сөеп үстерү генә түгел безнең бурыч. Тән сәламәтлеге белән бергә рух сәламәтлеге дә ата-ана өстендә.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Рухиятле чишелеш

Сүзне узган язмада куелган сораудан башлыйк: бүгенге тотрыксызлык шартларында илаһи яшәешкә ничек ирешергә? Россия өчен бүген бу сорау ничектер шомлы да яңгырый. Чөнки гайре табигый яшәү кагыйдәләре анда хәзер хәтта закон дәрәҗәсендә урнаштырыла. Ә илаһият кануннарына яшәештәге барлык табигый закончалыклар керә, игътибар итик, Күк йогынтылы илаһи гыйлемлек серләрен дә колачлый. Беренчеләрен (әйтик, Ньютонның өченче законын) инкяр итә торган закон кабул итү теләге беркемнең (хәтта Клишас ишеләрнең дә) башына килми, ә менә әдәп-әхлак нормаларына яки милли вә иҗтимагый яшәеш кануннарына каршы килә торганнары (әйтик, төп халыкларның туган телләрен һәм хокукларын чикләгән, яки аларның милли мәгарифен җимерә торган һ.б.) шактый ук еш кабул ителә. Дини яки төбәк мәнфәгатьләре белән санлашмый торган (мисалга, сәяси партияләр турында һ.б.) законнар да бар. Чөнки дөнья тотучы кавемгә бу, милли вә дини күптөрлелекне мәҗбүри бетереп, үз максатлы глобальләштерүне алга этәрү өчен кирәк. Димәк, төп сорауга җавапны рухият вә сәясәт өлкәсеннән эзләргә туры киләчәк.

Бу җәһәттән алгы планга иң элек Изге Китапларда бирелгән серле мәгънәләрне дөрес аңлау проблемасы чыга. Узган язмаларда, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм татар алгарышы теоретигы Рашат Сафин хезмәтләренә таянып, Аллаһка кайту юлының тугрысын (Аның хозурына кадәргесен) бары тик хак динебез ислам гына ачыклавы, ул юлның соңгы маягын күрсәтеп, кешегә иң югары омтылыш ирәге бирүе турында да бәян иткән идек. Бу юлы исә, мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, аның ислам метафизикасы (мәңгелек һәм тәҗрибә ителә алмый торган илаһи башлангычларның даимилеген таный торган фәлсәфи тәгълимат) теориясенә дә мөрәҗәгать итәрбез. Чөнки, Р.Сафин язуынча, ислам метафизикасы Алланың барлыгын вә берлеген, йөрәк белән генә түгел, акыл аша да тану һәм, Коръәндә бирелгән серле мәгънәләр белән бергә, исламның тәүхиди-иҗтиһади асылын да ачыклау мөмкинлеген бирә. Шуңа ул мөэминнәргә ислам метафизикасының асылын аңларга киңәш итә дә. Бүген исә аның фикер-киңәшләре аеруча актуаль яңгырый. Ә бу инде аның хезмәтләрен (бигрәк тә аның өч фундаменталь хезмәте – «Татар юлы», «Татар миссиясе» һәм «Татар инануы» китапларыннан торган фәлсәфи-сәяси трилогиясен) кабаттан да нәшер итү зарурлыгы зур булуы турында сөйли. Чыннан да, ул хезмәтләр бүген дин әһелләренең өстәл китабы да булырга лаек. Әмма эреле-ваклы түрәләрнең милли аң дәрәҗәсе әлегә аларны кабаттан да бастыру мөмкинлеген бирми.

Хәлбуки, мәсьәләнең икенче ягы да бар. Иблис токымы кешелекне хәзерге глобаль кризис һәм рухи деградациягә дөньякүләм диннәрне сәяси максатларда кулланып та кертте. Шул ук вакытта, бүгенге тотрыксызлык шартларында илаһи борылыш вә рухи яңарышка гел сәясәтсез дә ирешеп булмый. Аның илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүне максат иткән төре «метасәясәт» дип атала. Ә татарга, илаһи миссияле милләт буларак, бүгенге кыен чорда Урталык җирләрендә тотрыклылык һәм илаһи борылыш факторы булу бурычы да йөкләнә. Шуңа күрә, ислам метафизикасына таянган рухи яңарыш белән бергә, аңа хәзер метасәясәт яктан үзоешырга да (бу хакта тәфсилле сүз газетабызда инде булды, «МҖ» №31, 12.08.2022) туры киләчәк. Илаһи миссиянең гамәли ягына килгәндә, ул бик күп (меңләгән) метасәяси проектларны гамәлгә ашыруны күздә тота. Шөкер, бүген күп кенә андый проектлар милли энтузиастлар һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан ихтыяри рәвештә дә гамәлгә ашырыла. Андыйлар рәтенә, әйтик, балалар һәм яшьләр арасында татар батыры образын торгызу һәм брендын булдыруны ният иткән «Туган батыр» проектын, «Фәнсоярлар клубы» эшчәнлеген, «Ачык университет» проектын һ.б. кертергә була. БТК Башкарма комитеты химаясендә гамәлгә куелган «Ык елгасы авыллары җыены» проекты да игътибарны җәлеп итә. Колачлы һәм 13 төрле юнәлеше (Ык буе татар авылларының тарихын язу һәм шәҗәрәсен булдыру; «Сәламәт милләт» проектын гамәлгә ашыру; Мөслимдә Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивален уздыру; «Татар тур» проекты аша татар атларын кулланышка кертү һ.б.) үз эченә алган бу проект халкыбызның милли яшәеш моделен татар милли традицияләре нигезендә һәм заман рухына туры китереп торгызуны максат итә. Әлеге мегапроект татарның тән, җан һәм рух берлеген чагылдырган чара – Ык елгасы авыллары Сабан туе һәм Җыены белән төгәлләнеп гамәлгә кертелер, дип көтелә. Әлбәттә, күптөрле һәм күпсанлы проектлар әле алга таба да булыр һәм алар милләт киләчәгенең мозаикасын тәшкил итәр.

Фоат УРАЗАЙ.

Парламентарийлардан эшлекле тәкъдимнәр

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Йошкар-Ола шәһәрендә узган Идел буе федераль округы субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары ассоциациясе утырышында катнашты. Парламентарийлар Идел буе төбәкләрендә «Мәдәният» илкүләм проектын, челтәр мәгариф проектларын (сүз берничә белем бирү оешмасы ресурсларыннан файдаланып белем бирүне оештыру мөмкинлеге турында бара) гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алышты, быелгы эшләргә йомгак ясадылар, шулай ук 2023 елга эш планнарын расладылар.

Утырыш кысаларында Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле Игорь Комаров Фәрит Мөхәммәтшинга Александр Невский орденын тапшырды.

Ассоциациянең алтмыш алтынчы утырышында мәдәният мәсьәләләренә аерым игътибар бирелү очраклы түгел, чөнки бу ел илебездә Россия халыкларының мәдәни мирас елы дип игълан ителде. Идел буе парламентарийлары утырыш алдыннан Яков Эшпай исемендәге Мари дәүләт филармониясендә, республика курчак театрында һәм И.С.Палантай исемендәге Мәдәният һәм сәнгать көллиятенең милли гимназиясендә булдылар. Марий Эл республикасының күптәнге тарихы булган мәдәни һәм мәгариф учреждениеләре соңгы елларда шактый яңарган һәм үз эшчәнлекләре өлкәсен киңәйткән.

«Мәдәни мохит» төбәк проектлары субъектларда яңа мәдәни объектлар төзергә һәм инде кертелгән объектларны реконструкцияләргә мөмкинлек бирә. Әйтик, Татарстанда быел гына да биш авыл мәдәният йорты төзелгән, мәдәни үсеш үзәкләре һәм модуль китапханәләр ачылган, район һәм шәһәр сәнгать мәктәпләре, муниципаль музейлар һәм театрлар ремонтланган. Якын арада Түбән Камада төзекләндерелгән яшь тамашачы театры ачылачак. Гомумән алганда, быел Татарстанда «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга 1,2 млрд. сумга якын акча каралган.

Идел буе закон чыгаручылары берничә инициатива белән чыгыш ясады, аерым алганда, Россия Хөкүмәтенә «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру срокларын 2030 елга кадәр озайтырга, авыл җирлегенә эшкә килгән мәдәният хезмәткәрләренә ярдәм буенча федераль программа кабул итүне тизләтергә тәкъдим иттеләр. Андый программа, парламентарийлар фикеренчә, мәдәният тармагында кадрлар кытлыгын хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк һәм бу эшкә яшьләрне җәлеп итәчәк, «Пушкин картасы» программасында катнашучылар даирәсен киңәйтергә, аңа циркларны да кертергә кирәк дигән фикергә килделәр. Моннан тыш, парламентарийлар «Мәдәни мохит» федераль проектына балалар сәнгать мәктәпләренең янгын куркынычсызлыгы таләпләренә һәм санитария нормаларына туры килә торган заманча яңа биналарын төзүне тәкъдим итте.

Ассоциация утырышында Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентының РФ Кодексын балигъ булмаганнарга татуировкалар ясауга кагылышлы маддә белән тулыландыру турындагы инициативасы хупланды. Республиканың яшь парламентарийлары фикеренчә, балигъ булмаган балага тату ясау өчен ата-аналарыннан яки аның законлы вәкилләреннән рөхсәт алырга кирәк.

«Мәдәни җомга»га 2023 елның I яртыеллыгына язылыр өчен санаулы көннәр калды. Газетага почтада гына түгел, интернет аша podpiska.pochta.ru сайтында да язылып була. Соңга калмагыз!

Ярты елга язылу хакы – 725 сум 94 тиен.

Саваплы эш

Лаеш районы Сиңгел авылында «Чишмә» проекты кысаларында чираттагы бушлай чиста су алу пункты ачылды. Лаеш районындагы алтынчы пунктның тантаналы ачышында район башлыгы Илдус Зарипов, имам-мөхтәсиб Наил хәзрәт Әбелханов, хәйрия проектының координаторы – Гайнетдинов, төзүчеләр һәм меценатлар катнашты.

Реабилитация һәм адаптация үзәге генераль директоры, Иҗтимагый палата әгъзасы Азат Галимҗан улы әйтүенчә, бу проектның максаты – халыкны бушлай сыйфатлы чиста су белән тәэмин итү. Проект «Чишмә» дип аталса да, бу гади кизләү суы түгел. Беренче чиратта артезиан суын чыгару өчен, тирән скважина бораулана. Аннан соң кыйбатлы, суны тирәнтен чистарта торган фильтрлар куела. Көненә бу ясалма чишмә 8 тонна чиста эчәргә яраклы су биреп тора. Бу суны динена һәм милләтенә бәйсез рәвештә теләгән һәр кеше, юлчылар куллана ала.

Наил хәзрәт Әбелханов мәҗлесне Коръән укып башлап җибәрде. Хөрмәтле кунаклар чыгыш ясагач, проектны тормышка ашыруга көч куйган кешеләргә рәхмәт хатлары тапшырылды.

Эльмира СИРАҖИ.



«Хатлар йорты»ннан яңа тупланма

«Хатлар йорты» проекты «Искусство жить» мәдәни-мәгърифәти киңлектә яңа коллекцияләрен тәкъдим итте. Проект авторы Энҗе Садыйкова үткән ике елдагы эшчәнлеккә нәтиҗә ясады, уңышлы коллекцияләрне тасвирлады.

Рәссамнар белән эшләнгән яңа коллекцияләрнең берсе «Туганлык җепләре» дип атала. Аның авторы – рәссам Лилия Гәрәева. Икенче коллекция – шаян открыткалар.

«Төп миссия, әлбәттә, туган телне табигый рәвештә куллану. Тел, мәдәният аша милләтне яраттыру да безнең максатка керә», – дип «Хатлар йорты» проекты белән таныштырды Э.Садыйкова. «Безнең газета-журналларыбыз күп, радио- -телевидение дә бар. Ләкин шул кечкенә генә открыткалар проекты эчтәлеге һәм татарлыкны тарату ягыннан зуррак та. Татар милли коды булган ул открыткалар дөнья буйлап тарала», – диде «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте директоры Шамил Садыйков.

1 нче биттә – «Татар кызы» республикакүләм бәйгесенең финал өлешеннән бер мизгел. Салават Камалетдинов фотосы. «Татар-информ».

Каһарманга истәлек тактасы

Казанда Советлар Союзы Герое Борис Кузнецовка истәлек тактасы ачылды. Тантанада катнашкан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. «Борис Кириллович – шәхси батырлыкның олы үрнәге, 19 яшендә Советлар Союзы Герое булган чын патриот. Аның тормыш юлы бүген махсус хәрби операциядә катнашучы татарстанлылар өчен чын үрнәк булып тора», – дип белдерде.

Рөстәм Миңнехановның сүзләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Россия Хезмәт Герое Минтимер Шәймиев тулыландырды. Ул геройның гаиләсе белән шәхсән таныш булуын билгеләп үтте.

«Борис Кузнецов чын герой иде һәм данлы тормыш юлын узды. Ул үз гомерен лаеклы уздырды, ә аның батырлыкларын без һәрвакыт истә тотачакбыз», – дип белдерде Минтимер Шәймиев.

Истәлек тактасы эскизын скульптор, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Фәнил Вәлиуллин эшләде. Тантанадан соң Татарстан Президенты Социалистик хезмәт Герое, «Татарстан Геройлары» оешмасының мактаулы рәисе Илдус Мостюков белән очрашты.

Җырлары калды күңелдә

Узган атна ахырында кайгылы хәбәр ирешге: шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, күпсанлы популяр җырлар авторы **Мансур ШИҺАПОВ** вафат.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Әхмәт улы Шиһапов 1940 елның 1 маенда Балык Бистәсе районы Яншык авылында туа. Олы Солтан авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң В. Качалов исемендәге Зур театр каршында оешкан театр студиясендә белем ала, соңрак Казан театр училищесын һәм Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый.

Мансур Шиһапов күп еллар дәвамында Курчак театры, К.Тинчурин исемендәге дәүләт театры, Г.Камал исемендәге театр директоры урынбасары, С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залының директоры булып эшләде. Аның шигырьләренә 50 дән артык җыр иҗат ителгән: «Әйләнеп кайтыгыз», «Аккош белән сөйләшү», «Туй күлмәге», «Яшьлегем эзләре», «Өлешемә тигән көмешем» һәм башкалар.

Хөрмәтле тел остазы иде

КФУның татар теле белеме кафедрасы тел галиме, Гомәр Саттаровны искә алу кичәсе уздырды.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни эшләр буенча директор урынбасары, филология фәннәре докторы Олег Хисамов тюрколог-ономатолог Гомәр Саттаров яшәгән йортка истәлек тактасын кую тәкъдиме белән чыкты. «Бу – аның шәкертләренең, ул эшләгән уку йортының бурычы. Гомәр Саттаров – минем остазым. Киңкырлы тел галиме, сүзлек төзүче лексикограф. Татар диалектологиясенең сөйләм культурасына тәэсире турында хезмәтләре бар. Ул ономастиканың киләчәккә юнәлешләрен билгеләде. Гомәр абый үзеннән соң да шәкертләр үстерде. Таләпчән, чын мәгънәсендә эти ролендә булган галим», – диде ул.

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов Гомәр Саттаровны энциклопедист-галим дип атады: «Чөнки ул татар тел белеме өлкәсенең бик күп тармакларында эшләгән. Татар тел белеме фәнен һәм университетлыбызны танытуга зур өлеш керткән галимебезгә 90 яшь тулган булыр иде. Ул татар ономастикасына нигез салучы. Гомәр абыйның татар лексикологиясе, диалектология, тел тарихы өлкәсендәге хезмәтләре Татарстанда гына түгел, чит илләрдә дә зур танылу алды».

«Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли?» китабы бүгенге көндә һәм киләчәктә дә һәр гаиләдә кулланылыр. Мин Бөгелмәдә яшәгәндә ул китап берничә кешедә генә бар иде һәм миндә булган китап та бик күп танышлар кулыннан үтте», – диде Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү процессын укыту-методик чаралары белән тәэмин итү секторы мөдире Ләйсән Гайфуллина.

«Кичәгә барырга кием сайлаганда кызыл күлмәккә күзем төште. Аны беренче тапкыр кигәч, Гомәр ага: «Тәлгат, синә кызыл әйбер килешә», – диде. Бу күлмәкне ун ел кигәнем юк иде. Аның һәр адымы, сүзе һаман да хәтердә», – диде галим Тәлгать Галиуллин.

Татарстанның атказанган архитекторы, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Айвар Саттаров этисе – тел галиме Гомәр Саттаровның архивын барлавын, архивыннан бик күп шигырьләр табылуы турында хәбәр итте.

«Әти вафат булганнан соң өйдә бик зур архив калды. Ул китаплар, кәгазьләр белән тулган. Папкаларны карый торгач, әтинең бик күп шигырьләре табылды. Әти миңа: «Галим булмасам, шагыйрь булыр идем», – дип әйтә иде. Әтинең шигырьләрен укыган саен татар теленең матурлыгына сокланам».

Г.Саттаровның татар җанлы кеше булганлыгы васыятендә чагыла. «Әти миңа кабер ташының арткы ягына түбәндәге сүзләрне язарга кушып калдырган иде: «Кадерле татар телем! Шау чәчәк атар гөлем. Бәхетем, шатлыгым син! Милли йөз, аклыгым син! Сиңа Гомәр Саттар гомерен багышлады һәм һич тә ялгышмады», – дип искә алды галимнең улы.

МИЛЛИ ЗАТЛЫЛЫК – АНАДАН

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Балаларга бәхет телибез. Чын бәхетнең матди җитешлектә, дан-дәрәҗәдә генә түгел, зур бер кавемнең бер вәкиле булып, кавемдәшләрең белән аңлашып, аралашып, үз халкың белән горурланып яшәүдә дә икәнен аңларга кирәк. Күз алдына китерегез: татарча сөйләшмәгән буын килсә, иң беренче әдәбият һәм газета-журналлар юкка чыгачак.

Аннан радио-телевидение, театр; алга таба җыр һәм тел белән бәйле башка өлкәләр. Шуннан инде «үзем татар, туган телем – урыс» диючеләр китә. Аңламаган әйберне яратып булмый. Тора-бара, телен яратмаган милләтен яратыр, дип әйтеп буламы? Монда хәзерге балалар гына түгел, оныклар, аннан соңгы буыннар турында да сүз бара. Шуны да әйтергә кирәк, рус телен, рус мәдәниятен кабул иткәнгә карап, ул урыс та булып китә алмый бит. Чөнки тамыры татарныкы, ислами карашлары да беркая китмәячәк аның. Шулай итеп, ни татар, ни рус булмаган, үзен нинди милләт вәкиле итеп атарга белмәгән бәхетсез токым барлыкка килә. Ул токым безгә рәнҗемәс дип, кем әйтә? Иң беренче чиратта туган телеңне белмәүнең кимчелекле, хурлыклы гамәл икәнен хәзерге ананың үзенә аңлау кирәк. Тормышта акыл утыртканнан соң, бигрәк тә Россиядән читкә чыгып, дөнья күрүчеләр арасында әниләренә туган телне өйрәтмәүләре өчен рәнҗүчеләр күп. Ә.Баяновның «Тау ягы повесте»ндә (1972) төп герой Тәбрик: «Ә ни өчен ихтирам итәргә, ни өчен табынырга тиеш әле мин аларга? Үзләренең иң кадерле байлыкларын, йөрәк хисләрен түгел, хәтта телләрен, моңнарын да мирас итеп бирә алмаган ата-аналар хакына гыйбадәт кылу мөмкинме? Нәрсә хакына?» – ди. Димәк, балаларыбызның туган телләрен камил белеп үсүе әллә кемнәргә түгел, үзебезгә – хәзерге аналарга – нәсел дәвамчыларының хәерхаклы булулары һәм аларның бәхетле киләчәге өчен кирәк.

Рус телен дә, башка телләрне дә белү зарур, тик үзеңнекенә беренче чиратта торырга тиеш. Ана кеше «безнеке» һәм «аларныкы» дигән чикне кечкенәдән аңлатып үстерсен иде. «Аларныкы»на дошманлык белән түгел, хөрмәт белән, әмма «үзеңнеке»н йөрәк түренә куеп. Кавказ халыклары бу яктан, чыннан да, үрнәк. Аларда әлеге чикләр нык билгеләнгән. Әлбәттә, төрле яклап безне чолгап алган рус дөньясы, җәмгыятьтә күп эшләрнең рус телендә генә алып барылуы бала тәрбияләүче ата-анадан зур сабырлык һәм көч таләп итә. Моңарчы татар теле табигыйлек белән буыннан-буынга күчеп килгән булса, хәзер аңлы рәвештә сакламыйча булмый. Совет заманындагы кебек, русча сөйләшү модасы бетте, хәзер үз телеңдә матур, дөрес сөйләшүчеләр мәртәбәдә. Башка халыклар да үз телен яратучыларны хөрмәт итә. Гомумән, милли горурлык хисе дөнья халыкларында һәрвакыт соклану тудырган. Моңа багышлап бик күп сәнгать әсәрләре иҗат ителә.

Бүген кем ничек тели, ничек дөрес дип таба – шулай яши. Әмма тормышта хыянәт итәргә ярамый торган кыйммәтләр бар. Шуларга сиңа гомер биргән анаң кебек үк газиз, гасырлар буе буыннан-буынга күчеп килгән халкыңның теле дә керә. Үз телеңне санга сукмый, башка кавем телен якынрак күрү – ата-бабага хыянәт!

Әлегә без начар яшәмибез: күпгасырлык мәдәнияте, гыйбрәтле тарихы, искиткеч матур, камил теле булган бөек халык статусында торабыз. Яшь буынны да бу олы байлыкның кадерен белерлек итеп үстерәсе иде. Шуларны аңлаучы, зыялы, затлы Аналар саклый телне. Милләт киләчәге алар кулында. Нинди авыр заманнарда да үз йөзен саклап килгән милләт безгә калгач кына какшарга тиеш түгел.

● КХР таможнясы мәгълүматлары буенча, быел октябрьдә генә дә Кытайдан Россиягә 560 миллион долларлык автомобиль кертелгән. Быел гыйнвардан октябрьгә кадәр барлыгы 3,61 миллиард долларлык машина кайткан (былтыр исә ел буена барлыгы 3,45 миллиард долларлык автомобиль сатып алынган). Кытай машиналарын кертү структурасында җиңел автомобильләр күпчелекне тәшкил итә (1,08 млрд $). Аннары йөк машиналары (1,06 млрд $), автобуслар (970 млн $), автокраннар һәм башка махсус машиналар (250 млн $) килә. Хәзер исә Иран да Россиядә үз автомобильләрен сатарга җыена. Әлеге ил машиналарын Әрмәнстан һәм Азәрбайҗан сатып ала икән инде, меңгә якыны Венесуэлага да җибәрелгән.

● Алабугада Aurus Komendant автомобиле сериялап җитештерелә башлаячак. Аның детальләренең 70 проценты Россиядә ясала. Затлы автомобильнең бәясе 33,7 миллион сум чамасы булачак.

● «Москвич» автозаводы эшли башлады һәм «Москвич-3» кроссоверын сериялап җитештерүгә керешге. Машина Мәскәүдә гыйнвар аенда, ә бөтен Россия буенча исә мартта сатыла башлар, дип фаразлана. Яңа автомобильнең бәясе 1,6 миллионнан 2 миллион сумга кадәр тәшкил итәчәк, дигән сүз йөри, әмма заводның матбугат хезмәтенең машина бәясен атаганы юк әле.

Караңгылык сәхнәдә яисә тормыштамы?..

Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә беренче тапкыр – Лев Толстой.

Ел тәмамланырга санаулы көннәр калганда, Әлмәт татар дәүләт драма театры тамашачыларны гадәти булмаган премьера белән сөендерде. Рус классигы Лев Толстойның «Дөм» («Власть тьмы») әсәре үз асылын югалтмыйча, заманча яңгырады. Спектакль «Кече Ватан мәдәнияте» федераль программасы ярдәмендә куелды. Текстның сәхнә вариантын Е.Августеняк һәм Л.Бондарь әзерләгән, спектакльнең режиссеры – Лиза Бондарь. Икесе дә – Питер һәм Мәскәү сәнгатькәрләре.

Толстойны татар дөньясы белән бәйләүче җепләр шактый, моны күпләр белә. Тик Толстой күтәргән проблеманың заманы да, милләте дә юк. Чичән шагыйрәбез Клара Булатовачарак әйтсәк, гөнаһ эшләү өчен тәһарәт тә, намаз да кирәкми.

Лев Толстой «Дөм» пьесасын җинаятькә баткан бер гаилә эчендә булган чын хәлләргә нигезләнеп яза.

Сәхнә дөм караңгы, син дә шул караңгылыкта утырасың. Караңгылык эченнән гаилә башлыгы Петр (Татарстанның халык артисты Рәфыйк Таһиров) күренә. Ул авыру, инвалид арбасында гына хәрәкәт итә. Бик бай булса да, авыру хуҗаның кулыннан тормыш дилбегәсе инде ычкынып бара. Сүзенә колак салучылар юк дәрәҗәсендә. Яшь хатыны Анисья (Лилия Заһидуллина) да, хезмәтчесе Никита (Д.Хөснетдинов) да, хәтта, беренче хатыныннан туган олы кызы Акулинаның да (Ләйсән Заһидуллина) исе китми. Бөтенесенең теләге – җиңел генә баю һәм рәхәт тормыш. Шул теләк берсеннән-берсе авыр җинаятьләргә этәрә. Анисья байлыкка хуҗа булырга теләп һәм хезмәтче егет Никитага кызыгып, ирен агулап үтерә. Тик байлык аңа эләкми, Никита хуҗа була. Байлыкка кызыгып, ятимә кыз Маринканы (С.Мифтахова) алдап ташлаган Никитага хәзер Анисья кирәкми. Янәшәсендә муенына сарылырга торган Акулина бар. Әйе, гөнаһка бер бармагыңны тыксаң, башыннан чумасың. Никита да дөм-исерек дөньяда, дөм-караңгылыкка батканнан-бата бара. Атасы Аким картның (А.Шаһимәрдәнов) сүзе сүз түгел. Атасын тыңлаган – адәм булган, тыңламаган – әрәм булган дип халык белми әйтмәгән. Анда күптән намус та, оят та юк. Бай Никитага хәзер Митрич (Р.Мөхәммәтҗанов) хезмәт итә. Оятсызлык азганнан-аза, гөнаһ базы тирәнәя. Бөтен явызлыкны үз күзләре белән күреп торган Анютка (И.Нәбиуллина) гына чарасызлыктан чабулап йөри. Спектакль Акулинаның Никитадан бала табуы, «ата» кешенең нарасыйны үтерүе, әнисе Матрена (Э.Сәйфетдинова) ярдәме белән базга күмүе һәм Акулинаны башкага кияүгә биреп, аннан котылу белән тәмамлана. Никита тәүбә итә, тик дөм караңгылык таралмый, баз авызы тагын үз корбаннарын көтеп ачык кала.

Сәхнәдә бары тик берничә карт агач төбе һәм яшь килеш корыган агач көүсәләре. Башка берни дә юк. Рупордан татар һәм рус телләрендә караңгылыкның ничек кешеләрне үзенә суыруы турында заманча стильдә җыру яңгырый. Яктылык бары тик персонажларның хәрәкәтен, эш-гамәлләрен күрсәтү өчен генә хезмәт итә. Режиссер кулланган шартлылык та тамашачыда, «монысы нәрсә икән?» дигән аңлашылмаучылык тудырмый.

Инде килеп актерлар турында. Әлбәттә, театрда үз йөзен, исемен булдырган шактый гына хатын-кыз артистлар булса да, режиссерлар мондый төр спектакльләрдә күбрәк яшьләрне күрә. Яшьләр начар уйный, дип әйтә алмыйм. Ләкин тамашачы буларак, театрның егерме булган урта буыннарны да күрергә теләр идек. Спектакльдә катнашучы тугыз артистның берсе – Р.Таһиров кына – башка катнашучылар туганчы ук сәхнәдә яши башлаган, исем-дәрәҗәле актер. Аның тудырган һәр образы мөмкинлекләренең чиксез булуын, иҗат диапозонының киңлеген ассызыклый. Кулларында программа булмаган тамашачыга Петрның Рәфыйк Таһиров икәнен тану кыен булыр иде. Артист Петрның чарасызлыгын оста ачып бирде. Тавыш та, мимика да килешле. Р.Таһиров һәрвакыттагыча үз югарылыгында.

Артист Лилия Заһидуллинаның Анисьясы минем өчен чын «бомба» булды. Бик катлаулы образ булуга карамастан, Л.Заһидуллина көчсез, мескен, башсыз, чарасызлыктан явызланган бәхетсез хатын булып яши белде. Ул үзенә карата бер нәфрәт тә тудырмады, бары кызгану хисләре генә. Үз-үзен тотышы, хәрәкәтләре – бары да табигый. Ул күңеленең кайсыдыр бер җирендә кешелек сыйфатлары сакланып калуын күрсәтә алды. Бу – иренә «порошок» бирү мизгелендә һәм Никита хатыны булып бәйләү бәйләп утыру моменты. Тик ул сыйфат җанның әллә кай төпкелендә. Дөм-караңгыда башкалар гына түгел, үзе дә таба алмый. Аның каһкаһәле көлүгә охшаш авазлар чыгаруы да чарасызлык билгесе булып кабул ителә. Яңа туган сабыйны ата кешедән үтерткәндә дә, ул балага һәм анага явызлыгыннан түгел, ә Никитага булган нәфрәтеннән эшләгәнен табигый рәвештә күрсәтә алды. Әйтергә кирәк, артистның киң диапазоны, табигый сәләте ярылып ята.

Никита роле белән Динар Хөснетдинов үз иҗат багажына тагын бер саллы образ өстәде. Никитаның тискәре герой булуына карамастан, Д.Хөснетдинов аның кешелек сыйфатларын таба белгән. Кеше бит дөньяга явыз, имансыз булып тумый. Аның уенында вакыт-вакыт шул фикри иман чаткылары күренеп китә. Никитадагы мыскыллы сөйләшү, хатын-кызга түбәнсетеп карау, баланы үтерү һәм күмү күренешләре искиткеч табигый иде. Ә менә, әллә татар сәхнәсенә беркадәр ят күренеш булганга, әллә тамашачы бик якын утырганга «уйнаш» уеннарында артистның беркадәр уңайсызлык кичерүе сизелде. Ләкин бу артист талантын киметмәде. Никита-Динарның тәүбәсен күкләр дә, җирләр дә, Аллаһ та, бәндә дә кабул итмәде. Никадәр генә кызганыч булса да, гөнаһы алай гына бетәрлек түгел. Тик башкалардан аермалы буларак, бер ул тәүбә итәргә үзендә көч тапты. Тамашачы да кабул иткәндер. Чөнки ул бик ихлас ялварды.

Шәхсән үземдә иң зур нәфрәт тудырганы – Акулина-Ләйсән булды. Л.Толстой аны акылга таманрак кыз дип биргән. Ләйсән Заһидуллинаның Акулинасы чып-чын мәгънәсендә шундый килеп чыкты. Аңа карата бер кызгану хисе дә юк. «Уйнаш уенында» да актриса спектакль башланган дулкыннан читкә чыкмады. Ахырга кадәр үзенең «оятсыз» халәтен саклый алды.

Алмаз Шаһимәрдәновның Акимы никадәрле генә караңгыдан чыгарга тырышмасын, хатыныннан уза алмый. Аның башында да хатыныннан калган баш киеме. Ул көчсез, шулай да ул үзфикерле, авыр булса да үзенең хаклыгына ышана. Акимның йомшак күңеле артист тудырган образның сөйләмендә үк чагыла. Яшь артист карт кеше образын ышандырырлык, соклану хисләре уятырлык итеп башкарды.

Спектакльдә Митрич кечкенә эпизодик роль булуга карамастан, Раушан Мөхәммәтҗанов истә кала торган образ тудыра алган. Сәхнәдә бик аз күренә, сүзләре дә артык күп түгел. Ләкин ул йөзе белән уйный. Сөйләмендә рэп алымнары чагылып китә. Йөреше, хәрәкәте белән дөм-караңгыда да күрә торган икәнен, сизгерлеген югалтмаганын күрсәтә алды. Ул – спектакльдәге өч аек акыллы кешенең берсе. Ыштанын сатып эчәр дәрәҗәгә җитеп эштән чыкканнан соң, тәүбәгә килә алган мәхлук җан буларак истә кала.

Режиссер тавыш, хәрәкәтләр ярдәмендә образларны отышлы ачкан. Анюта-Илүзә Нәбиуллинаның дөм-караңгыда таеп егылырдай булып чабулап йөрүе, кылдай нечкә, менә-менә өзелергә торган тавышы. Режиссерныңмы, артистның үзенең табышымы, ничек булса да уңышлы алым.

Сәхнәдә ике генә эпизодта күренеп киткән Маринка – Сиринә Мифтахова караңгылык дөньясына көчле, ярсып, мәхәббәтә хакына горурлыгын бөтенләй югалткан шашкын хисләр белән килеп керде. Никитага булган нәфрәтен күрсәтә алды. Ә Акулина туена ирен эзләп килгән вакытта, әллә рупордан урыс сөйләме артык күп, әллә артык көчле яңгыраганга, С.Мифтахованың тавышы югалды. Әлбәттә, бу әле беренче көн. Алга таба горурлык хисләрен калкурак күрсәтсә, әлеге образ артистканың иң матур эпизодик рольләренең берсе булачак.

Дөм караңгылыкның, гөнаһ базының, явызлык, исереклек, вәхшилекнең анасы – Матрена. Өстенә элгән туны да, сырты саргаеп беткән карт күсене хәтерләтә. Байлык, акча хакына әллә нинди вәхшилеккә дә барырга әзер торуын һәм бар нәрсәдән дә коры чыгасына ышану йөзенә чыккан. Ярым бөкрәеп атлавы, йөз кыяфәте, әшәке теле – гомумән, аналык хисенең әсәре дә юк. Гамәлендә түгел, тавышында да андый хис сизелмәде.

Спектакль тәмам, тик сәхнәдән караңгылык таралмады. Дөньяга килгән бер гөнаһсыз сабыйны йоткан баз авызы да ачык калды. Ни кызганыч, Толстой бүген дә актуаль. Сүз дә юк, әле шомартасы яклар да юк түгел. Кайдадыр җитеп бетмәгән, кайдадыр артып киткән урыннар бар. Тик кай яктан гына карасаң да, уйландыра, уй яндыра торган сәнгать әсәре туган. «Дөм» карадан якты тәрәзә уя алган безнекеләр.

Рәфкать ШАҺИЕВ.

(Дәвамы. Башы 47-48 нче саннарда).

Рәис ЗАРИПОВ

ИКЕ ЙОЛДЫЗЛЫ ТАТАР

Нәкъ шул язда полк, очучыларга олы шатлык хисләре өстәп, парашютлар җыючы кызлар хисабына тулылана. Әлбәттә, бу вакыйганың үз шәхси тормышында зур үзгәрешләр китереп чыгарасын М.Гәрәев күз алдына да китерә алмый әле. Аның кызларны тәүге тапкыр күрүе турындагы истәлекләре кызыклы. Бары да полкның команда пункты янына җыела. Биредә хәрби бурычларын үтәп кайткан очучыларның гәпләшүе, күңелләрен бушатуы гадәткә әйләнгән була. Гадәттәгечә, төркемнән читтәрәк басып торучы һәм бервакытта да сөйләшүләргә катнашмаучы Гәрәев үзләре янына килеп баскан кызларны беренчеләрдән булып күреп ала һәм елмая төшеп, аларның үзара көлешә-көлешә чөкердәшүләрен тыңлап тора:

–Нәрсә турында гәп куерта алар? – дип сорый берсе үзенең ахирәтеннән.

– Ничек самолетта очулары турында, билгеле. Син әллә очучыларны белмисеңме? Мөгаен, фашистларны ничек бомбага тотулары турында мактанышa торганнардыр. Бу аларның һөнәри кимчелекләре.

– Ә теге, читтәрәк басып торганы, озынрагы кем? Очучы түгелме әллә?

– Очучы.

– Татарга охшаган.

– Шулайрак шул...

– Кара, нинди кеше сөймәс!..

Менә шушы, үзен кеше сөймәс дип атаган сержант Галина Мигунова аның гомерлек тормыш юлдашы булып чыга да инде. Мәхәббәтләре тиз бөреләнә, моңарчы кызлар белән мавыкмаган Муса тимерне кызуында суга: озакка сузмыйча өйләнеп тә куялар. Тик аңарчы, мондый хәлиткеч адым ясаудан алда полк командирыннан рөхсәт алу мәслихәт. Монысы исә яшь очучы кече лейтенант өчен катлаулы бурыч. Чөнки кызу канлы Василий Стефанович туры сүзле егеткә карата үтә кырыс позициядә тора. Кыскасы, баштагы мәләрне командир белән очучының борчаклары пешми. Әмма полк командиры үз рөхсәтен бирә, аның кырыслыгына карамыйча, гадел була белүе М.Гәрәевне беренче хәрби бүләккә тәкъдим иткәндә дә чагылыш таба.

1943 елның 19 апрелендә полк командиры гвардия майоры Василий Семенов очучы кече лейтенант Гәрәевне, Сталинград янындагы сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен, Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим итеп тутырылган документны имзалый. Анда очучының батырлыклары шактый җентекләп тасвирланган: “1942 елның октябреннән, алманнарның камалышта калган гаскәрләрен тар-мар иткәнче, Сталинград фронтында булды. 9 хәрби очыш вакытында кече лейтенант Гәрәев дошманның өч “Ю-52” самолетын, ике танкын, 6 автомобилен, 30-40 солдатын һәм офицерын юк итте...”

Әмма 1 нче гвардия штурмлау авиациясе дивизиясенең вакытлы командиры гвардия подполковнигы Алейников яшь очучыны “Батырлык өчен” медале белән генә бүләкләргә карар кыла. Бу документның икенче ягында язылган. Ниһаять, 1943 елның 30 апрелендә СССР Югары Советы Президиумы исеменнән дивизиянең 4 хәрбиен медальләр белән бүләкләү турындагы яшерен боерык чыга...

Звено командиры кече лейтенант М.Гәрәевне беренче орден белән бүләкләгәндә дә, бераз матавыклар булмый калмый. 1943 елның 24 июлендә майор Семенов үз очучысын Кызыл Байрак ордены белән бүләкләргә тәкъдим итеп тутырылган документка кул куя. Тик дивизия командиры генерал-майор Токарев звено командиры кече лейтенант Гәрәевне күпкә түбәнрәк дәрәҗәдә йөрүче Кызыл Йолдыз орденына лаек дип саный...

Хәер, каһарман очучыны Кызыл Байрак ордены белән бүләкләү мизгелләре дә озак көттерми: 1943 елның 5 августында полк командиры гвардия майоры Семенов звено командиры кече лейтенент Гәрәевне Ленин орденына тәкъдим итеп тутырылган документка кул куя. Очучы андый югары бүләккә шул елның 8 маеннан 1 августына кадәрге чорда 14 хәрби бурыч үтәгәндә күрсәткән батырлыклары өчен лаек дип табыла. Өч көннән документның икенче ягына дивизия командиры генерал-майор Токаревның да имзасы төшә. Тик анда Борис Кузьмичның милләт баласын түбәнрәк дәрәҗәдәге Кызыл Байрак ордены белән бүләкләргә карар кылуы язылган. 8 нче һава армиясе командующие авиация генерал-лейтенанты Тимофей Хрюкин дивизия командиры тәкъдиме белән килешә: Кызыл Байрак ордены белән бүләкләү турындагы боерык 1943 елның 20 августында чыга...

1944 елда Муса Гәрәев 2 Кызыл Байрак һәм Александр Невский орденнары белән бүләкләнә. Ел башында дошман позицияләрен штурмлауга ул инде 6 һәм 8 самолеттан торган төркемнәргә дә җитәкчелек итә башлый. Нигездә, һәрвакыт югалтуларсыз аэродромга әйләнеп кайтучы командирга аннан күбрәк самолетларны әйдәп очарга да туры килә. Шундый үзгә бер очракны ул үз истәлекләрендә дә бәян итә: “21 гыйнварда мине полк командиры үзенә чакыртты.

– Төркем белән дошман аэродромына очарга әзерлән. Разведка хәбәр итүенә караганда анда бик күп самолетлар тупланган. Яхшылап эшкәртегез үзләрен! – диде ул.

– Бурычны җиренә җиткереп үтәп чыгарга әзер, – дим үтә көр тавыш белән, үзем исә күңелдә генә аэродромга маршрут сузам.

– Төркемдә 18 машина. Аз түгел. Башкарып чыгарсың дип уйлыйм”.

Бу юлы да М.Гәрәев теләсә нинди катлаулы бурычларны үтәргә сәләтле икәнен күрсәтә: әлеге очыш вакытында аның төркеме дошман аэродромындагы 14 самолетны юкка чыгара, 15 енә зыян сала. Язын Никольскийдагы дошман плацдармын кыйратуда катнашкан 76 нчы полк, Кырым өчен барган сугыш хәрәкәтләре барышында уртак җиңүгә саллы өлеш кертә. Кырым операциясе 8 апрельдә башланып китә һәм 12 майга кадәр дәвам итә. Тәмам алынмаслык кирмәнгә әйләндерелгән ярымутрауда дошман объектларына бомбалар яудырырга барганда, өлкән лейтенант Гәрәев төркемен еш кына, исеме бөтен фронтка яңгыраган кырым татары Советлар Союзы Герое Әхмәтхан Солтан командалыгындагы истребительләр эскадрильясы лачыннары саклап оча. Әле хәтта ике очучыга очрашып танышу мөмкинлеге дә чыга. Күренекле якташыбызның, үз истәлекләрендә, “тормышта һәм яуда шул искиткеч кешегә бик тә охшарга тырышу теләге туды” дип аерым басым ясап язуы гайре табигый хәл түгелдер. Дошман исә ахыргача үҗәтләнеп каршылык күрсәтә. 5 майда Херсонес борынындагы алман самолетлары тупланган аэродромны бомбага тотарга очкан майор Тюленев, капитан Анисимов һәм өлкән лейтенант Филиппов җитәкчелегендәге төркемнәр зур югалтуларга юлыга. Гәрәевнең якын дусты Виктор Протчев самолеты да әйләнеп кайтмый. Бәхеткә, зарарланган самолетын үзебезнең якка алып чыга алган яралы очучыны санитар машинасында аэродромга кайтаралар. Ул терелеп сафка баскач, күп очышлар ясый, Алтын Йолдыз белән бүләкләнә, сугышны майор булып тәмамлый.

Бу урында, кайбер аңлашылмаучанлыкларга урын калдырмау җәһәтеннән, Сапун-тауны штурмлау турында тарих битләрендә язылганнарга да игътибар юнәлтү мөһим. Хәрби чыганакларда расланганча, нәкъ 5 майда Севастопольне азат итү өчен сугышлар башланып китә. Һәр метр җир өчен үҗәтлек күрсәтеп сугышкан алман гаскәрләре бер үк вакытта Кырымнан эвакуацияләнә башлый. Шул тарихи көннәрдә командование совет штурмовикларына алманнарның Херсонес борынындагы төп аэродромын тар-мар итү бурычын куя. 1944 елның 5-7 май көннәрендә 1 нче гвардия дивизиясенең, шул исәптән 76 нчы авиаполк очучыларының Сапун-тауны штурмлауга зур өлеш кертүе турында Кырымны азат итү тарихына язылып калган. Әлбәттә, җиңү җиңел генә бирелми: өч көн эчендә дошман 90 совет самолетын бәреп төшерә, шуларның 33 е зенит артиллериясе утына эләгә. Бу сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен күп кенә очучылар Алтын Йолдызга лаек дип табыла. Мисал өчен, Виктор Протчевның биографиясендә Кырым өчен полк очучылары М.Г.Гәрәевнең, В.И.Протчевның, И.А.Воробьевның һәм тагын кайбер очучыларның Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителүе раслана. Әмма ярымутрау азат ителгәч, 12 майдан Югары Башкомандование резервына чыгарылган 1 нче гвардия штурмлау дивизиясен 8 нче һава армиясе составыннан алалар һәм 8 июньдә, Белоруссиядә башланып китәргә торган “Багратион” һөҗүм операциясендә катнашырга тиешле 1 нче һава армиясе составына кушалар. Шул ыгы-зыгы вакытында очучыларның мактаулы исемнәргә тәкъдим иткән документлар 8 нче һава армиясе штабында эзсез югала һәм, аларны кабаттан яңартканнан соң гына, 1945 елның 23 февралендә, СССР Югары Советы Президиумы Указы белән очучылар Алтын Йолдызлар белән бүләкләнә. Әмма хөкүмәт бүләкләрен очучылар кулына тапшырырга ашкынучылар булмый әле.

1944 елның 2 ноябрендә 3 нче Белоруссия фронты составындагы 1 нче һава армиясе буенча үз хәрбиләрен орден-медальләр белән бүләкләү турында яшерен Боерык дөнья күрә. Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүчеләр арасында эскадрилья командиры капитан М.Гәрәев тә бар... 1945 елның 17 нче гыйнварында 76 нчы авиаполк командиры гвардия подполковнигы Д.Бочко 2 нче эскадрилья командиры гвардия капитаны М.Гәрәевне II дәрәҗә Богдан Хмельницкий орденына тәкъдим итеп тутырылган документны имзалый. Ниһаять, 2 март көнне үз хәрбиләрен орденнар белән бүләкләү турында 3 нче Белоруссия фронты буенча яшерен Боерык чыга. Документта әүвәл капитан Гәрәевнең 1944 елның апрель аеннан эскадрилья командиры вазыйфасына билгеләнүе һәм Кырым ярымутравы белән Севастополь каласын азат итүдә катнашуы, аннан соң полк составында Белоруссия, Литва өчен сугыш хәрәкәтләрендә үзен оста командир итеп танытуы, Көнчыгыш Пруссиядә алман баскыннарын тар-мар итүгә саллы өлеш кертүе ассызыклана. Сталинград, Көньяк, 4 нче Украина, 3 нче Белоруссия фронтларында 177 хәрби очыш ясаган очучының 5 орден белән бүләкләнүе, ә аның эскадрильясы ясаган хәрби очышларның 755 кә җитүе һәм шул чорда нибары 4 самолет кына югалтулары турында бәян ителә.

25 февральдә гвардия подполковнигы Д.Бочко гвардия майоры М.Гәрәевне, соңгы хөкүмәт бүләге алганнан соң ясаган 27 хәрби очышы өчен чираттагы Кызыл Байрак орденына тәкъдим итеп тутырылган документка кул куя. Тик дивизия командиры гвардия полковнигы С.Прутков очучыны фәкать I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләргә ризалашуын раслап, ике көннән документны имзалый. 2 апрельдә СССР Югары Советы Президиумы исеменнән үз хәрбиләрен орденнар белән бүләкләү турында 1 нче һава армиясе командующие авиация генерал-полковнигы Тимофей Хрюкин һәм штаб башлыгы авиация генерал-майоры Иван Белов имзалаган яшерен Боерык чыга. Бүләкләү документында М.Гәрәевнең 23 февральдә Алтын Йолдыз медале һәм Ленин ордены белән бүләкләнүе күрсәтелми, ягъни, бу күңелле хәбәр ирешү өчен ике көн генә җитмәгән, дигән сүз...

● Муса Гәрәев. 1944 ел.

(Дәвамы киләсе санда).

КЫЧЫТКАННАР

Нигез елый, диючеләр хаклы:
Елый икән нигез тавышсыз...
Шамил МАННАПОВ.

Кешеләре киткән, авыл беткән,
Урыны гына ята каралып.
Кычытканнар тора еламсырап,
Нигез ташларына сарылып.

Кычытканнар исән, ни хәлдә дә
Нигезләрен ташлап китмәгән.
Үз кадерен белеп яшәгәнне
Туган туфрак ятим итмәгән.

Туган җиргә тугры кычытканнар
Бала чакта азмы елаткан!
Кычытканга чагылып үткән еллар
Бәхетлерәк булган күп яктан.

Кычытканнар! Әрсез кычытканнар!
Шифалы да, усал, хәтәр дә.
Беткән авыл рухын саклап торган
Кычытканнар чыкмый хәтердән.

БЕЗ КИЛМЕШӘК КАВЕМ ТҮГЕЛ

Күз ташлыйм да ерак үткәнемә,
Сөенеп куям: гаҗәеп үткәннәр.
Бабаларым килмешәкләр түгел,
Монда туып, монда үскәннәр.

Шушы җирдә тамыр җибәргәннәр,
Урман арчып, иген иккәннәр.
Киек-җәнлек аулап, терлек асрап,
Гаилә корып гомер иткәннәр.

Нинди халык, кемнәр булган алар,
Кем кабызган тәүге учакны?
Тамырларда ага кемнәр каны –
Болгар, Нугай, әллә Кыпчакмы?

Шушы хакта әле дә бәхәс бара,
Кемгә генә безне кертмиләр.
Нәсел-шәҗәрәбез эргәсендә
Тора фин-угорлар, төркиләр.

Бу төбәктә төрки Атилланың
Оныклары яшәп калганнар.
Шушы хакта сөйли табылдыклар,
Иске каберлекләр, курганнар.



Идият ӘШИРОВ

Көзге җилдә бөтерелә яфрак,
Оча, югарыга тартыла.
Үзе сизми: гомер җәе үткән,
Яшимен, дип, һаман талпына.

Кире кайтыр иде, булдыра алса,
Яшел яфрак булган чагына.
...Кешеләр дә шулай, торган саен,
Яшьлекләрен ныграк сагына.

ҖИТМӘҮ

Җитмиләрне җиткерергә
Вакыт җитеп бетми...
Фәнис ЯРУЛЛИН

Табигатьтә бары да җитеш,
Күпне өмет итми.
Кешеләргә генә җирдә
Гел нәрсәдер җитми.

Кемнәргәдер эчәр суы
Йә икмәге җитми.

Кычытканга чагылып үткән еллар Бәхетлерәк булган күп яктан...

ШИГЫРЬ ЯЗГАН ИДЕМ

Шигырь язган идем унбер яшьтә,
Сабакташлар укып көлделәр:
«Без белмәгән берәр шагыйрьнекен
Чәлдергәндер әле», – диделәр.

Шигырь язган идем унсигездә:
«Гашыйк булгандыр бу?» – диделәр,
Таныш кызлар: «Кем соң илһамчысы,
Мин түгелме?» – диеп йөрделәр.

Шигырь язган идем утызларда,
Кыйнадылар, тәнкыйтьләделәр:
«Фикерең сай, шулай да яз, әйдә,
Гонорары булыр», – диделәр.

Шигырь язган идем кырык яшьтә,
Мактадылар, күккә чөйделәр:
«Тырыша торгач, булдырган бит малай,
Дүрт юл шигырь язган», – диделәр.

Шигырь язган идем өлкәнәйгәч,
Миңа карап гаҗәпләнделәр.
Аннан кызгандылар: «Моңарга да
Бала акылы кергән», – диделәр.

ИСКӘ ТӨШӘ ӘНКӘЙ СҮЗЛӘРЕ

Әйтә торган идең: «Өлкәннәргә
Авыр сүз әйтмәгез, балалар!»
Шул сүзләрең, әнкәй, бүгенгедәй
Җанга кагылып-кагылып алалар.

Әйе, киңәшеңне тотмаганбыз,
Калдырганбыз картлар хәтерен.
Гаепләп йә ватып кичәгене,
Җайлап әйталмыйча әйтерен.

Намус беткән, әхлак зәгыйфьләнгән,
Имансызлар арткан заманда,
«Кем гаепле?» дигән бакый сорау
Борчып тора шуңа һаман да.

Нинди булыр бездән соңгы буын,
Аңларлармы кеше кадерен?
Тәрбияләп, соңгы юлга озатып,
Зиярәт кылырлармы каберен?

«Өлкәннәрне, берүк, рәнҗетмәгез!»
Искә төшә әнкәй сүзләре.
Шушы сүзне әйткән әнкәйләрнең
Кадерләдек микән үзләрен?

Шул чорларның телсез шаһитлары –
Табыла сөңге, окоп эзләре...
Күргән төсле булам шул чагында
Бабамнарның нурлы йөзләрен.

Әйе, Тол буеннан төркиләрнең
Җитез чаптарлары үткәннәр.
Унбер Әхмәт, Җиде Газизләре
Оран салган, тәкбир әйткәннәр.

Дошман килсә, уртак йортны саклап,
Яу чапканнар гаярь ирләре.
Куылып килгән монда яклау тапкан,
Сыендырган Гәйнә җирләре.

Ни хәлдә дә күңелен төшермәгән
Безнең халык элек-электән.
Татар, башкорт, удмурт, урыс – барысы
Бертугандай булып береккән.

Күз ташлыйм да нәсел-шәҗәрәмә,
Әйтеп куям шулчак рухланып:
«Әйе, без килмешәк кавем түгел,
Без – тарихта эзле, зур халык».

ӘМАНӘТ

Кеше хакын хаклау, вөҗдан, намус
Өлкәннәрдән күчкән әманәт.
Ахры, шуңа кыен чакларда да
Чыгармадык кебек яманат.

Рәнҗетмәдек авыр сүзләр әйтеп,
Кеше өлешенә кермәдек.
Кемнәргәдер ярап, койрык болгап,
Тәлинкәләр тотып йөрмәдек.

Кызыкмадык малга, дәрәҗәгә,
Булмады һич андый хирыслык.
Тик хезмәттә таптык чын бәхетне,
Кыйблабыз булды дөреслек.

Белләм: күпләр безне аңламады.
Санадылар хәтта юләргә.
Санасыннар! Кеше булып үстек,
Кеше булып язсын үләргә.

Иманнар сау, рухыбыз нык калыр,
Купканда да җирдә кыямәт.
Үзгәрү яшеннән уздык бугай,
Әманәткә булмас хыянәт.

БАРДА БЕЛӘН АРЧА АРАСЫ

Барда белән Арча арасы...
Ничә чакрым икән барасы?
Очрашсыннар, сөйләшсеннәр әле
Бер милләтнең ике баласы.

Барда белән Арча арасы...
Кардәшлекне искә аласы:
Тукай булса Арча җиреннән,
Каҗмактыдан чыккан бабасы.

Барда белән Арча арасы...
Җанга рәхәт йомшак һавасы,
Арча киче, Барда таңнары
Күңелләргә кереп каласы.

Барда белән Арча арасы
Дуслык юлы булып каласы,
Каршы алыр, озата барыр әле
Дусларымның җылы карашы.

РӘССАМ БУЛӘГЕ

Пейзаж бүләк итте күршем.
Уйга калдым бер мәлгә:
Тере табигать каршыма
Килеп бастымы әллә?..

Елга агышлары салмак,
Каеннар моңсу хәлдә.
Ник сары төсне күп биргән,
Рәссам ялгышкан мәллә?

Күршемнең бу иҗат эшен
Мин яхшыга юрадым.
Мөгаен, бу – август ахыры,
Көз башы, дип уйладым.

Аңларга була анысы
Мондый хәлне ничек тә.
Рәссамның яше бит бүген
Илле түгел, җитмештә.

КӨЗГЕ МОҢ

Өзелде дә кинәт сары яфрак
Иңнәремә килеп сарылды.
Шушы мизгел, сары сагыш булып,
Күңел кылларыма кагылды.

Саф һавалы туган ягы
Истән чыгып бетми.

Кемгә акча, кемгә чүпрәк,
Кемгәдер җир җитми.
Качак булып куылулар,
Кан коюлар бетми.

Ил башында торганнарга
Уйлап эшләү җитми.
Адым саен ялгышулар
Башка сыеп бетми.

Җитми акыл, җитми намус,
Бик күп нәрсә җитми.
«Җитми»ләр җитәр иде дә,
Кеше булу җитми.

ЯХШЫ КЕШЕ ЕШРАК КАГЫЛА

Сүнеп барган чакта ышанычлар,
Авырлашса тормыш тагын да,
Ярдәмләшер, терәк булыр дуслар,
Яхшы кешеләр, шөкер, табыла.

Җиңел түгел яхшы булулары –
Андый җаннар ешрак кагыла.
Ак төсләргә җирдә, пакь хисләргә
Каралыклар тизрәк ягыла.

Начарлыкка күнекмәгәнгәме,
Кеше күбрәк акка табына.
Тышта – яшьлы яз, ә күңелең
Ак буранлы кышны сагына.

РЕДАКЦИЯДӘН. Пермь крае Барда авылында яшәп иҗат итүче шагыйрь, байтак популяр җырлар авторы Идият Әшировка шушы көннәрдә 75 яшь тулды. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән котлыйбыз, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары телибез.

Нәкый Исәнбәтнең җанисәптәге сүзе

Нәкый Исәнбәтнең архивы белән эшлим, минем өчен бу затлы мәгарә ишекләре ачык. Архив ике фатирда урнашкан. Бу шәхеснең олуглык масштабын аңлау да читен. Ул «Хәсәния» һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрен тәмамлаган, совет мәктәбе белеме юк, әмма Алматы советының һәм Көнчыгышны өйрәнү институтының бәйсез эксперты булган. Аны «халык академигы» дип йөрткәннәр. Аның зур хезмәте турында Scopus мәкалә-рецензия 1972 елда чыга. Татар гуманитарлары арасыннан әле беркемнең дә ул дәрәҗәгә җитә алганы юк. Аның хезмәтләрен чит ил галимнәре эзләгән, таптырган; китаплары җибәрелеп торган, ә Н.Исәнбәт үзе дөньяга чыга алмаган. Бервакыт ул Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә урнашырга дип баргач, Гали Халитов аңа: «Синең совет белемең юк, мин сине хәтта лаборант итеп тә алмыйм», – дип кире борган.

Архивларда Нәкый аганың бер гаризасына юлыктым. Эзли торгач, бу гаризага бәйле хатларын да таптым.

* * *

Бүген, җанисәп алуның чираттагы дулкынын ерып чыкканнан соң, без «замана шартларында ничек исән калырга» дигән сорауга туктаусыз бәхәсләр алып барган көндә, мине татар һәм башкорт арасындагы гади булмаган мөнәсәбәтләр борчый. Без – тугандаш халыклар, мөгаен, күптән инде «Кем беренче туган?» дигән сорауны ябып, тату яши башларга кирәктер. Алда телгә алган чыганакларны мин нәкъ шуңа күрә халыкка чыгарырга карар кылдым: ни эше, ни элемтәләре булмаган, һичкем ярдәм итмәгән килеш, ялгыз бер кеше халык исәбен алуда бозып күрсәтү очракларын булдырмый калу өчен олы бер борылыш ясый аламы? Менә шуны күрсәтергә телим.

Мин татарлар да, башкортлар да дәгъва белдерә алмастай галимнең фикерләренә таянырга карар кылдым. Дмитрий Горенбург мәкаләсеннән өзек, 1959 елгы җанисәп алу нәтиҗәләрен ул ничек бәяли:

«1959 елда башкорт нәселләре саны, мөгаен, гомуми халык санын алу чорында хакимиятнең гамәлләре, аерып күрсәткәндә, «башкорт» дип язылырга мәҗбүр итү максатыннан, респондентларга административ басым ясау белән бәйле. 1959 елгы җанисәп алдыннан Башкорт хөкүмәте, кешегә милләте турында сорауга җавап биргәндә, «үзаңлылыкка таянырга кирәк, ул туган тел белән туры килмәскә дә мөмкин» дигән пропаганда кампаниясен үткәрә. Җирлек халкына, «бу ике билге туры килмәгән очракта, милләтең үзаң белән билгеләнә» дип күрсәтмә бирелә».

* * *

Исәнбәтне эзәрлекләүләр оештырылган чорда, аның «Миркәй белән Айсылу» әсәренә карата обком карары чыга. Бер генә язучы да шундый «дан»га лаек түгел! Туктаусыз борчулардан көчәйгән астма чире аркасында көчкә тын алучы, үлем белән якалашучы өлкән әдип 60 яшен каршыларга әзерләнгәндә җыентыгын чыгара, һәм кинәт обкомның аны милләтчелектә гаепләгән карары дөнья күрә! Әсәрдәге нибары бер җөмлә – әсәр героеның «Мөселман кардәшләр!» дигән бер репликасы өчен! Һәм барысы да аны панисламчылыкта гаепләргә тотына! Әммә Исәнбәт – обком карарын гамәлдән чыгарттыра алган бердәнбер кеше!

Исәнбәтнең җәдидчелеккә багышланган 3-4 варианттагы хезмәтенә тап булгач, аның кыюлыгына янә шаккатмалы. Саулыгы начар булуга карамастан, Исәнбәт татар җәдидчелеген яклау юлына баскан икән. Мәскәүдәге СССР тарихы институты оештырган кампания төрки халыклар өчен аяныч нәтиҗәләргә китерә һәм мәгърифәтчелекне феномен буларак юкка чыгара. Җәдидчелек – ул рус мәгърифәтчелеге түгел, XX гасыр башында булдырылган культурага бүген андый үлчәүләр белән якын килергә ярамый, ди ул. Әз дә түгел, күп тә түгел, Исәнбәт институтның директоры белән тарткалаша! Галимә Галләмова миңа архивта бары тик беркетмәне генә табуын, Исәнбәтнең китабын очратмавын белдерде. Китап юкка чыгарылган, әмма гауга бик зур була.

Исәнбәтнең Мәскәүгә сәфәрен мин партия карарын гамәлдән чыгару максаты белән оештырылган, дип уйлаган идем. Абына-сөртенә, көчкә-көчкә тын алып, кулына таяк тоткан Исәнбәтнең көч-хәл белән поезд вагонына менүе турында бик тәмләп сөйләгән сүзләр күп булды. Әммә бу яңа ел сәфәренең максаты бөтенләй башкада булган икән. Бу – билгеле шәхеснең партиягә дә, башка интеллигенция вәкилләренә дә таянмый-аркаланмыйча, үз интеллектына гына ышанып, бюрократия машинасы белән көрәшкә чыга алуының бер мисалы. Шуңа таянып, алда сөйләнгән гаризаның төп асылын да аңлатырга мөмкинлек туа.

* * *

Безнең татар зыялылары бик еш кына, мәсьәләнең төбенә төшеп тормастан, үз коллегаларына ярлык тагарга ярата. Әммә хакыйкать турында уйлану һәм нәтиҗә ясау өчен янә бер хат тәкъдим итик әле.

Бу хат СССР Фәннәр академиясе этнография институты директоры исеменә юлланган. Ул Н.Исәнбәт имзасы белән киткән. Адресы да Исәнбәтнең шәхси адресы: Мясницкая, 5. Шушы ук эчтәлектәге хатны Н.Исәнбәт Башкортстан АССР Статистика идарәсе башлыгына да юллый. Өченче хат исә Үзәк статистика идарәсе башлыгы исеменә юл ала. Хат рус телендә язылган, кыска, төгәл һәм ачык.

«Гомуми халык санын алу якынлашкан көннәрдә, Башкортстанда яшәүче татар, типтәрләрне «башкорт» итеп яздырырга чакыручы мәкаләләр чыга башлады. Мин үзем БАССРның Салават районы Малаяз авылыннан. «Типтәр» атамасы безнең авылга да туры килә, шуңа күрә мин түбәндәгеләрне җиткерергә телим: «типтәр» дигән милләт юк! Алар – яшәү урыны буенча Башкортстанга кушылган татарлар. Типтәр сүзе «кушылган» дигәнне аңлата. «Типтәр» сүзе үзе үк бу кешеләрнең Башкортстанның җирле халкы түгел, башкорт милләтеннән булмаган, читтән килгән кешеләр икәнен әйтеп тора. Безнең Малаяз – тулысынча татар авылы. Авылның шәҗәрәсе башкортларның безнең нәсел җебенә һич катнашы булмауларын күрсәтә. Бу шәҗәрә авылда да саклана, минем кулымда да бар».

Башкортстанга баргач, Исәнбәт искә алган музейга да кердем, әмма миңа бу документны күрсәтүдән баш тарттылар.

«Икътисадый яктан караганда, безнең авыл Башкортстанга кушылган башка татар авыллары шикелле үк шартларда яши. Авылның үз җирләре булмый диярлек, шуңа күрә революциягә кадәр ул башкортлардан басулар арендалый. Шул рәвешле, үз тарихы, икътисады һәм килеп чыгышы ягыннан башкорт авылы булмыйча, авылыбыз үз татар телен, гореф-гадәтләрен, тормыш рәвешен, көнкүрешен саклап калган. Хәтта хәзерге башкорт язучылары да үз әсәрләрендә безнең авылны «татар авылы» дип күрсәтә. Мәсәлән, Т.Гыйләҗетдинов – үз шигырьләрендә. Шул рәвешле, фәнни рәвештә типтәрләрне «башкорт» дип атау мөмкинлеге булмаган килеш, гомуми халык исәбен алу вакытында типтәрләрне «башкорт» дип яздырырга маташу, дип атала бу күренеш. Мәкалә авторы бу темага үз тезисын тәкъдим итә: имеш, типтәр – ул башкортлашкан тел, һәм, дәлил буларак, анда «ч» хәрефе урынына «с» хәрефе кулланыларын китерә».

Бу урында Исәнбәт башкорт телчеләренең эшчәнлеген анекдот дәрәҗәсенә, абсурд чиккә җиткерә, язын бу хат белән танышкан бер генә рус цензорына да моны кире кагу уе килмәслек итә.

«Әйе, безнең авылда да бу күренеш бар. Әммә ул берничек тә безнең телнең башкорт теле икәнлегенә дәлил булып хезмәт итә алмый. Ул – татар сөйләшенең бер төре генә. Хәтта Казан астында да, Дөбьяз районында «ч» хәрефе урынына «с» дип сөйләшәләр, аларның «печән» урынына «песән» дип әйтүләре Казан татарларының рәхәтләнеп көлүенә бер сәбәпче дә булып тора.

Мишәрләр исә «с» урынына «ц» хәрефе куллана. Бу күренеш русларда да бар. Безнең күрше рус Малаязы авылында «чай» урынына «цай», «четыре» урынына «цетыре» дип әйтәләр.

Мондый җирле сөйләш формаларына карап, әлеге телнең башкортныкына каравын исбатлап булмый, чөнки һәркемгә яхшы билгеле: милли башкорт теле «с» хәрефенә түгел, ә бәлки «һ» хәрефенә һәм башка билгеләргә карап аерымлана».

Ювелирларча нечкә осталык! Кечкенә генә рус Малаязы – бу авылга юл аша гына, анда рус мәктәбе эшли. Этнология институты, димәк, рус Малаязы авылы да башкорт телендә сөйләшә, дип танырга тиеш булачак. Бу – Исәнбәтнең телне ювелирларча нечкә дәрәҗәдә белүе һәм тезислау осталыгы.

«Шәхес буларак, һәркем үзенең кайсы милләткә каравын үзе билгеләргә хокуклы. Территорияләр туры килми, дигән сәбәп белән һәм теге яки бу хәрефнең татар-башкорт, типтәр телендә булу-булмавына карап, максатчанлык һәм зарурият белән мотивлаштырып, тулы бер авылларны «башкорт» дип яздырырга агитацияләү омтылышы, бәлки, аларны үзләрен «башкорт» дип яздырырга мәҗбүр дә итәр, әммә бу – гадел һәм дөрес булмаячак».

* * *

Алга таба Н.Исәнбәт Фәннәр институтына башкорт галимнәре тезисларын юкка чыгара торган үз хезмәтләрен тәкъдим итә. Бер караганда, иләк белән су ташуга тиң бу. Анда – институтлар, авылларга чыгып җанисәп алу кампаниясен алып баручы уннарча галим, монда – дәшмичә, «шыпырт кына» утыручы татар обкомы, һәм менә Исәнбәт. 60 яшьлек юбилеена беренче җыентыгын нәшер итә, инде кулларына тоткан вакытта аңа каршы обком карары чыга, олы бер пьесаны ертып аталар, һәм җыентык сатылмый – рәнҗергә тиештер кебек. Ә юк, Исәнбәт андый түгел! Ә җәдидчелек белән көрәш?! Әз булдымы? Һаман үз эченә бикләнмәгән, Мәскәү кадәр Мәскәү институты белән бәхәсләшә!

Исәнбәт, чынлап та, яңа елда Мәскәүгә бара, ләкин җәдидчелек өчен дә түгел. Чөнки ул китап язылган бит инде, галимнәр аны аңлар, дискуссия булыр, дигән фикергә килә. Аны хәтта обком карары да борчымый, аны, барыннан да бигрәк, татарларны башкортлаштыруның нинди хәвефкә китереп җиткерү мөмкинлеге һәм Советлар Союзында бюрократия машинасының ничек эшләве борчый.

Аның хатына Мәскәү мондый җавап бирә:

● Х. Туфан, Ш. Гали, Н. Исәнбәт, М. Кәрим, Ә. Еники.

«Хөрмәтле Исәнбәт! РСФСР-ның Үзәк статистика идарәсе башлыгы Колпаков яза.

РСФСРның ҮСИ типтәр милләтен билгеләү мәсьәләсендә сез китерген күрсәтмәләрне дөрес дип саный. Җанисәп алучылар түбәндәгеләргә таянып эш итә: сорашылган кеше үзе әйткәнчә итеп, кәгазьгә милләте языла. Типтәрләрне язганда, сорашылган кешедән үзен ул типтәр-башкортка кертәме, әллә типтәр-татарга кертәме икәнен сорау таләп ителә.

21 гыйнвар, 1959 ел».

«Типтәрләрне язганда, сорашылган кешедән үзен ул типтәр-башкортка кертәме, әллә типтәр-татарга кертәме икәнен сорау таләп ителә» дигән шушы бер җөмлә өчен көрәшә галим. Исәнбәтнең гарәпчә имзаланган хаты кыска вакытта барып җитә. 10 гыйнварда яза, 21 гыйнварда инде җавап килә. 28 гыйнварда исә СССР ҮСИ (бөтенсоюз дәрәҗәсенә менеп җитә!) Бөтенсоюз җанисәпне үткәрү буенча идарә башлыгы урынбасары Максимовтан җавап ала:

«Сезнең 1959 елның 10 гыйнварында язган хатыгызга җанисәп вакытында типтәрләр санын алу тәртибенә аңлатма РСФСР ҮСИ тарафыннан 2911341 саны астындагы хатта 22 гыйнвар көнне бирелде».

Шулай итеп, бөтенесе тын гына нидер көткәндә, бер кеше, бер галим халык саны алу исәбе кәгазен үзгәртә һәм нинди зур югалтуларга китерәсен искә төшерә. Моны берүзе, институтлардан башка эшли.

* * *

Шушы кысылу-тыкшынулардан Исәнбәт үзе һәм татар мәдәнияте никадәр зур югалтуларга дучар булуын аңлар өчен, мин ике хаттан өзекләр укып китәргә телим.

Нәкый Исәнбәт Сәйфи Кудаш белән дус була. Кудаш аның янына килеп йөри, Исәнбәт аша татарларның җанисәпкә, декадага ничек әзерләнүләрен белеп тора. Декада алдыннан Исәнбәт янына килгәч, Кудаш аның «Башкорт фольклоры» дигән хезмәтен алып китә. Галим аны нәшер итү өчен бирә. Исәнбәт бу хезмәтне әле 1930 еллар уртасында ук язган, һәм башкорт зыялыларының монда үз-үзләрен тотышы логикага туры килми. Бу – татар-башкорт фольклоры түгел, мондый мәдәни катлам да барлыгын дәлилләүче чиста башкорт фольклоры. Исәнбәт җидегәнчелектә, аннан алда милләтчелектә гаепләнә, аны репрессияләргә тиеш булалар, шуннан файдаланып, башкортлар, Казанга килгәч, бу томны тапшыралар. Әмма мин аның папкасын таптым, ул буш…

Һәм менә, ниһаять, Сәйфи Кудашка хат. Әхнәф Харисовның «Башкорт халкының әдәби мирасы» китабын тәнкыйтьләп, үзенең тар карашлы күрсәтмәләре белән башкорт галимнәренең кәефен төшерде дип, Сәйфи Кудашның Исәнбәткә карата кисәтүле мәкаләсе дөнья күрә. Бу вакытта Исәнбәт – изоляциядә. Аны татарлар да өнәп бетерми, башкортлар да яратмый. С.Кудаш обком белән бәйләнештә, дәрәҗәсе зур, Исәнбәтнең дусты, бергәләп, төрле мәсьәләләрне хәл итәләр. Бу очракта дәшми калуны, эшне зурга җибәрмәүне таләп иткән дустына ничек оста, ювелирларча төгәллек белән җавап бирүендә Исәнбәтнең кыюлыгы чагыла:

«Син, (Сәйфи) Әхнәфнең тезислары дөрес, ул – татар-башкорт культурасы дуслыгы, аларның тарихи хезмәттәшлегенә ярдәм итә (дип санайсың). Мине дә, тискәрелеккә барып, шуңа каршы килә, дип орышасың. Бу дөрес түгел. Мин халыклар дуслыгы һәм культура багланышлары ягында торам. Ләкин Әхнәфнең китабы шуңа хезмәт итәме соң? Ул бит татар культурасын, аның әдәбияты нигезен инкяр итә. Аны, юк нәрсә, дип бара. Янәсе, ул әдәбият Тукайдан гына башланган. Хәтта Тукай да, аныңча, татар авыз иҗатын, кыйммәтен инкяр иткән. Әмма Гафури, Акмуллаларның том кантуннарын Тукайдан да элек язулары билгеле. Шунлыктан, аныңча башкорт әдәбияты Тукайга кадәр күп алдан туган».

Бүген бездә Гафури томнары басылып чыга. Җанисәп вакытында кабат Гафуриның нинди телдә язуы, кайсы милләткә каравы турында дискуссияләр булды, югыйсә, архивның кайда саклануы билгеле. Ә мин сезгә үзенең дусты белән ачуланышудан да курыкмаган галим-энциклопедиянең 1966 елгы сүзләрен җиткерәм. Исәнбәт «башкорт әдәбияты чыгытай әдәбиятыннан килеп чыккан, ул безнең татар әдәбиятыннан борынгырак» дигән тезиска каршы чыга. Болар, шулай ук, халык саны исәбен алуга барып тоташкан механизмның бүген без күрә торган нәтиҗәсе.

«Ул (Ә.Харисов), башкорт әдәбияты борынгы чыгытай әдәбияты нигезендә үскән, татарның Тукайга кадәрге әдәбиятында үзбәк-чыгытай төркисе булган, ягъни борынгы татар әдәбияты булмаган, бәлки борынгы төрки гомуми бер әдәбият кына булып килгән, дип раслый. Ул анда Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» һәм «Шура» журналлары хакында яза. Бик әйбәт. Ләкин ул Риза Фәхретдиннең татар галиме һәм әдибе булуы хакында яки аның әсәрләре татар телендә язылган булуы хакында берәр генә сүз булса да әйтәме? Юк!»

Шул рәвешле, Исәнбәт Әхнәф Харисовның 1965 елда фәнни йомгаклау сессиясендә җиткергән тезисларына каршы чыга. Бу дискуссиягә катышып, Исәнбәт кабат «кара исемлек»кә эләгә, аны үз туган республикасында нәшер итүдән туктыйлар.

* * *

1966 елда Нәкый Исәнбәт Алматыга бара. Анда астмадан дәвалана, галимнәр белән дә аралаша. Алматыга киткәнче үк, ул Сәйфи Кудаш белән бергә тыелган язучыларны кире кайтару буенча эш башлаган була, гыйльми советлар үткәрәләр, җирле обкомнарга язалар. Моны рәсми рәвештә түгел, мәдрәсә тәмамлаган, вәзгыятьне эчтән белгән өлкән галимнәр буларак, үз исемнәреннән эшлиләр. Сәйфи Кудашка язган хатында Исәнбәт Казахстанның Фәннәр академиясе милли китапханәсендә булуын һәм казах галимнәре татарларның үз мәдәни тормышларында бинаһая зур роль уйнавын тануларын, татар язучыларының казахчага тәрҗемә ителгән әдәбияты күп булуы һәм китапханәләрдә тәкъдим ителүе турында яза. Монда күргәннәреннән чыгып, ул шундый нәтиҗәгә килә:

«Казахстанда татарлар белән кардәшлек һәм мәдәни мөнәсәбәт дөрес юлга куелган».

Кызганыч, әмма бүген без башка күренеш – оныту, бу хәлләрне истән чыгару белән очрашабыз. 1966 елда Казахстан галимнәре тарихи фактларга каршы бармый, татар язучылары һәм галимнәре мирасын популярлаштыру өстендә эшли.

Исәнбәт алга таба үз хатында «татарлар һәм мишәрләр башкорт язучыларына нәшер ителергә комачаулый, популярлашуларына киртә тудыра» дигән сәер фикер таралуы турында яза. Ул моңа бик гаҗәпләнә һәм, моны кире кагу өчен, нибары Казан типографияләре эшчәнлегенә күз салып, анда басылган китаплар исемлеген күздән үткәрү дә җитә – башкорт язучыларына карата никадәр яхшы мөнәсәбәттә булуыбызны шул да ачыклый, ди. Еш кына бу китаплар беренче тапкыр нәкъ менә бездә басыла. Татар һәм башкорт язучыларына мөрәҗәгать итеп, ул «фәнни хезмәтләрдә ничек моны телгә алырга мөмкин» дип, аптыравын белдерә.

Казахстан һәм Башкортстанны чагыштырып, ул болай дип яза:

«Кайтышлый, мин үз ватаным аша юл тотарга һәм казахлар китапханәсен башкорт китапханәсе белән чагыштырып карарга уйладым».

Кабат бу урында җанисәпкә бәйле нәтиҗәләргә тукталабыз. Исәнбәт монда коточкыч саннар китерә. Башкорт каталогында үзенең пьесалары һәм берничә кыршылып беткән китабыннан башка берни дә булмавын билгеләп үтә. Башкорт мәдәнияте үсешенә гаять зур өлеш керткән кеше буларак, моңа бик хәтере кала. Ул – Габдрахман Сәгъди белән берлектә беренче әлифба, мәктәп әдәбиятын төзегән кеше. Бу үзе үк толерантлык түгелмени?!

«Без – ике тугандаш халык, безгә казахлардан үрнәк алырга кирәк! Анда халыклар дуслыгы саклана», – ди ул. Игътибар итегез әле, Исәнбәт идеология формулалар белән ничек оста уйный! Берничек бәйләнеп булмый! «Бу күренеш милли сәясәткә каршы килә» дип, Ленин, Сталиннан цитаталар китерә һәм сорау куя: «Ни өчен соң соңгы дистә елларда бер генә татар китабы да чыкмый?»

Нәкый Исәнбәт үрнәге безне рухландырсын иде. Академик галим, рәсми танылмаган килеш, үзенең тормышын куркыныч астына куеп, (ә ул вакытта психлар йортына озатулары да бик мөмкин!), чирле килеш юлга кузгала. Ә кайткач, Язучылар берлеге һәм обком белән бил алыша. Соңыннан безнең обком җитәкчесе Исәнбәтне үзенә чакырта һәм әйтә: «Мин гаепле түгел. Синең хезмәттәшләрең – драматурглар әләкләште. Мин бит гап-гади экономист. Хөрмәтле язучылар нәрсә әзерләп китергән, мин шуңа кул гына куйдым».

Әлеге беркетмәне кабат бастырып чыгардым. Иң беренче аны Х.Хәмитов нәшер иткән иде. Бу басма кемнәрнең Исәнбәт яклы булганын ачык күрсәтә.

«Үз мәдәниятебезне яктырткан һәм аңа кагылышлы сорауларны күтәргән өчен генә, ничек безне берәмләп юкка чыгарып була? Бүген минем артымнан килгәннәр икән, иртәгә сезнең арттан килачәкләр». Исәнбәтнең бу кыю гыйбарәсе дә игътибарга лаек.

Әлбәттә, обком Исәнбәтнең ният-максатлары турында белгәндер һәм галимнән файдалангандыр. Чөнки Исәнбәтнең улы Татарстанның мәдәният министры булып торган. Булат Гыйззәтуллин әтисен бу сәфәрдә озата барган. Кайчандыр Идегәйдән файдаланган шикелле, обком да Исәнбәттән файдалана: башта заказ бирә; үзе, кирәк була калса, дип артка чигенә һәм аннан: «Соң, бу Исәнбәт бит инде! Партиясез, эшсез! Ул үзе гаепле! Хыялый!» – дип бәя бирә.

Ә җиңү килгәндә, ия вә хуҗалар күбәя. Бу адымга барырга кирәк булганда, бер Исәнбәт кенә кузгала. Бу тарихны белүчеләр бар, әмма дәшмиләр.

Обком карарыннан соң, Исәнбәтне яһүд зыялылары яклап чыга: «Әсәрдәге геройның бер репликасы өчен кешене панисламчылыкта гаепләү – гөнаһ булыр», – диләр. Шулай ук, игътибар итегез: Исәнбәт үзенең фәнни хезмәтләре өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән. Бүген Исәнбәтне гаепләргә, башта чыганакларны эзләргә, эзләрне барларга, төбенә төшәргә кирәк.

Хәзер Исәнбәт белән башкорт халкы да горурлана. Фильм төшерергә, аның хезмәтләрен басарга әзерләр, әмма 40 еллык тынлыктан соң, әлегә бер хезмәте генә дөнья күрде. Бүген без «Идегәй»не Исәнбәтнең даһи текст төзүче булуы аркасында укыйбыз. Ул – партия обкомы карарын гамәлдән чыгаруга ирешкән бердәнбер кеше. Шуңа аны ул вакытта да алкышлаганнар, бүген без дә аны алкышларга күмә алабыз.

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,
филология фәннәре кандидаты.

intertat.tatar.

Туган туфрак җылысы

(шул исемдәге автобиографик повестьтан)

(Ахыры. Башы 48 нче санда).

Ул әби алай акылыннан тайпылган кешегә охшамаса да, без – малайлар – буага су коенырга төшкәндә барыбер шикләнеп, ул өй яныннан тизрәк үтеп китәргә тырышабыз. Бәләкәй генә гәүдәле ул әби сирәк-мирәк кенә безгә дә кереп, минем әнкәй белән иплә генә сөйләшеп, чәйләр эчеп утыра торган иде әле. Шулай бер керүендә нишләптер, ул әбекәйнең алъяпкычы бездә онытылып калган. Бәлки ул аны чәй эчкәндә салган булгандыр.

Салкын кыш көне иде. Әткәй белән әнкәй кич мал карарга чыгып киттеләр. Мин өйдә ялгыз калдым. Ул чакта электрның «э» хәрефе дә юк. Өйне матчадагы кадакка эленгән куыклы лампа яктырта. Мичтә шарт-шорт килеп, учак яна. Мин ул чакта укуга кермәгән малай булсам да, әнкәй миңа мичтәге учакка күз-колак булырга кушты.

– Алай-болай утлы күмер идәнгә чәчрәп төшсә, соскы белән алып, кабат мичкә ыргытырсың. Алай эшләргә курыксаң, әнә сулы кисмәк. Янында чүмеч тора. Шуның белән идәнгә төшкән утлы күмергә су сибәрсең, – диде.

Әлегә ул-бу юк. Мичтән җылы бәреп тора. Рәхәт!

Әмма күпмедер вакыттан соң, искитмәле хәл булды: әбинең ишек янындагы чөйдә эленеп торган алъяпкычыннан бер-бер артлы кеше ишарәтле ике аяклы, ике куллы булсалар да, колаклары маймылныкы кебек зур, тәннәрен кәҗәнеке кебек йон баскан җеннәр тезелешеп чыктылар да миңа таба килә башладылар! Мин куркуымнан чырылдап кычкырып җибәрдем, күрмәс өчен кулларым белән битемне капладым, чытырдатып күзләремне йомдым.

Минем тавышны ишетеп, әнкәй йөгереп керде.

– Нәрсә булды, улым? Күлмәгенә ут каптымы әллә? – дип, мине әйләндерә-әйләндерә тикшерә башлады.

– Юк! Ут капмады. Әнә теге алъяпкычтан куркыныч кыяфәтле җеннәр сикереп төштеләр дә кулларын сузып, миңа таба килә башладылар, – дип, булган хәлне сөйләп бирдем.Шуннан соң ул чөйдәге алъяпкычны кискен генә тартып алды да тышка чыгарып ыргытты. Аннан соң кабат өйгә кереп:

– Курыкма, улым! Мин аны «аятел-көрси» укый-укый карга салып таптадым. Бүтән сиңа күренмәсләр! –дип, мине тынычландырды.

Ә алъяпкычны... әнкәй икенче көнне карларын кагып, хуҗасына кертеп тапшырды.

* * *

...Сабан туйлары җитсә, әткәй искә төшә. Минем хәтердә ул урта буйлы, чандыр гәүдәле, кырыс холыклы кеше буларак сеңеп калган(хәзер бик күрәсе килә, сагынганда карар идең, нишләтәсең, үз гомеремдә бер генә мәртәбә дә рәсемгә төшмәгән). Тагын шунысын да яхшы хәтерлим: болай да җиңел сөякле әткәй, атка атланса, егетләр кебек яшәреп, тагын да җитезләнеп китә. Ат дигәндә, ашавын ашамас, йокысын йокламас, мәгәр атын тәрбияләр иде. Авылдагы йөзләгән атның холык-фигылен, нинди нәселдән икәнен белсә, бер минем әткәй генә белгәндер. Әле сугыштан соңгы елларны да, колхоз атлары арасыннан танып:

– Менә, улым, безнең туры биянең нәселе шушы булыр инде, – дия торган иде. Ә туры бия үзе бер тарих...

...1918-1919 еллар булса кирәк, аклар авылыбызның берничә кешесен атлары белән бергә алып китәләр. Өстәвенә кайры тун, башына «мескен» бүрек кигән бу агайлардан үзләрен Бакалыга илттереп куймакчылар, янәсе. Әмәкәйгәме, кайсыдыр бер авылга җиткәч, халыкны куркытыр өчен, атның сыртына пулемет куеп, атарга керешәләр. Гомердә мондый мәхшәрне күрмәгән ат, нишләргә белми, як-якка ыргыла. Аттан биргәк колыны үрле-кырлы сикерә. Колынына карап, безнең бия тагын да ныграк тыпырчына, тибенә башлый. Ат өстеннән пулемет тәгәрәп төшә. Солдатлар як-якка сибеләләр...

– Атыйк моның колынын, – ди ак офицер, берни булмагандай, алтатарын чыгарып.

Аның сүзләре әткәйнең йөрәгенә ук кебек килеп кадала. Безгә җир сөргән, утын ташыган, безнең нәселгә тугрылыклы хезмәт иткән туры биянең колынынмы?! Шулчак ул ак офицерның каршысына барып баса да, дошманына ташланырга торган бөркет кебек, күзләрен төбәп: — Үземне атсаң ат, колынга тиясе булма! – дип кычкыра.

Офицер мыскыллы елмая. Авырлыгын чамаларга теләгән сыман, кулындагы наганын селеккәләп, эре генә кыяфәттә басып тора. Кара син аның кыланышын! Бер дә авыл мужигы димәссең. Куркуның әсәре дә юк. Нәфрәт тулы күзләрен төбәгән дә тотып ашардай булып карап тора. Өйрәтермен мин сине! Менә наган сабы белән авызыңа берне кундырсам, башкача сөйли башлаганыңны сизми дә калырсың, янәсе.

Әткәйнең дә чигенергә исәбе юк. Синең ише калай әтәчләрне күргән бар инде, ди аның кырыс карашы.

Ул үзе дә патша армиясендә хезмәт иткән кеше. Анда да шушы көяз мыек сыман бер поручик аларның теңкәсенә тигән. Русчасы такы-токы булган солдатларга бөтенләй көн юк: ачыктан-ачык мыскыл итә. Юри җыен кара эшне алардан эшләттерә. Иң авыр урынга постка аларны җибәрә. Анысына да түзәр идең, стройда да күрәләтә кимсетә бит, кяфер. Җитмәсә, юкка-барга да сугып җибәрә. Менә монысына ничек түзәсең инде. Нахакка рәнҗетелгән солдатлар, үзара киңәшеп, теге поручикны шундый итеп акылга утырталар – госпитальдә ике ай дәваланганнан соң, ул алпавыт кавемен бөтенләй имениесенә үк кайтарып җибәргәннәр. Ә хәзер, шалишь, энекәш, курку юк сездән. Алай бик әтәчләнсәң, мин дә карап тормам. Кунычтагы кендек тимере синең белән бер тумаган. Тимер кендеккә үрелергә өлгермәсәм, тун җиңендә пычак та бар. Мал суя торган бик зәһәр үткен пычак!

Таза гәүдәле егет арага керә.

– Ваше благородие, калдырыгыз үзен! Мин аларны беләм. Ат дигәндә җанын бирер бу халык, но атын бирмәс!

Офицер, бик зур яхшылык эшләгән кыяфәттә, йомшаргандай итә.

– Ну ладно, Степан, синең хакка. Ә син, такырбаш, кара аны! Икенче тапкыр авызыңны үлчәп ачмасаң, Бакалыга барып җитә алмавың да мөмкин.

«Бакалы дисең инде син, килмешәк. Бакалы синең өчен генә ерак ул. Туры бия белән без аны көнен урап кайткан бар. Төн җитсен әле, тотарсыз минем койрыкны!» – дип, үзенчә план кора минем әти.

Караңгы төшкәч, исерек солдатлар тәгәрәшеп йокыга китәләр. Сакчы гына уяу. Тик ул да чайкалып утыра. «Әһә, озакламый син дә сүнәрсең, болай булгач».

Йончыган сакчы, чыннан да, озакка чыдамый. Ә минем әткәйгә шул гына кирәк тә. Аклардан «истәлеккә» (ничек җаен тапкандыр?) алтатар һәм патроннар алып, җәһәт кенә атына менеп атлана да элдертә генә. Әнисенә сырышып, колыны чаба.

Солдат кайчан да солдат инде. Еллар буе походта йөреп күнегелгән, күрәсең. Тояк тавышы сакчыны уята. Ул шундук тревога күтәрә. Берничәсе әткәйне куа чыгып карый-каравын.

Ләкин алар, куган саен ерагая барган тояк тавышларын ишеткәч, файдасыз эш белән йөрүләрен аңлап, кире борылырга мәҗбүр була. Шулай итеп, тугрылыклы туры биясе аны дошман тырнагыннан коткара. Авылдашларның:

– Абдулла абзый каравылга алтатар белән йөри, аң булыгыз! – дигәннәрен ишеткәнем бар. Булса да булгандыр, нинди генә караңгы төннәрдә дә атына атланып, колхоз икмәген сакларга чыгып китә торган иде ул...

* * *

Без – кесәбездә җилләр уйнап торган малайлар – кич белән клуб ниргәсе астыннан шуышып кача-поса киногa керәбез. Башта идән астына үтәбез. Залга эләгү өчен тагын бер киртә – сәхнә бар. Ә без беләбез: сәхнәнең стена буендагы бер тактасы кадакланмаган. Әкрен генә шул тактаны күтәреп, залга үтәбез һәм беренче рәттә утырган абзыйларның, җиңгиләрнең аяк астына чүмәшәбез. Юк, сеңәбез дисәң дөресрәк булыр. Чөнки киномеханиклар идән тактасы шыгырдаганын ишетсәләр, алгы рәткә килеп, билет тикшерә башлыйлар. Андый хәвеф сизелсә, без тиз генә эскәмия астына чумабыз. Абзыйлар, бигрәк тә җиңгиләр, безнең хәлгә кереп, итәкләрен җәебрәк җибәрә. Киномеханик эскәмия астын карарга үрелә башласа, аларның җавабы әзер:

– Кит, оятсыз! Күлмәк итәген күтәрмәкче буласыңмы әллә? – дип, аларны куып җибәрәләр.

Шуннан соң без эскәмия астыннан чыгып, иркенләп идәнгә утырып, кино карыйбыз. Ул чорда кинофильм дигән сүз безнең телдә юк. «Кино карыйбыз» һәм вәссәлам!

Әгәр башлангыч сыйныфларда укыганда мин күбрәк Галимҗан абыйга ияреп йөрсәм, бишенче-алтынчы сыйныфларда инде без – малайлар – урманга яки болынга җиләккә барганда үзебез күмәкләшеп йөрибез.

Тормыш никадәр генә авыр булмасын, аның күңелле, матур яклары да бар. Бигрәк тә җәй көне әби-апалар белән җиләк, шомырт җыю үзе бер бәйрәм. Шомырт – сыгылмалы, пеше агач. Аның җимешен очына кадәр менеп җыярга була. Сыгылса сыгыла, иллә мәгәр чаган ботагы сыман шартлап сынмый. Без – малайлар аның очына менеп, атынып утыра торган идек. Якынрак үскәне, тагын да эрерәк җимешле булып безне кызыктырып торса, җиргә төшеп тормыйбыз, Тарзан шикелле бер агачтан икенче агачка сикерәбез. Көзгә таба куагын тигәнәк кебек сырып алган чикләвек, гөлҗимеш җыюлар... Кем әйтмешли, исеңә төшсә, исең китәрлек... Миләш белән баланны кышка бүкән-бүкән итеп әзерләп куясың. Аларның да кирәге чыга. Өйдә яки мунча кергәндә башына ис тигән кешене миләш ашатып айнытала. Ә балан бәлешен ел әйләнәсе диярлек пешерәләр. Аның исе бөтен ихатага тарала, урамга ук бәреп чыга. Әнә бит, урамнан үтеп барган Низам абзый да ихатасын себереп йөргән хуҗабикәне:

– Ай-һай Майкамалттәй, бигрәк тәмле бәлеш пешергәнсең, ахры. Исе әллә каян борынны ярып керә, – дип, мактап ала.

Мактаганны кем генә яратмый икән. Маһикамал түтинең дә күңеле эреп, йөзе яктырып китә.

– Һе-һе! Яхшы сүзеңә рәхмәт инде. Низаметдин энем, рәхмәт! Әйдә, авыз итеп чык, алайса. Сугышта сезне бәлеш пешереп сыйлаучы булмагандыр, – ди ул, ихластан елмаеп.

Ватан сугышында танкист булган Низам абый кыстатып тормый, җилкапканы ачып, ихатага үтә. Маһикамал түти, штан бөрмәсенә кыстырган күлмәген, сызганган җиңнәрен төшереп, ачык тәрәзә аша кызына дәшә:

– Сәрмәдия кызым, Низаметдин абыеңны бәлеш белән сыйла әле.

Ә Низам абыйга шул гына кирәк тә инде. Ул буй җиткән кызга кайтканнан бирле күз атып йөри. Кичке уеннарда да гел аның тирәсендә бөтерелә.

Фәтхулла АБДУЛЛИН

Татарстан Фәннәр академиясендә өч көн дәвамында «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбе узды. Дүртенче тапкыр үткән мәктәп быел «Дөньякүләм рухи мәдәният контекстында төрки телле китап» дигән темага багышланган иде. Аны Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үткәрде. Пленар утырыш башында институтның директоры, профессор Ким Миңнуллин һәм Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, профессор Дания Заһидуллина татар халкының китап басу тарихын үз эченә алган чыгышлар ясады.

Татарлар борынгыдан укымышлы булган

Быел Россиядә беренче татар басма китабы дөнья күргәгә 300 ел булды. 1722 елда Әстерханда Петр I Манифесты татар телендә басылып чыга. Халкыбызның беренче наширы булып исә Габделгазиз Бурашев исәпләнә. Ул 1800 елда Казанда беренче басмаханәне оештырган. Анда гарәп һәм татар телләрендә, күбесенчә дини эчтәлекле китаплар бастырыла башлый. Әмма Г.Бурашов 1805 елда нәшрият эшеннән читләштерелә. 1900 елда бертуган Кәримовлар нәшрияты оештырыла. 1904 елда – «Мәгариф», 1907 елда Әхмәдгәрәй Хәсәниләрнең – «Гасыр», 1906 да – «Сабах» нәшриятлары, шул ук елда «Милләт» басмаханәсе нигезләнә. Казан үзәгендә урнашкан бу нәшрият-типографияләр басма продукция белән Идел буе төбәкләрен, Себер, Урта Азия, Төркестанны тәэмин итә.

Танылган галим, китап белгече, академик, беренчеләрдән булып татар китабы тарихын өйрәнүче Әбрар ага Кәримуллин исәпләп чыгарганча, 1801 елдан 1917 еллар аралыгында татар телендә гарәп графикасында 15 мең исемдәге китап нәшер ителгән. Аларның гомуми тиражы 50 миллион белән исәпләнә. Шуннан соң татар китабының тарихын академик өйрәнү Тел, әдәбият һәм сәнгать институты эшчәнлеге белән бәйле. 1920-1940, 1950-1970 еллардагы актив гыйльми эшчәнлек, Татарстан районнарына һәм Россиянең татарлар яшәгән төбәкләренә экспедицияләргә чыгу, эзләнүләр аша институтның мирасханәсе сирәк кульязмалар, басма китаплар, әдәби һәйкәлләрнең фотосурәтләре белән тулыландырыла.

1939 елда латин графикасы Кирилл хәрефләренә алыштырылгач, Г.Тукайның әдәби һәм публицистик мирасын әзерләп китап итеп чыгару турында карар кабул ителә. Ул 1943 елда ике томда басылып чыга.

1950 еллар ахырында халыкка әдәби мирасның бер өлешен кайтару мөмкинлеге барлыкка килә. «Борынгы татар әдәбияты» хрестоматиясе (1963 ел), Казан ханлыгы шагыйре Мөхәммәдьяр җыентыклары, К.Насыйри, Г.Тукай, М.Җәлил һ.б. әсәрләре нәшер ителә. 1980 елларда татар классик әдипләренең күптомлыкларын әзерләү буенча эш башлана. Галимнәрнең ул елларда иң зур казанышы – 1983 елда Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы басылып чыгу. Тыелган язучы-галимнәр арасында Галимҗан Ибраһимов әсәрләре дә дөнья күрә. Язучының 15 томлык академик басмасын чыгару – галимнәр генә түгел, халкыбыз өчен дә горурлык. Тукайның 130 еллыгына шагыйрьнең 6 томлык академик басмасы, «Тукай энциклопедиясе» һәм фундаменталь тикшеренүләр нәтиҗәләре кергән кызыклы берничә басма укучылар кулына ирешә. Институтның фәнни хезмәткәрләр тырышлыгы белән Гаяз Исхакыйның 15 томлык академик басмасын әзерләп нәшер итүе зур вакыйгалардан булуын да хәтерлибез. Алар арасында 70 ел дәвамында тыелган әсәрләр бар. «Зиндан» исә 1991 елда гына дөнья күрде. Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына «Идел Болгарстанының язма һәйкәлләре» дигән китап чыгарылды. Аңа Болгар чорының биш әдәби истәлеге кертелгән. Аның икесе укучыларга беренче тапкыр тәкъдим ителде.

Тарих фәннәре докторы, Наманган дәүләт университеты профессоры Абдулла Рәсүлов (фотода) үзбәк телле басмаларга да татар белгечләре нигез салуы турындагы чыгышы бик күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Галим искәрткәнчә, Үзбәкстанда XX гасыр башында нәшер ителгән көндәлек матбугат татар, төрек һәм гарәп сүзләре катнашмасыннан торган һәм үзбәк теленә җайлашкан телдә нәшер ителгән. Моның сәбәбе исә Үзбәкстанда күп кенә көндәлек матбугат чараларының татарлар тарафыннан нигезләнүе.

Төркестанда төбәк матбугаты һәм типографияләр барлыкка килү тарихы 1869 елдан башлана. Төркестан генерал-губернаторы К.П. фон Кауфман хәрби министр Д.А. Малютинга мөрәҗәгатендә Ташкенттагы генерал-губернаторлыкның матбугат органы сыйфатында «Төркестан хәбәрләре» газетасын чыгаруга, шулай ук Санкт-Петербургтан шушы максатларда типография оештырырга рөхсәт һәм газетаны бастыру өчен Петербургтан полиграфистларны җәлеп итүләрен һәм гарәп шрифтын алып килүләрен сорый. 6–7 айдан соң Ташкентка дөяләрдә (бу вакытта тимер юллар салынмаган була әле) шрифтлар белән хәреф җыючы татар белгечләре – Шаһингәрәй Бикколов, Габделлатыйф Яушев, Гали Биктимеров килеп төшә һәм үзбәк телле беренче басманы нәшер итә. Шул рәвешле, Үзәк Азиядә яңа өлкәгә – полиграфия сәнгате һәм нәшрият эшчәнлегенә нигез салына. 1870 елда «Төркестан хәбәрләре» газетасына кушымта итеп «Туркистон вилоятининг газети» бастырыла башлый

«Төркестан генерал-губернаторы тәрҗемәчесе Шаһимәрдән Ибраһимов һәм канцелярия тәрҗемәчесе Мөхәммәд Чанышев зур энтузиазм белән «Туркистон вилоятининг газети» басмасын оештыруда үз өлешен кертә. 1872 елдан Ш.Ибраһимов газетаның мөхәррире була. 1883 елны М.Чанышев аның редакциясе белән җитәкчелек итә. Абдулла Яушев һәм Мөхәммәд Курмишев та Төркестан генерал-губернаторы канцеляриясендә һәм Төркестан өлкә газетасы редакциясендә машинист булып эшләгән», – дип ачыклады Абдулла Рәсүлов.

1906 елда татар милләтеннән булган Исмәгыйль Абидов тарафыннан Ташкентта «Тәраккый» газетасына нигез сала. Ул 1906 елның 27 июненнән 1906 елның 20 августына кадәр атнасына ике тапкыр чыга. Мәгариф һәм азатлык идеяләрен пропагандалаучы «Тәраккый» газетасы җирле язучылар тарафыннан тәнкыйтьләнә, редакция хезмәткәрләре эзәрлекләнә. «Тәраккый» газетасы 72 көн генә яшәсә дә, Төркестанда милли матбугатны торгызуда мөһим роль уйный.

1917 елгы февраль революциясеннән соң Төркестан җәдитчеләренең татар мәгърифәтчеләре белән нәшрият һәм басмаханәләр өлкәсендәге хезмәттәшлеге яңа дәрәҗәгә күтәрелә. Әхмәд-Зәки Вәлиди, Пулат Солиев, Кәбир Бәкер, Мөхтәр Бәкер һ.б. Төркестандагы иҗтимагый-сәяси процессларда актив катнаша.

Россия ислам институты (Казан) доценты, филология фәннәре кандидаты Резеда Сафиуллина «Гарәп телле татар китабы» дигән темага ясаган чыгышында галим Миркасыйм ага Госмановның татар милләтенең борынгы вакытлардан ук язулы, динле, дәүләтле халык булуы турында әйткән сүзләрен китерде. «Мин халкымның милли йөзен, рухи кыяфәтен билгели торган төп үзенчәлеге дип, иң элек бер сыйфатын әйтер идем. Ул бер сүзгә генә сыеп бетә: Китаплылык. Әйе, китаплы, ягъни язулы булу».

Татарлар төрки халыклар арасында иң беренчеләрдән булып басма Коръәнне дөньяга чыгарган. Голәмалар шурасы фикере буенча ислам дөньясында Коръән бастыру катгый тыелган булган.

Төрки халыкларның язма тарихы Күлтәгин язмаларыннан башлана. Борынгы дәүләтләрдә рун язуы белән бергә гарәп язуында да шактый бай мирасыбыз сакланган. XI гасырларда яшәгән төрки язучысы, фәйләсүф һәм дәүләт эшлеклесе Йосыф Баласагуниның «Котадгу белег» әхлакый-дидактик поэмасы – ерак гасырлардан безнең көннәргә килеп җиткән мирас.

Әйе, татарлар борынгыдан белемле халык булган. Зыялы гаиләләрдә, гыйлемне гарәп телендә язылган дәреслекләр аша үзләштерсәләр дә, әдәби әсәрләр белән фарсы телле китаплардан танышканнар. Чөнки элек-электән шигърият фарсы телендә иҗат ителгән. Әниләр балаларын кич белән йокларга яткырганда, Руми, Алишер Навои кебек фарсы шагыйрьләренең шигырьләрен укыган. Алтын Урда чорындагы мәдрәсәләрдә шәкертләрнең кулларында гарәп телендә язылган китаплар булган. Казан ханлыгы чорында, мәркәзебезне шагыйрьләр каласы дип йөртүләре дә мәгълүм. Хан сараенда фарсы, гарәп шагыйрьләре белән бергә, үз шагыйрьләребез дә сынау тоткан. Ханлык җимерелгәннән соң да, китапчылык юкка чыкмаган, мөселман укымышлылары әкренләп бер тирәгә тупланган. Монда әйдәүче көч булып суфи шәехләре торган.

XIX гасырда Казанда яшәгән олуг галим һәм этнограф, Казан император университеты ректоры Карл Фукс татарлар арасында наданлык бик сирәк күренеш булуын язып калдырган. Аның «Халык европалыларга караганда да укымышлырак. Татарлар укый һәм яза белмәгән әмматтәшләренә, мөселманлыкларына карамастан, җирәнеп караган», – дигән сүзләре теркәлеп калган. Хәтта православие галиме, миссионер Петр Знаменский да татар хатын-кызларының укый-яза белүенә исе киткән. Халык арасында гарәп телле китаплар аша гыйлем таратуда авылларда яшәүче суфи муллалар, имамнар күп көч куйган. XVIII гасырда Россия патшабикәсе Екатерина II Казанга килеп, татарларга мәчетләр салырга рөхсәт биргәннән соң, татар халкы арасында, гомумән, рухи яңару башланган.

Фәнни мәктәптә Үзбәкстан, Азәрбайҗан республикаларыннан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа шәһәрләренең югары уку йортлары, Татарстан Фәннәр академиясе, республиканың фәнни һәм фәнни-мәгариф учреждениеләре галимнәре катнашты. Пленар утырышта күтәрелгән мәсьәләләр турында тулырак фикерләшү кульязма мираска багышланган секция утырышында дәвам итте. Яшьләр чыганаклар буенча эшләү дәресләрен алды, сәнгать белеме һәм археография өлкәсендә Казанда, шулай ук Россия һәм чит илләрдә яшәүче галимнәрнең лекцияләрен тыңлады, семинарларда фикер алышты.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Нуриманда – Актаныш авыллары

● Сугыш ветераны Ришат Исмәгыйлов Брест крепостеның каһарманлыгын иң беренче булып дөньяга яңгыраткан әдип С.Смирнов белән. 1957 ел.

Башкортстанга чираттагы сәфәргә чыкканда ук Актаныш җирлегеннән андагы районнарга 1860 елларда күченгән татар авылларын күрүне максат иткән идек. Мин фәкыйрегез, үземнең туган авылым Иске Байсардан иллеләп гаиләнең нәкъ шул елларда Яңавыл районы җирләренә күченеп, андагы Биз елгасы буенда Байсар исемендәге яңа бер авыл нигезләве турында ярты ел элек язган идем инде.

● Без Байкилде лицеенда. Уртада күзлек кигәне – С.Исмәгыйлов.

Язмамны башлаганда, өстәмә дәлил булсын дип, безнең Актаныш җирлегеннән ут күршебездәге Илеш, Бакалы, Чакмагыш, Бүздәк, Яңавыл, Краснокама, Калтасы, Тәтешле районнарына төрле елларда күченгән 45 кә якын авылның исемнәрен дә санап чыктым. Боларга өстәп, соңгы бер-ике айда тарихчы галим Таһир Кәримовның Бүләр волосте тарихына багышлап язган, әмма, ни үкенеч, фәнни вә тарихи институтлар гамьсезлеге нәтиҗәсендә бүгенгәчә дөнья күрми яткан кульязма белән танышу мин бичарагызны тагын да ныграк «чир»гә сабыштырды. Таһир әфәнде санаган мәгълүматлар аша актанышлыларның безгә терәлеп урнашкан районнарга гына түгел, хәтта бүгенге күзлектән караганда да «җиде дәрья аръягында» яткан Ярмәкәй, Нуриман, Иглин, хәтта Мәчетле районнарына кадәр күченеп, аларда да өр-яңа авыллар нигезләп гомер итә башлауларын белдем. Элекке якташлар белән туганлык җепләрен яңартмыйча яшәү олы битарафлык булыр иде, менә шул сәбәпле ноябрь аенда ясаган сәфәрдә дә «дилбегә»не иң беренче чиратта кичәге актанышлылар тарафына бордык.

Безне Нуриман районының үзәк китапханә мөдире Эльвира ханым Шәйхелисламова район чигенә үк килеп каршы алды. Сәфәр максатыбыз белән танышуга ук, юл читенә терәлеп торган Байкилде авыл лицеена алып керде. Әүвәл мондый борылышны аптырабрак кабул иткән идек, лицей музеена аяк баскач, бары да аңлашылды. Байкилде белән аның күршесендәге Бикморза һәм Теңкәш авылларында да бер төркеме – 260, икенчесе 160 ел элек күчеп килгән актанышлылар гомер итә, әлеге салаларның әйдәманнары да безнең якташлар икән!..

Вакыйгалар эчендә буталып бетмәс өчен, аларны аерым-аерым чылбырларга тезик. Без туктаган Байкилде лицее аның тәүге директоры Ришат Исмәгыйлов исемен йөртә. Ул Бөек Ватан сугышы башланган 22 июнь таңында соңрак дөньякүләм дан алган, Брест крепосте гарнизонында рацияче булып хезмәт иткән. Немец фашистларына берничә тәүлек каршылык күрсәткәннән соң, гарнизон башлыгы, миләттәше майор Петр Гаврилов Р.Исмәгыйлов белән тагын ике солдатка дошман чылбырын өзеп чыгу һәм совет командованиесенә крепостьның аяныч хәлдә калуын аңлату турында фәрман бирә. Егетләр чыннан да дошман камалышыннан чыгуга һәм составына үз полклары да кергән 42 нче укчы дивизия командиры Лазаренконы табып рапорт бирүгә ирешә, шушы батырлыгы өчен Ришат әфәнде II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә. Әмма егетнең әле сугыш тулысынча тәмамланганнан соң да Брест крепостеның каһарманлыгы турында сыңар сүз белән дә искә алмаулары өчен җаны телгәләнә. Үзәк матбугат журналисты, әдип С.Смирновның Брест крепосте белән аеруча ныклап төпченүе турында ишетеп, аның белән очрашуга бара һәм сугышның тәүге көннәре турындагы хакыйкатьне ачып сала. Смирнов тиз арада Брест крепосте турында китап нәшер итә, һәм шуннан соң гына 32 тәүлек буена дошманга бирелмәгән крепость гарнизоны данга күмелә.

Сугыштан әйләнеп кайтканнан соң, 40 ел буена Ришат әфәнде Байкилде мәктәбен җитәкли, аны балаларга урта белем генә түгел, э гомерлек һөнәр дә биреп чыгара торган уку йортына әйләндерә. Безнең өчен күренекле булган шагыйрьләрдән Зиннур Насыйбуллин белән Халисә Мөдәррисова да шушында белем ала. 1985 елда Ришат Исмәгыйлов мәктәп коллективын улы Салаватка калдыра. Ришат әфәндене республикакүләм абруен ассызыклау өчен бер генә дәлил китерү дә җитәдер. 2010 елда аның 90 еллыгын билгеләп үткән чакта, республиканың мәгариф лидерлары һәм дистәләгән туганнары, оныклары гына түгел, Башкортстанның халык шагыйре Марат Кәримов һәм татарпәрвәр филология фәннәре докторы, язучы Рәиф Әмиров та килә. Ришат әфәнде үзе 100 яшенә җитеп, әле ике ел элек кенә вафат була... Шунысын да өстәми мөмкин түгел: аның улы Салават кебек мәктәп директорын көндез чыра яндырып эзләсәң дә табуы бик кыен. Аяклы энциклопедия! Кулында нәселенең өч гасырлык шәҗәрәсе, туган як авыллары, хәтта бабалары әүвәл гомер иткән Актаныш салаларының тарихы – һәммәсе бар!..

Менә шул Салават әфәнде туплаган мәгълүматлар буенча, ерак-ерак тарихка да чумыйк. Аларның нәсел учагы Актаныш туфрагыннан ук башлана. Хәзерге Яңа Кормаш авылы урынында, Шәбез елгасы буенда элек шактый сирәк исемдәге Җизмыек авылы яшәп яткан була. Шундагы халыкның бер өлеше, имана җире җитмәгәнгә, аннан да яманрагы – мәчет төзергә дә хокукы калмаганга күрә, алдан ук сөйләшеп, Өфе каласы аръягындагы Кызылъяр авылы янына күчеп китә. Күчмәннәрне Бикбай Бикбау улы атлы әйдәман җитәкли. Аның «отряд»ында үзенең Исмак (Исмәгыйль), Мөслим һәм Әбзән атлы өч туганыннан тыш, Казанбай Исәкәев, Габдулла Ибраев, Күчәрбай Чүрәбаев, Тәкәнә Тутбаев, Сөендек Уразаев, Төкәй Бигатев, Әхмәт Әхмәтов, Үтәкәй Алексеев (?), ... Сәетов кебек крестьяннар да була. 1763 елның 15 сентябрендә аларны Себер юлындагы Бүләкәй-Кәзәй волосте старшинасы Әсәнов һәм Кәргенбаш авылының Мәсгуть Теләнчеев җитәкчелегендәге вотчинниклары каршы ала. Тиешле түләү-бүләкләрне бирешкәннән соң, күчмәннәрне үз волостьларына кертү һәм имана җире белән бергә күл, урман һәм печәнлек яланнар бирү турында килешү төзиләр. Аңа Ногай һәм Себер юлларының Кәргенбаш, Сәвәләй, Ярмәш, Шыгай, Чураш авылларының старшиналары Мәсгуть Теләнчеев, Сөярмәт Сөярхуҗин, Габдулла Сәлимов, Шаһмәмәт Рәсүлев, Хәсән Муллакаев, мулла Мөрсәлим Хансөяров, сәркәтиб Буранчы Туктаров кул куя. Шуннан соң күчмәннәр әле 1651 елда ук тарихка кергән Байкилде һәм Бикморза авылларындагы татар санын ишәйтә. Бер өлеше тарихи документларда тәүге тапкыр 1683 елда искә алынган Кызылъяр авылына өстәлеп утыра. Дөрес, ул чагында Кызылъярны әле «Чабаклы» дип кенә йөртәләр, ул «татар үзәге» атлы данны соңрак кына яулый.

Ә күчмәннәр калдырып киткән Җизмыек авылы тагын 60-70 ел буена барешмичә гомер итә әле. Бу авылдан 62 крестьян Пугачев явында катнаша. 1795 елда 5 нче ревизия вакытында Җизмыектагы 32 йортта 108 ир-ат белән 98 хатын-кыз исәпкә алына, аларның күпчелеге – типтәр, 16 кеше генә мишәр булып языла. Ни үкенеч, XIX гасыр башында Җизмыек юк була, 1850 елларда аның урынында Яңа Кормаш авылы калкып чыга...

Кабат Нуриман районына, Бикбай бабай нәселенә кайтыйк. Бикбай үзенең энекәше Әбзән белән бергә Байкилде авылын аякка бастыру өчен көч сала да 1795 елда дөнья куя. Әбзәннең улы Гаделша 1798 елда төзелгән Башкорт гаскәре составындагы типтәр полкының йөзбашы булуга ирешә, 1812 елда Наполеон явына каршы башланган Ватан сугышында прапорщик һәм поручик дәрәҗәләренә, ике көмеш медаль белән бүләкләнүгә лаек була. 1825 елның 3 декабрендә ул үзе һәм аның өч улы Оренбург губернасының дворяннар җыелышы тарафыннан дворяннар сафына кабул ителә... Билгеле ки, бу төбәк крестьяннары 1774 ел язында Нуриман районы аша да шаулап үткән Е.Пугачев җитәкчелендәге азатлык явыннан да качып калмый. Уфа провинциясе буенча 1775 елның 16 февралендә төзелгән рапорт буенча, бу төбәктә старшина А.Бикмәтевкә буйсынган татар һәм марилардан Байкилде авылы – 80, Нимесләр – 47, Үгәрле – 26, Үктәй – 19, Җангали – 27, Үсәбаш – 77, Шиде белән Бөдәй авыллары 58 әр крестьянны Пугачев армиясенә казак итеп бирә... Инде соңрак кузгалган яуларны да телгә алсак, Граждан-

Мосафир сәфәрдән кайтты

● Р.Исмәгыйловның (уртада, кулына таяк тоткан) Байкилде мәктәбендә үткәрелгән 90 яшьлек юбилееннан бер күренеш.

● Без Кызылъяр район китапханәсендә.

нар сугышы вакытында Нуриман районы аша М.Фрунзе белән В.Блюхер армияләре дә, атаклы В.Чапаев дивизиясе дә туфан туздырып уза. 1918 елның 5 июнендә Агыйдел елгасын Кызылъяр авылы янында кичеп, чапаевчылар Уфа каласын акгвардиячеләрдән азат итә, әмма нәкъ шул вакытта фетнә кузгатып, Себер һәм Уралны ак чех әсирләре үз кулына ала. Акларга каршы көрәшеп йөргән крестьяннарга, партизан отрядына берләшеп, Иглин һәм Кызылъяр арасындагы урманнарга кереп качарга туры килә. Өч ай буе шулай качып яткач, партизаннар отряды В.Блюхер армиясенең Белорецк каласын ак чехлардан азат итүе турында ишетеп ала. Аның белән элемтә урнаштыру өчен Байкилде авылыннан партизаннар отрядына килеп кушылган 17 яшьлек Гайнетдин Әхмәтҗановны озаталар. Гайнетдин командарм Блюхерны Менҗитәр авылында эзләп таба һәм хәвефсез юллар аша кызыл полкларны туган ягына алып килә башлый. Гайнетдин юлда йөргән арада, август ахырында, партизаннар Кызылъяр авылын үз кулына төшерә, акларның вак-төяк отрядлары белән утлы бәрелешләр өч тәүлек буе дәвам итә. Дүртенче көнне таңда ук партизаннар елга аша күпер төзеп куя, ул әзер булуга ике меңнән артык арбалы кәрванны елганың икенче ягына чыгаралар. Гайнетдин Блюхер полкларын Яңа Күл авылы янына алып кайтып җиткерә. 29 августта берләштерелгән кызыл гаскәр Байкилде һәм Бикморза авылларына туплана. Мулла Насибулла Мостафин йортын штаб итеп, төн буе анда киңәшмә уздыралар. 3 сентябрьдә Илек авылы янында акларның куәтле гаскәре белән канлы бәрелеш була. Аклар Себер ягына чигенә, Уфа каласы янә хәвефтән азат ителә... Гражданнар сугышы турында бәян итү модадан төшеп калса да, бу төбәк татарлары кичергән хәвефле вакыйгалар, барыбер, гыйбрәт бит ул...

Хәзер район үзәге булуга ирешсә дә, күршедәге Кызылъяр авылы XVIII-XIX гасырларда нык үскән һәм данлы сала булып танылмаган әле. Әлеге Кызылъярның ким дигәндә яртысын Актаныш җирлегеннән күченгән халык тәшкил итә, дисәң дә, һичбер арттыру юк. Анда безне, китапханә тулып, якташлар каршы алды. Татар һәм башкорт дөньясында танылган Халисә Мөдәррисова да шунда гомер итә бит. Ул инде әллә кайчан ук актанышлы якташлары белән бергә нәсел шәҗәрәсен дә төзеп куйган икән. Без китапханә белән танышып чыгуга ук, алдыбызга озынлыгы 8 метрга җиткән шәҗәрәне сузып салды. Бабасы ягыннан чыгышлары – Актанышның Җияш, ә әнкәсе – элек Актаныштагы Бүләр волосте, аннары Илеш районына күчкән Кадер авылыннан! Бабалары 7 гаилә булып, Акай-Килмәк фетнәсендә катнашкан өчен, карательләрнең үч алуыннан куркып һәм 1742 елда Казан өязендәге 536 мәчетнең 418 ен поп вә солдатлар вәйран итүен күреп, хәзерге Кызылъяр калыккан урынга күчеп килгән. Шушы 7 күчмән гаилә төзегән яңа йортлар Кызылъярдагы иң тәүге урамнарның берсе булган.

Кызылъяр авылы 1859-1860 елларда янә Актаныш районыннан күченгән халык исәбенә кинәт үсеп киткән. Саннарга гына игътибар итегез, хәтта ышанмаслык!

1859 ел – Аеш авылындагы 36 хуҗалыктан 173 татар күчеп килә. Шәбез авылыннан 411 «башкорт» һәм 10 типтәр бирегә килеп урнаша. Әнәктән Мөхәммәтша Баязитов, Габделвәли Мәгъсутов, Габделмалик һәм Мөхәммәтлатыйф Габделвәлиев гаиләләре шушында күчеп төпләнә. Илтимер авылындагы Мөхәммәтгали Бикбауов, Габделлатыйф Ишкилдин, Габдулла Әрдәширов, Шәмсетдин Әиткулов, Фәтхулла Җомангулов, Вәлит Рәмгулов, бертуган Камалетдин һәм Сәйфетдин Сәеткулов гаиләләре бирегә күчеп килә. Бүген Мөслим районында исәпләнүче Исәнсеф авылыннан 129 ир-ат белән 109 хатын-кыз 1860 елда Кызылъярга килеп өстәлә. Шул ук елда Пучы авылыннан 3 гаилә күчеп утыра. Түке авылыннан шушы Кызылъярга – 9, күршедәге Кече Шидәгә – 2, Кырмыскалы районындагы Сарт-Чишмә авылына 88 гаилә күченә. Качкын авылындагы 28 кеше – Кызылъярга, 36 кеше Кырмыскалы районындагы Сарт-Нәүрүз авылына килеп өстәлә. Усы авылыннан 38 кеше Кызылъярны, 46 кеше Сарт-Чишмәне баета. Карач авылы 1860 елда Кызылъяр халкын 14 йорттагы 61 кеше белән арттыра... Әле болары да йомгак ясардай төгәл саннар түгел, чөнки Гәрәй белән Йәнәй һәм Байлар волостьларыннан ничә дистә яки ничә йөз гаилә күченгән булу ачыкланып бетмәгән. Мондый массакүләм күченүнең сере бик тирәндә түгел. 1855 елда элек Башкорт гаскәре сафында исәпләнүче барча башкорт, мишәр, типтәр, татар, хәтта мари крестьяннарын да, тулаем рәвештә, фәкать «башкорт яугирләре» дип кенә игълан итәләр, әмма озак та үтми, элек башкорт хәрбиләре булып исәпләнгән 300 мең крестьянның 200 меңе гаскәр составыннан чыгарыла. «Башкорт катламы»на язылган крестьяннарга имана җире 40 ар дисәтинә итеп бүленгән замана бит. Актаныш районындагы Бүләр, Гәрәй, Йәнәй, Кыргыз волостьларында «башкорт катламы»на язылып яшәгән татар крестьяннары 40 ар дисәтинәле имана җирен югалтмау һәм иркенләп яшәү хыялы белән хәзерге Нуриман, Кырмыскалы, Иглин, Ярмәкәй районнарына күченергә мәҗбүр була...

Әлеге Нуриман җирлеге 1812 елгы Ватан сугышына әүвәл Беренче, аннары берничә айдан соң Өченче типтәр полкы туплап озата (Икенче типтәр полкын Актаныш районындагы Бүләр волосте авыллары туплый). Беренче типтәр полкы Наполеонга каршы яуда әүвәл генерал Н.Тучков, аннары генерал М.Платов корпусы составында сугыша... 1942 елда 112 нче номерлы Башкорт дивизиясе туплау башлангач, янә шушы төбәктән ничәмә-ничә эскадрон аның сафына баса. Әмма кайсы гына Ватан сугышын телгә алмасыннар, Наполеонга каршы «чип-чиста» башкорт полклары гына яу йөргән дә, 1943 елда «чиста» башкорт дивизиясе генә дан казанган, имеш. Шушы кадәр кан коеп та абруең булмасын, һаман өченче сортлы халык урынына кимсетелеп яшә, адәм тәганәсе!.. Ә шул ук вакытта Нуриман районы халкы Кызылъяр авылыннан чыккан Гыймай Шәйхетдинов һәм шуның күршесендәге Чураш авылында үскән Гайфетдин Аскин атлы татар егетләренең Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булулары белән горурланудан туктамый. Гаҗәп сәер бизмән!..

Бүген Нуриман районында 19 меңнән артык кеше исәпләнә, авыллар 13 җирле идарәгә бүленгән. Район үзәге булган Кызылъярдагы халык 5 мең хисабына якынаеп килә. Ачылып киткән чакта хуҗалар: «Иске һәм Яңа Күл авылларында гына башкортлар яши, калганының барысында да күпчелек халык – татар», – дип җанга җылы өрә. Әмма җанисәптә татарларны – 46, башкорт халкын 38 процент, дип күрсәтәләр. Ике төрле бизмән яшәвен дәвам итә.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.



● Байкилде авылында 1795 елда язылган җанисәп хисабының беренче бите.

● Х.Мөдәррисова тәкъдим иткән 8 метрлы шәҗәрә.

Хан нәселен сайлаган космонавт

Мәскәүнең Космонавтика музеенда каһарман космонавтыбызга 80 яшь тулу уңаеннан ачылган «Джанибеков эффекты» күргәзмәсе эшли. СССРның очучы-космонавты, ике тапкыр Советлар Союзы Герое, җәмәгать эшлеклесе, рәссам В.Джанибеков үзенең «Кешелекнең йолдызлы балачагы» (Ике дөнья очрашуы) картинасында Ю.Гагаринның Җиргә төшкән көнен һәм аны бирәдә беренче булып каршы алган татарлар – Әнихәят Тахтарованы һәм аның оныгы Румияне сурәтләгән. Әлеге картина – диптих өлеше. Диптихның икенче өлеше – «Гагарин старт алдыннан» картинасы. Күргәзмә күрке бу әсәр 1988 елда иҗат ителгән.

● **Очучы-космонавт В.Джанибеков һәм Румия Нурсканова.**

Тугыз тематик өлештән торган зур күргәзмәдә – шәхси әйберләр, документлар, уникаль фотолар, махсус костюмнар, очучы-космонавтның орден-медальләре, 20 ләп әсәре... Халык күргәзмәне ошатып карый.

Булачак космонавт 1942 ел хәзерге Үзбәкстанның Ташкент өлкәсе Бостанлык районына кергән Искәндәр бистәсендә офицер гаиләсендә туган. Әтисе Александр Крысин янгыннан саклау органнарында төрле вазыйфалар башкарган, әнисе Евдокия хирургия бүлегендә шәфкать туташы булып эшләгән. Балага гаиләдә моннан алданрак кына үлгән ир баланың исемен кушканнар. Әмма әбиләр: «Юкка болай эшләдегез, хәзер аңа инде ике кеше тормышын яшәргә туры киләчәк», – диешкән. Балачакта Владимир дусты Валентин Рзянин йогынтысында рәсемнәр ясый башлаган. Ә инде Суворов училищесында укыганда, китапханәдән В.Цесевичның «Что и как наблюдать на небе» дигән китабын алган. Китап арыктагы суга төшеп чылангач, әнисе белән аның бар битләрен үтүкләп киптерсә дә, китапханәче аны кире кабул итмәгән. Яшүсмер әлеге басманы кат-кат укыган. Әнисе улына: «Улым, үскәч кем булырга телисең?» – дигәч тә, «Мин астролетчик булачакмын!» – дип җаваплаган.

Яшьлегендә ул Лилия Джанибекова белән танышкан. Ә бу кыз Алтын Урда ханы Үзбәкнең өченче улы – Җанибәк хан (1342-1357) нәселеннән. Аның әтисе Мөнирнең ир балалары булмаганга күрә, ул нәселдәге соңгы ир-ат булуын бик авыр кичергән. Ата кеше 1956 елны вафат булган. 1964 елны Владимир Александрович, үз әти-әнисенең ризалыгын алып, җәмәгате фамилиясен кабул иткән. Алар гаиләдә ике кыз бала үстергән. Кызлары Инна – биолог, биология фәннәре кандидаты, ә Ольга – рәссам-дизайнер. Хәзерге көндә исә космонавт Татьяна Геворкян белән гомер кичерә. Татьяна Алексеевна – тарихчы, Мәскәүдәге Космонавтика мемориаль музееның фәнни-экспозиция бүлеге җитәкчесе.

1953-1960 елларда Суворов училищесында хәтта сәнгать, рәсем, скульптура дәресләре дә укытылганга күрә, Владимир бу өлкәләрдә дә калышмаган, бик яхшы укыган, инглиз телен өйрәнгән, дәрәҗәле спортчы булган. Укуын алтын медальгә тәмамлагач, Ленинград дәүләт университетының физика факультетында белем ала башлаган. Тик беренче сессиядән соң, университеттан киткән. Хәрби очучы булу теләге белән янган. 1961-1965 елларда ул Ейсктагы югары хәрби-авиация училищесында белем алган. Әлеге училище инкыйлабка кадәрге хәрби-диңгез училищесы нигезендә ачылган һәм аның китапханәсендә сынлы сәнгать буенча да күп китап тупланган. Сәләтле егет аларның күбесе белән шунда танышкан. Ул шушы училищеда да, ә соңрак космонавтлар отрядында да рәссам-бизәүче вазыйфаларын бик теләп башкарачак әле.

Укудан соң Владимир Александрович СССР Хәрби-Һава Көчләрендә очучы-инструктор булып хезмәт итә. Һәм 1969 елда космонавтлар отряды өчен сайлап алына. Мәгълүм ки, тәүге очышларын кайбер космонавтлар озак еллар көтә. Ул да космоска кайчан очачагын алдан белмәгән, әлбәттә. Соңрак аннан еш кына: «Галәмне беренче тапкыр күрү мәлен хәтерлисезме?» – дип сораячаклар. «Космоста таңнар ату – ул тормышка гимн белән тәңгәл. Галәмдәге иң гаҗәеп һәм иң матур күренеш – ул Кояш чыгышы! Космоста бу мәл Җиргә караганда тизрәк бара, һәм әлеге күренеш фантастик төсләр белән бәйле. Ләкин иллюминатор янында озак утырып булмый, Кояш искиткеч нык кыздыра башлый...», – дип җавап бирә космонавт.

Владимир Джанибеков галәмгә 5 тапкыр оча: 1978, 1981, 1982, 1984 һәм 1985 елларда. Һәр очыш саен аны экипаж командиры итеп билгелиләр. Ә бу факт – дөнья рекорды. Әлеге рекордны узган башка космонавт юк. Гомумән, В.Джанибеков планетабызның төпле белемле, кризис хәлләрдә мәсьәләләрне стандарт булмаган рәвештә чишә алган космонавтларның берсе. 1981 елны ул – Монголиянең беренче космонавты Ж.Гуррагча белән, ә 1982 елда космонавт А.Иванченков һәм Франциянең беренче космонавты Жан-Лу Кретьен белән бергәләп космоска күтәрелде. 1982 елгы очыш вакытында, «Союз Т-6» космик корабле «Салют-7» станциясенә тоташыр алдыннан ара 900 метр калгач, штаттан тыш хәл килеп чыга. Сынауларның берсе шушы була... «Союз Т-6» корабленең якынаю һәм тоташу системасы эшләүдән туктый... Шул чакта В.Джанибеков кыю карар кабул итә, ул кул идарәсенә күчеп, зур осталык белән орбиталь комплексны очып үтә. Һәм станциягә агрегат бүлеге ягыннан тоташа. Бу батырлыкны сүз белән аңлату кыен.

Ә менә дүртенче очышта ул космонавтларыбыз С.Савицкая һәм И.Волк белән бергә була. Һәм бу хакта ул болай дип искә ала: «... Бу очракта ачык Галәмгә беренче тапкыр чыгуым иде һәм, өстәвенә, Җир шарының нибары икенче хатын-кыз космонавты белән берлектә... С.Савицкая, шушы очышында, дөньяда ачык галәмгә чыккан беренче хатын-кыз буларак, ачык космоста универсаль кул инструменты белән тәҗрибә куярга тиеш булды. Барысы да бергә туры килде. Мин аның өчен дә җаваплы идем. Иң авыры кушылу булды. Үзем белән кино һәм телекамералар бар иде. Ачык космоста берничә кадр ясадым... Ә бит шундый чакта галәмгә карап, аның белән дә сокланасы да килә! Иллюминатор аша карау түгел бит инде ул...» В.Джанибеков тарафыннан төшерелгән С.Савицкая фотосы, Галәмдәге иң яхшы фото буларак, соңрак берничә бүләккә дә лаек була!

1985 елгы, бишенче очышы вакытында В.Джанибеков очучы-космонавт Виктор Савиных белән берлектә «Союз Т-13» кораблен тарихта беренче тапкыр тулысынча идарәсез калган егерме тонналык «үле» станциябез белән тоташтырырга тиеш була (Бу бурычны үтәүчеләр уңышсызлык килеп чыккан очракта, һәлак булачакларын алдан ук аңлап очалар). Акрын гына Җиргә таба якынлашкан, үз иркендәге траектория буенча очкан станциябез түбәнәя бара... Димәк, Җирне афәт көтә, безнең илнең идарәсез калган станциясе аркасында Өченче бөтендөнья сугышы башлану куркынычы да бар. Башка дәүләтләр, аеруча да АКШ моны техник һәлакәт килеп чыгу алдында тору дип кабул итә. АКШ үз астронавтларын идарәсез калган «Салют-7» станциясен космостан урлап төшерергә хәзерли башлый, ягъни Кушма Штатлар станцияне кораб эченә урнаштырып, аны үзләренә алып кайтырлык техник очыш башкарырга планлаштыра. Әлеге җитди очышка әзер булган һәм совет станциясен бик тә яхшы белүче ике француз астронавты да тиз арада табыла. Конфликт илебезнең техник серләрен белүне күздә тота. Чөнки АКШ бу өлкәдә артка калып бара. Ә менә әлеге мәсьәләне чишү алымнары безнең космонавтлар тарафыннан Җирдә нибары өч ай гына өйрәнелә. Вакыт тар. Очыш алдыннан Владимир Александрович рас төш күрә, имеш, ул инде станция эчендә һәм аны ремонтлый. Ул бу хакта 2011 елда Роскосмос телестудиясе иҗат иткән «Битва за «Салют». История подвига» документаль фильмда сөйләде. Әлеге фильмда каһарман космонавларыбыз үзләрен искиткеч тыйнак тота. Әйтик, В.Джанибековтан: «Әлеге очышыгызда бик катлаулы хәлләр булган бит...» – дип сорыйлар. Ә ул: «Анда нәрсә катлаулы булсын соң?! Бу – минем

● «Гагарин старт алдыннан». В.Джанибеков эше.

● «Кешелекнең йолдызлы балачагы». В.Джанибеков эше.

һөнәрем! Мине бер вакыт Луганск ир-атлары шахтага алып төшкән иделәр. Миңа анда куркыныч була башлады. Менә алар – чын геройлар. Алар анда ничек эшли, ничек тир түгә...» – дип җавап бирә.

Экипаж ташландык станциябезне Айдан өстәрәк чагында күреп ала. Владимир Александрович, үтә тыныч халәттә калып, бертуктаусыз һәм теләсә ничек бөтерелеп очкан «Салют-7» орбиталь станциясе янында гаять катлаулы маневр ясый. Һәм бары тик кул идарәсе белән иң беренче омтылышта ук «Союз-Т-13»не «үле» станция белән үзара тоташтыра. Җирдәге белгечләр аның гамәлен тын да алмыйча диярлек күзәтә. Җиргә янаган бер афәт юкка чыга.

Станция космонавтларны коточкыч тынлык, дөм караңгылык, боз салкыны һәм эшләүдән туктаган җайланмалары белән каршы ала. Бу шартларда эшләү бик авыр була. Беренчедән, баш, куллар туңа. Алар хәтта йоннан бәйләнгән баш киеме киеп эшләргә мәҗбүр. Икенчедән, ремонттан соң, станция җылына башлауга, аның эче су плёнкасы белән каплана башлый, янгын чыгу куркынычы туа. Алар моны: «Ниндидер могҗизаи рәвештә генә бар да яхшы дәвам итте! Панельләрнең артында – су, аларга суккалагач, аннан су тамчылары чәчрәп чыга иде. Кинәт күбәйгән суны бар булган тукымалар, тастымаллар белән, шунда яткан киемнәрне ертып, сөрттек. Станцияне корыта башладык, әмма чүпрәкләр аз иде...» – дип искә алачаклар. Станция эксплуатацияләнә башлый. Шушы очышта аларга 5 сәгать дәвамында ачык космоста да булып, ремонт эшләрен башкарырга туры килә. Бу очыш дөньядагы бар махсус уку әсбапларына кертелгән инде.

В.Джанибековның авырлык югалу шартларындагы ачышы безгә «Джанибеков эффекты» буларак мәгълүм. Ачыш космонавтыбыз тарафыннан шушы үле станцияне ремонтлаганда ачыкланган. Владимир Джанибеков – җисемнең Космостагы шартларда берникадәр араны очып үткәннән соң, үз күчәрендә 180 градуска борылуын һәм очышын дәвам итүен беренче тапкыр күргән белгеч. Бу шәхси күргәзмә аталышы шушы ачышка барып тоташа. Шушы ахыргы, бишенче очышында да ул, тәҗрибәләр нәтиҗәсендә элиталы, чыдам, яңа мамык сортын да ача әле.

Күпләр 1985 елгы очыш өчен әлеге космонавтлар өченче тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек иде дип саный. Әмма Советлар Союзында ул чакта космонавтларга өченче тапкыр мондый исем бирелми. В.А.Джанибеков үз хезмәтләре өчен ике «Алтын Йолдыз» медале, биш Ленин ордены, «Кызыл Йолдыз» ордены, III дәрәҗә «За службу Родине в Вооруженных силах СССР» ордены, Дуслык орденына ия, аның чит дәүләт бүләкләре дә бихисап! Ташкент үзәгендә һәйкәл-бюсты да урнаштырылган. № 3170 кече планета да аның исеме белән аталган.

Очышлар тәмамлангач, Владимир Александрович үз профессиясендә калып, җаваплы урыннарда дәрәҗәле җитәкче булып эшли, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. 1991-1994 елларда, АКШ-Россия экипажы составында, һава шарларында Җир әйләнә очышларда да була. Ул хәзерге көндә Россия Космонавтика музейлары ассоциациясе президенты вазыйфаларында.

СССР Рәссамнар берлеге сафларындагы В.Джанибеков рәссам Г.Комлев белән берлектә төрле миниатюралар иҗат иткән. 1970-1980 елларда аларның эскизлары буенча космонавтика темасындагы почта маркалары, почта блоклары, конвертлар нәшер ителгән. Ул пейзаж, натюрморт, портретлар остасы буларак та мәгълүм һәм аның графика юнәлешендәге хезмәтләре дә гаять кызыклы! Владимир Александрович бизәгән китаплар да бар. Хөрмәт иясе – гаҗәеп үзенчәлектәге кул сәгате авторы да, 2006 елда аның тарафыннан иҗат ителгән космонавигатор халыкара космик станциясенең шушы мизгелдә Җир шарының кайсы өлеше өстеннән очып баруын күрсәтә. Әлеге сәгатьләр галәмдә сыналган һәм космонавтларга бүләк ителгән. Моннан кала Джанибеков кешенең эчке әгъзалары активлыгын чагылдырган Биоритм сәгатен дә иҗат иткән.

Ул үз әңгәмәләрендә: «Галәмне урап кайткач, кеше үзгәрә. Өстәвенә, Җир шарын тулысы белән әйләнеп чыгу өчен нибары сәгать ярым вакыт сарыф итеп, һәм аны берничә мәртәбә әйләнеп тә чыккач, Җир шарыбызның никадәр кечкенә икәнен бар җаның белән аңлый башлыйсың. Һәм тормышның никадәр үзенчәлекле икәненә тиз төшенәсең. Һәр кешенең, аның җәмгыятьтәге урынына һәм кыен шартларга да карамастан, үзен бәхетле кеше дип санарга тиешлеген аңлый башлыйсың. Кеше үзенең Җирдә яшәве белән һәм үзенә берникадәр вакыт яшәргә һәм шул вакыт эчендә нәрсә дә булса эшләп өлгерергә кирәкле сирәк уңышка ия булуы белән үк бәхетле саналырга тиеш», – ди.

Владимир Джанибековның «Кешелекнең йолдызлы балачагы» (Ике дөнья очрашуы) әсәренә игътибар итсәк, даһи космонавтыбыз Румия Әбдрәшит кызы Нурсканова белән 2011 елда, академик С.П.Королев истәлегенә багышланган XXXV нче академия укулары көннәрендә очрашкан. Озак еллардан соң, Россия Космонавтика ассоциациясе гозере буенча, Румия Нурскановны эзләп тапкан милләттәшебез, әстерханлы Хәсән Туктар улы Кутлалиев 2021 елда түбәндә тасвирланган тарихи вакыйга хакында миңа да җөпләде. Хәсән Туктар улы җәмәгате Р.Сәйфетдинова белән 2011 елның 25-28 гыйнварында, С.П.Королев истәлегенә багышланган XXXV нче академия укуларда да катнашкан. Аның истәлекләре буенча, Румия ханым 27 гыйнварда узган «Космонавтика һәм мәдәният» секциясе утырышына чакырылган. Н.Э.Бауман исемендәге Мәскәү дәүләт техник университетында ачылган зур җыелышта В.А.Джанибеков күп дәрәҗәле затларның исем-фамилияләрен атаган. Вакыйганың әһәмиятен ассызыклап: «Безнең арабызда Рита да бар», – дигән. Хәсән Туктар улы әйтүенчә, зал алкышларга күмелгән. Румия ханым урыныннан торып, барысына да үз рәхмәтләрен белдергән, бераздан аңа да сүз биргәннәр. Залда янә көчле алкышлар яңгыраган. Румия ханым трибунага чыгып, үз тормыш юлы, әбисе Әнихәят белән бергәләп Галәмнән төшкән Юрий Гагаринны ничек итеп күреп алулары, аның белән нәрсә хакында сөйләшүләре турында да сөйләгән.

Рәссам-космонавтның диптихы Румия Әбдрәшит кызының күңеленә хуш килгән. «Кечкенә чакта шушы кызчыкка ошаган идем, мин бит балачакта бераз аксылрак чәчле идем!» – дигән ул.

Мәскәүдәге Космонавтика музее фәнни-экспозиция бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре Павел Каравацкий диптихның шул музейда саклануын һәм даими экспозицияләнүен хәбәр итте.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

● «Джанибеков эффекты» күргәзмәсеннән күренешләр.

Атнаның сәяси мизгелләре

ХАЛЫКАРА ПЛАТФОРМА БУЛДЫРЫЛА

«Зур җиделек» (G7) илләре 12 декабрьдә үткән онлайн очрашуда Украинага финанс ярдәмен координацияләү ниятендә халыкара платформа булдырырга карар кылган. Анда рәислек иткән Алмания канцлеры О.Шольц әйтүенчә, Украинаны торгызу Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Аурупа өчен Маршалл планы кебек үк глобаль мәсьәлә булачак. Ә әлеге G7 онлайн очрашуында Украина президенты В.Зеленский да чыгыш ясаган. Ул анда Украинада тынычлыкны якынайта торган «өч адым»ны атаган: Украинага заманча танклар, ераккарак ата торган реактив артиллерия системалары һәм ракеталар бирү; киләсе елда илнең финанс, энергетика һәм социаль тотрыклылыгына, шулай ук энергетикага ясала торган һөҗүмнәрдән ышанычлы саклауга ярдәм күрсәтү; элегрәк G20 саммитында тәкъдим ителгән һәм 10 пункттан торган «тынычлык формуласы»н үтәү, аны җайга салу өчен Global Peace Formula Summit очрашуын җыю.

Шул ук көнне Брюссельдә ЕС илләре тышкы эшләр министрлары Россиягә каршы санкцияләрнең тугызынчы пакетын үзара килештерү һәм Украинага өстәмә финанс ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен карау өчен җыелган. Тик ике мәсьәләне дә ахырынача хәл итеп бетерә алмаганнар. Тугызынчы пакетта чикләүләр 141 физик зат һәм 47 оешмага каршы кертеләчәк икән. Анда ЕС территориясендә Россиянең берничә телеканалы эшчәнлеген тыю турындагы пункт та булырга мөмкин, имеш. Шул ук вакытта әлеге пакетның атна ахырына кадәр кабул ителү мөмкинлеге турында да әйтелә. Украинага өстәмә финанс ярдәменә килгәндә, ул анда Тынычлыкның Европа фондын 3,5 миллиард еврога киңәйтү юлы белән хәл ителер кебек. ЕС 2023 елда Украинага 18 миллиард евро күләмендә кредит бирү мәсьәләсен дә хәл иткән. В.Зеленский исә телефон аша АКШ президенты Дж.Байден белән сөйләшкән. Ул аннан һава һөҗүменнән саклану (ПВО) чаралары белән ярдәм итүен сораган. Байден Украинаның ПВО системасын ныгытуда Вашингтонның өстенлекне нәрсәләргә бирәчәге турында сөйләгән. Ә АКШ финанс министрлыгы 2023 елда Украинага ярдәм күрсәтү максатында конгресстан 14,5 миллиард доллар күләмендә өстәмә акча сораган.

Узган атнаның игътибарга лаек башка вакыйгалары да җитәрлек: Евразия икътисади берлегенең Бишкәктә үткән саммитында 15 документ имзаланган; Алмания канцлеры О.Шольц В.Путин белән сөйләшүләрне дәвам итү кирәклеген әйткән; сугыш кораллары белән законсыз сәүдә итүдә гаепләнеп, 2012 елда АКШта 25 елга төрмәгә утыртылган һәм узган атнада алыштырып алынган В.Бут ЛДПР партиясенә кергән (ихтимал, тиздән депутат та булып куяр); Косово Европа Берлегенә әгъза булып керүгә гариза биргән; Кремльнең матбугат хезмәте Яңа елга кадәр В.Путинның зур матбугат очрашуы булмый, дип белдергән.

Фоат УРАЗАЙ.

1958 елгы хат

«Җепшеклек» чорында татар язучыларының фикерләре турында хат

Хәзер тәкъдим ителәчәк документ – «Татар язучылары даирәсендә йөргән милләтчел фикерләр турында ябык хат» – 1957-1958 елларда Н.С.Хрущев сәясәтендәге үзгәрешләрне чагылдыра. Бу вакытка «җепшеклек» үзенең иң югары ноктасын уза, әмма совет җәмгыяте әле моны тоймый. 1957 елның июнендә КПСС Үзәк Комитетының мәгълүм пленумында Хрущевны вазыйфасыннан алып ташларга маташалар, әмма бу уңышсыз булып чыга, шулай да оппозиция шактый ташламалар алуга ирешә. 1958 елның гыйнварында ҮКның идеология, мәдәният һәм партиянең халыкара элемтәләре комиссиясе оештырыла – әлеге структура барлык идеология һәм иҗат оешмалары эшчәнлеген үз контролендә тота. Н.Хрущев сәнгать интеллигенциясе вәкилләре белән әледән-әле очрашкалап тора, күргәзмәләргә йөри, иҗат мәсьәләләренә актив тыкшына. Урыннарда да шундый сәясәт алып барыла: партиянең өлкә һәм край комитетлары секретарьларының иҗат берлекләре вәкилләре белән киңәшмәләре нормага әйләнә.

1956 елның июлендә «Советская Россия» газетасы оештырыла, ул атнасына алты тапкыр 1 миллион тираж белән чыга. Редакциясендә 205 кеше эшли, шул исәптән 25 корреспондент өлкә-крайлардан хәбәр җибәрә, алар «үзәкнең» колагы-күзе дә булып тора.

Хәзер тәкъдим ителәчәк «ябык хат»ны «Советская Россия» газетасының ТАССРдагы үз хәбәрчесе язган. Әлеге материалдан күренгәнчә, татар язучылары ул вакытта ук 1990 еллар башында гына хәл ителәчәк мәсьәләләрне тикшергән. Язучылар һәм композиторлар киңәшмәләрне һәм съездларында яңгыраган кайбер фикерләрнең кыюлыгы таң калдыра. Алар күтәргән проблемаларның күбесе әле бүген дә актуальлеген югалтмаган.

Татар язучылары даирәсендә йөргән милләтчел фикерләр турында «Советская Россия» газетасының ТАССРдагы үз хәбәрчесенең баш мөхәррир П.П.Ерофеевка ябык хаты:

● Төрекмәнстанның халык язучысы Берды Кербабаев Татарстан җирендә. Сулдан уңга: Хатип Госман, Мирсәй Әмир, Әмирхан Еники, Берды Кербабаев, Гомәр Бәширов. 1950 еллар ахыры.

«1958 ел, 28 гыйнвар.

Совет власте елларында ТАССРда сәясәт, икътисад һәм мәдәният өлкәләре гаять зур үзгәрешләр кичерә. Республикада 10 театр, консерватория, 12 югары уку йорты, 3,5 меңнән артыграк мәктәп, СССР Фәннәр академиясе филиалы ачыла, 2382 китапханә, 2406 клуб һәм мәдәният сарае эшли. Хәзерге вакытта әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә меңнәрчә кеше хезмәт куя.

Соңгы елларда, бигрәк тә КПССның XX съездыннан соң, иҗат оешмаларының тормышы шактый активлашты. Әмма татар язучыларының кайберләре,«иҗат иреге» турында томанлы сөйләшүләрдән китеп, үзләренең милләтчел характердагы фикерләрен әйтергә җөрьәт итә башлады. Әлеге җәһәттән 1957 елның ноябрендә узган Татарстан иҗат активы җыелышында һәм Язучылар берлеге партия җыелышында, шулай ук язучыларның партия өлкә комитеты секретарьлары белән 1958 елның 18-19 гыйнварында узган очрашуында яңгыраган фикерләргә тукталу урынлы булыр. Аларны тәгәлрәк күзаллау мөмкин булсын өчен, мин әлеге чыгышларда күтәрелгән төп мәсьәләләргә аерым-аерым тукталам.

Социалистик реализм методына һөҗүм. Ел ярым элек республика Язучылар берлегендә үткән җыелышлардан берсендә язучы Әмирхан Еники «иҗат ирегe» таләп итте. Тәнкыйтьче И.Нуруллин исә үз чыгышында С.Хәкимне туган як турындагы оптимистик шигырьләренең ихлас булмавында гаепләде һәм карашын үзгәртергә өндәде. Кайбер язучылар «татар музыкасы язмышы» турында хафалануын күрсәтте. Әле Татарстан композиторларының 1955 елның декабрендә узган икенче съездында ук шагыйрьләр Э.Давыдов, М.Мазунов, М.Хөсәенов һәм филология фәннәре кандидаты Х.Курбатов республиканың әйдәп баручы композиторларын (Н.Җиһанов һ.б.) югары профессиональлеккә омтылуда һәм шуның белән халыктан ераклашуда гаепләгән иде. 1956 елның декабрендә Язучылар берлегенең хисап-сайлау партия җыелышында докладчы Г.Кашшафетдинов (Г.Кашшаф), шагыйрьләр Ш.Маннур һәм Э.Давыдов кабат татар музыкасында бер генә юнәлеш калдыруны даулый башлады – композиторларны примитивлыкка, югары иҗат культурасыннан баш тартуга, милли чикләнгәнлеккә өндәде, татар музыкасын баеткан башка юнәлешләрне исә кискен тәнкыйтьләп чыкты. Тик тормыш әлеге язучылар төркеменең субъектив, нигилистик карашларының дөрес түгеллеген исбатлады. Мәгълүм булганча, 1957 елның маенда Мәскәүдә узган татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы вакытында үзләрендә югары эчтәлекне музыкаль форманың нәфис камиллеге белән берләштергән музыкаль әсәрләр аеруча зур уңыш казанды. Башкала җәмәгатьчелеге Н.Җиһановның «Җәлил» операсын үзенең ихласлыгы һәм югары һөнәрмәндлеге белән сокландырган яхшы музыкасы өчен җылы кабул итте.

Шулай да Язучылар берлегенең 1957 елның ноябрендә үткән хисап-сайлау партия җыелышында Композиторлар берлегенә һөҗүм барыбер тукталмады. Югарыдарак аталган язучылар исә соңгы киңәшмә-җыелышларда инде музыкаль культура язмышын гына түгел, бәлки бөтен татар мәдәнияте, һәм хәтта бөтен татар халкының язмышы турындагы мәсьәләләрне күтәрә. Язучы Әмирхан Еникинең быел 18 гыйнварда партия өлкә комитеты секретарьлары белән очрашудагы чыгышы моңа ачык мисал булып тора.

Ә.Еники: Минем сезгә борчуымны, үземнең генә түгел, бөтен татар интеллигенциясенең хафалануын җиткерәсем килә. Бик зур мәсьәлә калка, аны вакытлыча чаралар белән генә хәл итеп булмаячак. Кардиналь чаралар, сәяси һәм теоретик чаралар кирәк. Бу – татар халкының киләчәге турында мәсьәлә.

С.Д.Игнатьев (партия өлкә комитеты беренче секретаре) репликасы: Нинди мәсьәлә соң бу?

Ә.Еники: Сез ишеттегезме икән, татар телендәге китап тиражлары кими, татар мәктәпләре саны азая, мәктәпләрдә татар әдәбияты сәгатьләре саны кыскара. Бу нидән килеп чыга? Мәгариф министрлыгының начар эшләвеннән түгел бит инде. Мин, татар халкы юкка чыга, димим. Ул яшәячәк һәм иҗат итәчәк, әмма аның мәдәнияте белән нәрсә булыр? Минемчә, соңгы 15-20 елда милли сәясәттә, бигрәк тә практикада, бик күп хилафлыклар ясалды. Мәсәлән, әлифба үзгәртү. Бу милли мәдәниятнең алга баруына этәргеч булдымы? Юк, әлбәттә.

С.Д.Игнатьев: Сезнеңчә, гарәп әлифбасын калдырырга кирәк идеме?

Ә.Еники: Мин алай димим, әмма латин графикасында калу мәслихәт булып, рус хәрефләренә күчәргә кирәк түгел иде!

Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис үз чыгышында район газеталарының рус теленнән татарчага тәрҗемә ителеп чыгаруын кискен тәнкыйтьләде: Районнарда дубляж-газеталар чыгаруны туктату зарур. Мин моны милли кадрларга ышаныч

● «Җепшеклек» чорында Татарстан түрәләре: Фикрәт Табиев алгы рәттә сулдан икенче, дүртенче – Семен Игнатьев, аның артында – Салих Батыев. Фото С.Игнатьевны эштән алган өлкә комитеты пленумыннан соң төшерелгән.

белдермәү, татар халкын мәсхәрәләү дип саныйм. Хәтта инглиз колонизаторлары да моңа кадәр барып җитмәгән.

Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире иптәш Госманов (Хатип Госман) трибунага «ТАССРда халык хуҗалыгы» китабын алып чыкты. Республиканың милләтләр буенча составын укып күрсәткәч (татарлар – 48, руслар – 42 процент, калганы башка милләтләр), ул яшьләрне югары уку йортларына милләт санына нисбәтле рәвештә кабул итү мәсьәләсен күтәрде.

Х.Госманов: Ә чынбарлыкта хәлләр ничек соң? 1956-1957 уку елында укырга кергән 27 мең студентның 8 меңе генә татар (30% чамасы), былтыр кергән 28 мең студентның 9 меңе татар. Әгәр моны республикадагы милләтләр нисбәтенә күчереп исәпләсәң, татар студентлары санының күпкә аз булуы күренә.

Игнатьев: Ә сез Мәскәү, Ленинградта, башка шәһәрләрдә укучы татар яшьләрен исәпкә аласызмы соң?

Госманов: Мин Татарстан турында гына сөйлим.

Иптәш Госмановка, әгәр барлык республикалар да милли кысаларга куып кертелсә нәрсә булачак, дигән сорау бирелде, тик ул җавапсыз калды.

Үз чыгышларында Х.Госман, Ә.Еники, Ә.Фәйзи һ.б. Казанда бөтен илдәге 6 миллионлап татар халкы белән җитәкчелек итү үзәге булдыру мәсьәләсен күтәрде. Игнатьев һәм Батыев иптәшләр әлеге тәкъдимне «милли аерымлануга курс» дип бәяләде. Бу очракта интернационализмнан бернәрсә дә калмаячак бит. Татар язучылары чыгышларында партиянең үзәк органнарына ышаныч булмау һәм татар халкы белән бер үзәктән – Казаннан торып идарә итү омтылышы күренде, ягъни партия ҮК җитәкчелек итү өчен яраксызга чыгарылды.

«Идегәй» дастаны турында. Партия ҮКның 1944 елгы «Татарстан партия оешмасында гаммәви-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» мәгълүм карарында Идегәй турында дастан «ханнар-феодаллар» эпосы дип аталган иде. Партия өлкә комитетындагы быелгы очрашуда шагыйрь Салих Баттал карарда дастанның шулай бәяләнүенә ризасызлыгын белдерде. «Ничек инде халык дастанына шундый бәя биреп була? – дип дәвам итте Баттал. – Моның булуы мөмкин түгел бит». Иптәш Батыев «Идегәй»нең халык эпосы булмавын әйткәч, язучы Шәйхи Маннур әсәрнең халыкчанлыгын «халык үзе дәлилләгән» һәм бу дастанда халыкның бөтен зирәклеге тупланган, дип каршы төште. Идегәй турында дастанның асылы нидә? Анда Мәскәүгә, үзәкләштерелгән Мәскәү дәүләтенә каршы яулап алу сугышларына дан җырлана. Моның халык дастаны булуы шикле! Ә кайбер татар язучылары әлеге дастанга кабат мәдхия җырлый һәм шуның белән ҮК карарының дөреслеген шиккә ала.

Җәдидчелек турында.

Ә.Фәйзи: Җәдидчелек сүзен бүкәйгә әйләндерделәр, аны телгә алмаска тырышалар һәм пантюркизмга бәйләмәкче булалар. Ә бит бу фән-мәгърифәтчелек хәрәкәте! Биредә утыручыларның яртысы мәдрәсәдә белем алган. Дөрес, бу хәрәкәткә контрреволюцион элементлар килеп кушылган, шунлыктан бөтен хәрәкәт тә шулай кабул ителә башлаган.

С.Д.Игнатьев: Сез Татарстанны гына күз алдында тотасызмы, әллә гомумән җәдидчелекнеме? Бохарада, Урта Азиядә ул реакцион булган һәм зур зыян китергән. Ахыр чиктә җәдидчелек Англия разведкасы агентурасына әйләнгән.

Ә.Фәйзи: Бездә шартлар башка булган. Татарстанда җәдидчелек сәяси агымга саналмаган.

Реплика: Ялгышасыз!

Ә.Фәйзи: Мин бу турыда китап язам һәм күп нәрсә беләм.

Ә.Фәйзине Ш.Маннур яклап чыкты, ул «без җәдидчелекне контрреволюциягә бирдек», диде. Әлеге язучылар, җәдидчелекнең буржуаз-милләтчелек асылына төшенмичә, аны бары тик мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр кертүгә генә кайтарып калдыра.

Татар мәктәпләре турында. Республикада стихияле рәвештә татар мәктәпләрен кыскарту бара. Бу чыннан да шулаймы? Моны нәрсә белән аңлатып була? Татар халкының шактый өлеше балаларны рус телендә укытырга кирәк, дип саный. Кайбер язучылар таләп иткәнчә, татар балаларын рус телендә укытуны административ юл белән тыю мөмкинме? Әлеге адым СССР халыкларының теләсә кайсы телендә белем алуны гарантияләгән Конституциягә каршы килер иде. ТАССРның милли үзенчәлекләрен дә исәпкә алу мөһим. Болар барысы да әлеге мәсьәләгә бик сак карауны, милли һәм гомумдәүләт шарт һәм бурычларын исәпкә алуны таләп итә. Әмма кайбер язучылар (кагыйдә буларак, аларның үз балалары рус мәктәпләрендә укый) кичекмәстән чара күрүне даулый. Кайвакыт исә бөтенләй милләтчел фикерләр дә ишетелгәли. Мисал өчен, күптән түгел «Совет Татарстаны» газетасында Язучылар берлеге рәисе, партиянең Татарстан өлкә комитеты бюросы әгъзасы Гомәр Бәширов татар балаларына рус исемнәре кушуны тыю тәкъдиме белән чыкты.

Шунысын да искәртү мөһим, мондый чыгышлар язучылар даирәсендә ризасызлык тудырмый. Хәтта КПСС өлкә комитетындагы очрашу вакытында да бер генә язучы да каләмдәшләренең ялгыш фикерләренә каршы чыкмады. Бары тик Игнатьев, Батыев, Фасиев иптәшләр генә бу язучыларның хаталы карашларын тәнкыйтьләде һәм дөрес юнәлешне күрсәтте.

Язучылар белән күзгә-күз сөйләшү әлеге әһле каләм җәмәгатьчелеген борчыган күп сорауларны ачыкларга һәм шунда ук хәл итәргә дә мөмкинлек бирде. Шулай да танылган язучыларның күбесенең чыгышлары Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлегендә җитди кимчелекләр булуын дәлилли, шулардан иң мөһиме – язучылар арасында идеология һәм сәясәт-тәрбия эшенең зәгыйфьләнүе.

Югарыда язылганнарны исәпкә алып, безнең газета милли республика тормышын яктыртуны көчәйтергә, идеология, милли мәдәният мәсьәләләренә күбрәк игътибар бирергә тиеш, дип саныйм.

Имза».

Иң яңа тарих Россия дәүләт архивы, 5 нче фонд, 34 нче исемлек, 31 нче эш, 6-15 нче битләр.

Материалны тарих фәннәре кандидаты **Резеда ДАУТОВА** әзерләде.

«Гасырлар авазы» журналыннан Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА тәрҗемәсе.

Айга кырыннан карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

17 декабрь (шимбә). ***Җөмәдел әүвәл аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 12.29 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.02 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Бишьяфрак шифасы (1)

Бишьяфрак яки саз утчәчәге (сабельник болотный) органик кислоталарга, С витаминына, каротин, сапонин, катехинга, флавоноидларга, фенолкарбон кислоталарына, эфир майларына, сумалага бай. Ашказаны авыртканда, 1 аш кашыгы киптереп вакланган үләнне термостагы 1 стакан кайнар суга салып, 2 сәгать төнәтәләр, сөзәләр. Көненә 3-4 тапкыр, ашарга 1 сәгать кала, өчтән берәр стакан эчәләр. Подаградан дәвалану өчен, 1 аш кашыгы вакланган үлән тамырын 200 мл суда сүрән утта 15-20 минут пешерәләр, сөзәләр дә, көненә 4 тапкыр, ашаганчы, 2шәр аш кашыгы эчәләр.

18 декабрь (якшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,1.12 сәгатьтә калка, 12.36 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.01 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Бишьяфрак шифасы (2)

Салкын тигәндә, 1 аш кашыгы вакланган утчәчәк үләне һәм тамырын 1 стакан кайнар суда 1-2 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көн дәвамында әкренләп эчеп бетерәләр. 1 аш кашыгы үлән һәм тамырны 1 стакан кайнар суга салып, икенче бер сулы савытка утыртып, 15 минут җылыталар, 1 сәгать төнәткәч, сөзәләр. Остеохондроз, ревматизм булганда, буыннар сызлаганда, көненә 3 тапкыр өчтән бер стаканны ашаганчы эчәләр, подагра, радикулит һәм остеохондрозны дәвалау өчен, шул төнәтмә кушылган ваннада коеналар. Вакланган бишьяфрак тамырын пыяла банкага тутырып, өстенә көнбагыш мае салалар, әледән-әле селкеткәләп, караңгы урында 3-4 атна төнәтәләр. Сөзеп, сызлаган буыннарга ышку өчен тоталар. Файдаланыр алдыннан майны 40 градуска кадәр җылытып, буынга сөртәләр, йон тукыма белән урыйлар.

19 декабрь (дүшәмбе). ***Җөмәдел әүвәл аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,2.36 сәгатьтә калка, 12.44 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Бавырга ярдәм

Колмакның яшел яфрак һәм сабакларыннан сыгылган 2 аш кашыгы сокны 200 әр мл кайнар сөт белән суга кушалар. Яисә 2 аш кашыгы киптереп вакланган колмак күркәсен 200 әр мл сөт һәм суга кушып, термоста 10-12 сәгать төнәтәләр. Колмак сөтен тәүлек буена өз-өзләп эчеп бетерәләр (ашаганнан соң). Дәва курсы – 10-12 көн. Мондый төнәтмә бавырны токсиннардан чистарта, бигрәк тә гепатит, цирроздан соң эчү файдалы.

20 декабрь (сишәмбе). ***Җомәдел әүвәл аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,4.05 сәгатьтә калка, 12.55 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

21 декабрь (чәршәмбе). ***Җомәдел әүвәл аеның 27 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 5.40 сәгатьтә калка, 13.12 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

22 декабрь (пәнҗешәмбе). ***Җомәдел әүвәл аеның 28 нче көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,7.18 сәгатьтә калка, 13.39 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзеңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Томаудан – борыч

Борычлы тукыманы (перцовый пластырь) 5 мм-1 см киңлектәге тасмаларга кисеп, берсен маңгайга сул каш уртасыннан уң каш уртасына кадәр, берәрне борынның ике кырыена ябыштыралар. Борын куышлыклары бар яклап җылына һәм томау тиз арада бетә. (Әмма болай эшләр алдыннан табиб белән киңәшү зарур!)

23 декабрь (җомга). ***Җомәдел әүвәл аеның 29 нчы көне. 30 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 8.48 сәгатьтә калка, 14.26 сәгатьтә бата. 13 сәгать 16 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 7.00 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Кәбестәле күптермә

Уртача зурлыктагы 1 баш кәбестәне саламлап турап, атланмай кушылган үсемлек маенда алтынсу төскә кергәнче кыздырып алалар. 3 йомырка, 1,5 чәй кашыгы шикәр, 1 чәй кашыгы тоз, 5 әр аш кашыгы каймак (яки куе сөт өсте) һәм майонез, 6 аш кашыгы он, 1 чәй кашыгы серкә белән сүндерелгән содадан камыр туглап, кәбестә өстенә агызалар да, кайнар газ мичендә пешерәләр.



Җан тынычлыгы булырмы?

Урта яшьләрдәге берәү юк-бардан тавышланганнан соң, урамга чыккан һәм анда үзенең гыйлем остазын күргән. Кечке тынлыкта, саф һавада болар икәү авыл күленең яр буена барып утырганнар. Тып-тын, җил юк, күл өсте көзге кебек. Остазы шәкертенең дулкынланган булуын күреп, аңа сорау бирергә уйлаган. Шәкерте анардан җитезрәк булып чыккан һәм остазыннан сораган:

– Хөрмәтле остазым, әйтегез әле, гаиләдә беркайчан тавыш чыгармыйча, бер-береңне аңлау (гармония) булырга мөмкинме? – дигән.

– Минем уемча, андый хәл кешеләр һәммәсе дә бертөрле уйлый башланнан соңдыр бәлки? Бер-берсенә дәгъва булмаячак, чөнки икесе дә бертөрле уйлыйлар бит! Шундый хәлнең булуы мөмкинме соң? – дип өстәгән.

– Бу хәлнең булуы мөмкин түгел, – дигән остаз, – чөнки синең очрак кешеләрнең шәхес буларак юкка чыгуына китерә. Һәр кешенең эчендә «МИН» дигән төшенчә бар бит. Кешеләр бер-берсенең чагылышы түгел, ә шәүләләре булыр иде.

Бераз тукталып торганнан соң, остаз өстәгән:

– Әгәр адәм баласы башкаларның хокукларын чикләмичә, иренә-хатынына хөрмәт белән караса һәм аның шәхесен кимсетмәсә, кешеләрнең бер-берсе белән аңлашу проблемасы чишелер иде, – диде.

Оныгы уйга калды

Мәктәпне тәмамлаучы онык каникул вакытында бабасы янына кунакка килә. Зур авыл, ерак түгел мәчете дә күренә.

Оныгы бабасына:

– Сезнең авылның табигате матур, әмма кызлары ошамый: барысы да диярлек озын итәктән, яулыктан – эчпошыргыч.

Бабасы кулын кесәсенә тыгып, аннан ике конфет чыгара: берсе – төрелгән, икенчесе – төрелмәгән (кәгазьсез).

– Кайсын сайлап аласың? – ди бабасы.

– Төрелгәнен, әлбәттә, – дигән җавабында оныгы.

– Нигә? – ди бабасы.

– Анысы чистарак, – ди оныгы.

– Кызлар да шулай ук, – ди көлемсерәп бабасы.

Кыйммәтле таш

Берәү үзенең бала чагын исенә төшереп, алмазны беренче күрүе фикеренең ничек үзгәрүе турында сөйләгән. Башта күргәч:

– Нинди кыйммәтле асылташ, – дигән.

Үсә төшкәч, ул алмазның составы графит кебек булуын, аның һәр карандашта файдалануын белеп, күңеле төшкән. Аннан соң аның структурасы кристаллик рәшәткәдән торуын һәм бик каты матдә булуын белгәч, күңеле күтәрелгән. Инде ул – мөхтәрәм акыл иясе, остаз булгач, алмаз аңа гади таш кебек кенә булып калган. Аның алмаз турында мәгълүматы арткан саен, ул таш үзенең моңа кадәр белмәгән яңа кырлары белән ялтырый.

– Акыл иясе һәм үсмер баланың фикерләве бертөрлеме икән? Әгәр алай булса, нигә тырышырга, зирәклек тупларга һәм аларны үзләштерергә? – дип сорады тыңлап торган үсмер.

– Үсмер бала һәм акыл иясе – бертигез түгел. Бала алмазны бәяли алмый, чөнки аның чын кыйммәтен белми, ә акыл иясе бәяләми, чөнки аның чын бәясен, кыйммәтен белә. Бәхетне, мәхәббәтне, зирәклекне һәм шатлыкны ул алмазга сатып ала алмаганны һәм ахирәткә дә алып китә алмаганны яхшы аңлый.

Кунакханәдә

Бер ир кеше кунакханә җитәкчесенә хат язып җибәргән:

– Мин сезнең кунакханәгездә вакытлыча ике атна торырга планлаштырган идем. Үзем белән этемне дә алырга теләдем. Ул бик яхшы тәрбия алган. Сезгә артык мәшәкать китермәс. Мондый тәкъдимемә сез каршы түгелме? – дигән.

Кунакханә җитәкчесеннән аңа җавап хаты килгән:

– Күп еллар буе бу кунакханәне җитәклим. Шул вакыттан алып хәзерге көнгә кадәр кунакханәдән бер генә эт тә сөлге, җәймә яки дивардагы картинаны урлап чыгып китмәде. Минем беркайчан да исерек этнең идәндә аунап ятып, тәртипсезлек эшләп полиция чакырганым булмады. Беркайчан да кунакханәдә яшәгән өчен бер этнең дә түләмичә калганы булмады. Рәхәтләнеп этегезне кунакханәбезгә чакырам, әгәр дә сезнең тәртибегезгә җаваплы булса, этегез белән сез дә килә аласыз.

Мәче балалары сатам

Урам ягында бер кибет ишегенә «Мәче балалары сатам» дигән белдерү ябыштырылган. Моңа, беренче чиратта, бала-чагалар игътибар итә.

Берничә минуттан кибеткә бер ир бала керә. Исәнләшкәннән соң, мәче баласының бәясен сорый. Утыздан илле сумга кадәр дип җавап бирә сатучы. Ир бала янчыгын алып карагач, анда барысы ике сум гына була. Ул күңелсезләнеп башын ия, аннан соң сатучыдан аларны карарга буламы, дип үтенә. Сатучы елмаеп аяк астындагы катыргы капны күтәреп, өстәлгә куя. Мәче балалары селкенеп хәрәкәтләнә башлый. Тик берсе генә арт аякларын авырлык белән сөйри.

– Ә бу мәче баласына ни булган? – дип сорый малай.

– Ул тумыштан ук зәгыйфь туган, гомер буе төзәлмәячәк, – ди яңашәдә басып торган ир-ат.

– Апа, минә шул мәче баласын үземә алыр идем, – ди малай.

– Нәрсәгә ул сиңа? – ди сатучы, – бик җәллисең икән, бушка бирәм, алып кит, – ди.

– Юк, апа, бушка алмыйм, ул да башкалар кебек бәядә булырга тиеш бит, – ди малай.

Сатучы малайга карап, аны кызганып та куя.

– Ул башкалар кебек йөгереп-сикереп уйный да алмый бит, – ди.

Малай сул чалбар балагын күтәрә, ә анда тимерчыбыклар тарттырылган.

– Мин дә чабып-сикереп йөри алмыйм, шуңа күрә мине «имгәк» дип мыскыл итәләр. Гарип мәче баласын башкалардан да яхшырак аңлыйм. Мин аны башкалардан саклар идем.

– Башка мәче балаларын алучыларның да йөрәкләре синеке кебек шәфкатьле, мәрхәмәтле булсын иде, улым, – ди күзләре яшьләнгән сатучы.

Яшьме-картмы, авырумы-сәламәтме – кешене аның башкарган эше белән бәялиләр.

Нияз БИШБАЛТА туплады.

Стратегияләр дә, комиссияләр дә сакламый

Бездә төрле бәйрәмнәр, юбилейлар, тарихи истәлекле көннәрнең билгеләп үтелгәннәре белән беррәттән, күренмичә читтә калганнары да шактый. 29 ноябрьдә дә истәлекле ике датаны билгеләп үтәргә булыр иде. 1991 елның 29 ноябрендә Татарстан Дәүләт Советында Республика флагы кабул ителде. Кызганыч, бу уңайдан халык өчен бернинди истәлекле чаралар да үткәрелгәне күренмәде. Рәсми рәвештә әләмебез кабул ителгән көн булуга карамастан, ТНВ каналыннан, Конституция көнендәге кебек, бер җөмлә белән генә, 31 ел элек бу көнне Татарстан флагының Дәүләт Советында кабул ителүен әйтеп киттеләр.

2017 елның 29 ноябре – Татарстан Дәүләт Советы депутатлары бертавыштан мәктәпләрдә татар телен мәҗбүри укытуга каршылык күрсәтеп, кулларын күтәргән көн. Бу безнең халкыбыз өчен 1552 елдагы дәүләтчелегебезне югалтуга тиң вакыйга булды. Бу гамәлләр Россия һәм Татарстан Конституцияләрендәге маддәләрне санга сукмыйча башкарылды. Хакимият вертикале барлыкка китерелгәч, Төп Закон үзенең вазыйфасын үтәүдән мәхрүм калды. Шул вакытлардан соңгы 5 ел эчендә татар телен саклау һәм үстерүгә багышланып, үзебезне-үзебез алдауга корылган чараларның, сөйләнгән сүзләр һәм язмаларның хисабы юк. Ул эшкә ашмастай проект – телне саклау һәм үстерү стратегиясе дигәннең дә, комиссияләрнең дә телне саклап калуга бернинди катнашы юк. Алар берсе дә мәктәп түгел. Имтиханнарны рус телендә генә тапшыру мөмкинлеге турында каһәр суккан законның үзен юкка чыгарып, мәктәпләргә элеккеге мәгариф системасын кайтарганда гына, телебезне саклап калу мөмкинлеге булачак.

Әле яңадан да телебезне юкка чыгаруның яңа ысуллары уйлап кына торалар. Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе дигәннәре үзгәртелеп, татар теле республикада яшәүче 100 гә якын милләтнең телләре белән бер югарылыкта калдырылуы, татар телен шулар белән бергә үстерә башлаячаклары турында ишеткәч, нәрсә әйтергә дә белмичә, аптырап калырлык бит. Бу кадәр дә ахмаклык, мәгънәсезлек, мәрхәмәтсезлек белән телебезне явызларча бетерүгә багышланган мәкерле гамәлләргә күпме түзәргә була? Бу вәзгыятьтә, республикада яшәүче 100 гә якын милләткә үз мәктәпләрен булдырып, атнага ике сәгать кенә булса да аларны да үз телләрендә укытырга тиеш булабызмы? Шулай килеп чыга түгелме? Аларның телләре үз илләрендә саклана, ә безнеке Финляндиядә сакланса гына инде. Безнең милләт халкы бөтен дөньяга таралган. Аларның берсе дә чит илләрдә, миңа татар телен укытыгыз, дип йөрмәгән кебек, бездәге чит милләтләр дә безгә андый таләп куя алмыйлар, һәм бу турыда беркайчан бер сүз ишетелгәне булмады. Булмаячак та. Казанда һәм башка шәһәрләрдәге халыклар дуслыгы йортларында аларның үзләренең оешмалары бар. Алар шунда үз гореф-гадәтләрен һәм телләрен саклап калу өчен тырышып яталар. Дөньяның барлык илләрендә яшәүче төп халык үзенең телен кулланып, аны хөрмәт итеп яшәгәндә, безгә үз телеңдә уку ник тыела икән? Үз телеңдә, Аллаһ Тәгалә биргән телдә уку җинаять түгел ул. Хәзерге ызгыш-бәрелешләр дә рус телен кыерсыталар дигән сылтау белән башланып китте түгелме? Шундый ук гамәлләрнең үз илеңдә хуплануын ничек аңларга?

Телебезне үстерәбез дигән булып, бездә дуслык, татулык дип, кемнәргәдер рәхмәт әйтеп торуны ничек аңларга? Телебезнең аяныч хәле турында төрле югарылыктагы җитәкчеләргә, депутатларга, министрларга язылган мөрәҗәгатьләрнең уңай нәтиҗәләр бирмәвен ничек аңларга?

Рәфкать ИБРАҺИМОВ,
Казан шәһәре.

Күңелдә кара юшкын

Мәсүфә Әюпова – Борайның 3нче мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы. Шигырьләр яза, татар теле өчен җан ата. Татар телен кысрыклауга түзә алмыйча язылган шигырен дә укып күрсәтте безгә. Мәсүфә ападан Борайда нинди милләтләр яшәве, татар теле дәресләре турында сорадым.

– Борай районында төрле милләт яши, күпчелеге – татарлар. Татарлар борынгы заманнан ук шушы җирлектә яшәгән, – дип башлады ул сүзен. – Мәсәлән, мин яши торган Берләч авылына Казаннан бер бабай килеп нигез салган, диләр. Мәктәпләргә башкорт телен керткән вакытта да, Борай районындагы Берләч, Кизгән, Кузбай, Мулла авылларына башкорт телен кертә алмадылар, чөнки алар төптән үк татар авылы дип санала. Шушы авылларда гомер буена татар телендә укыттылар. Бөтен фәнне татарча укыдык. Татар телендә рәхәтләнеп аралашып, балаларны да саф татар әдәби теленә сөйләшергә өйрәтеп чыгара идек. Бер генә бала да килешләрне, кушымчаларны, бәйләгеч, ымлык һ.б. темаларны белмичә калмый иде. Чөнки көн саен бер сәгать татар теле дәресе укытылды. Көн саен! Шулкадәр җайлы иде безгә... Хәзер ул ымлыкларны сөйләргә вакыт та юк. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына үзгәрешләр кертелгәч, башлангыч сыйныфта татар теле һәм татар әдәбияты бер генә сәгать укытыла башлады.

Бүгенге көндә халәтем нинди, дип сорасаң, җавап шул: күңелем әрни. Исем, фигыль, рәвеш турында гына сөйләп, шул турыда сорау биргәнгә, күпчелек бала русча җавап бирә. Утырып еларлык хәлләр. Өйдә дә, мәктәптә дә русча сөйләшәләр.

Бер генә сәгать белән татар телен укыту бик авыр. Китапта бик күп материал бирелгән, аны бер сәгатьтә генә берничек тә җиткереп бетереп булмый. Дәресләр кайчак бәйрәмнәргә дә туры килә, шул бер сәгать төшеп кала. Русча сөйләшә торган балаларга бу рәвешле татар телен өйрәтеп булмый, туган телгә мәхәббәт уята алмавыбыз эшләнеп бетмәгән эш кебек кала. Күңелгә кара юшкын булып утыра. Бездән соң татар телен өйрәнүчеләр табылырмы, яки ул мәңгелеккә тарихта гына калырмы?

З.МӨБАРӘКШИНА.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

16 декабрь – зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). Кече залда – «Көл» (К.Митани).
17 декабрь – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
18 декабрь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
23 декабрь – Премьера. «Рәшә» (Ә.Еники).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

17, 18 декабрь – «Спящая красавица» (П.Чайковский).
23 декабрь – «Летучая мышь» (И.Штраус).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

16 декабрь – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
17 декабрь – «Беренче мәхәббәт» (И.Гали).
22 декабрь – Премьера. «Идегәй» (Н.Исәнбәт).
23 декабрь – 13.30 – «Тылсымлы арена» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци, К.Тинчурин).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

16 декабрь – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
17 декабрь – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
18 декабрь – 13.00 – «Кәҗүл читек» (Г.Исхакый). 18.00 – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
20, 21, 22, 23 декабрь – «Галәм кунаклары һәм...» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән.

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

16-23 декабрь – «Сон в новогоднюю ночь» дип исемләнгән Яңа ел тамашасы һәм чыршы тирәсендә әйлән-бәйлән.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

17 декабрь – «ДНК Кармен» дип исемләнгән спектакль.
22 декабрь – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры һәм җырчы В.Самсоновның «Раштуа утлары балкышы» дип исемләнгән концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

17 декабрь – Композитор Эльмир Низамовның музыкаларыннан концерт. Катнашалар – Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге «La Primavera» Казан камера оркестры, җырчы Алинә Шәрипҗанова, музыкантлар Михаил Редреев (скрипка), Азат Сәхапов (ирен гармоникасы), биюче Мария һәм Марсель Нуриевләр.
18 декабрь – Татарстан Республикасы кыллы музыка кен кораллары дәүләт кавртеты башкаруында «Яңа ел вернисажы» дип исемләнгән концерт.
21 декабрь – «La Primavera» Казан камера оркестрына «Москонцерт» солисты, Мәскәүнең Зур театрында еш чыгыш ясаучы контртенор Рөстәм Ясавиев һәм күренекле җырчы Гөлнара Мурзиева кушылып җырлый. Дирижер – Рөстәм Абязов.
23 декабрь – Татарстан Республикасының М.Таминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры концерты.

Гаепсезлеге дәлилләнгән

АКШ та 56 ел төрмәдә утыруга хөкем ителгән Дин Гиллиспи 20 елдан соң гаепсез дип табылган, аннары исә полициядән 45 миллион доллар (2,7 миллиард сум чамасы) акча дәгъвалауга ирешкән. Аны 1991 елда талау, көчләү һәм кеше урлауда гаепләп ирегеннән мәхрүм иткәннәр, суд аның эшенең законсыз чаралар белән алып барылуын исбатлагач, 2011 елда ниһаять төрмәдән чыгарганнар. Шул вакыттан бирле Дин The Ohio Innocence Project хокук яклау оешмасы ярдәмендә үзенең гаепсезлеген дәлилләү өчен көрәшкән. 2021 елның декабрендә Гиллиспиның чыннан да гаепсезлеге расланган, ә Огайо штаты Майами тауншипы (бистәсе) полиция идарәсе һәм отставкадагы детектив Скотт Мурның тикшерү вакытындагы хилафлыклары дәлилләнгән – алар 57 яшьлек Дингa 45 миллион доллар түләргә тиеш дип табылган.

(“USA Today”).

36 елдан соң табышу

Чилидан игезәкләр Элан һәм Мика Нарди 36 елдан соң үзләренең биологик әнисен табып күрешкән. Бертуганнарны 1986 елда урлаганнар. Әниләре аларның абыйсы белән хастаханәгә барганда, өч айлык игезәкләрне дә үзе белән алган. Табиб олы улын тикшергән вакытта шунда эшләүчеләрдән берсе игезәкләрне үзем карап торам дип ышандырган. Берничә минуттан кабинеттан чыккан ана игезәк улларын тапмаган. Полиция дә килеп җиткән, әмма сабыйларны урлаучының эзенә төшә алмаганнар. Соңрак ачыкланганча, ул елларда Чилида яшәүче меңләгән баланы урлап Төньяк Америка һәм Европадагы гаиләләргә уллыкка биргәннәр. Элан һәм Мика Массачусетс штатында яшәүче гаиләгә эләккән. Үз әниләре исә аларны эзләүдән беркайчан да туктамаган, төрле программаларда катнашкан, бик күп хат язган. Былтыр ана кеше Connecting Roots оешмасына мөрәҗәгать иткән. Волонтерлар аңа ДНК-тестлар ярдәмендә балаларын табып биргән. Башта видеоэлемтә аша сөйләшкәннәр, аннары игезәкләр Чилига үз әти-әниләре янына кайткан. 1974 елдан 1990 елга кадәр, илдә диктатор Аугусто Пиночет хакимлек иткән чорда, хөкүмәт, шул рәвешле илне хәерчелектән чыгармакчы булып, меңләгән сабыйны урлаган һәм алга киткән илләргә җибәргән.

(“People”).

Өйнең яме – балада

Бөекбританиядә патронат тәрбияче ана 92 баланы үстерүдә катнашкан. Быел икесенә дә 52 яшь тулган Джо һәм Кристофер Ньюби моннан 22 ел элек өйләнешкән. Ул вакытта Джоның беренче никахында туган бер улы булган инде, әмма алар ирле-хатынлы икесе дә күп балалы зур гаилә турында хыялланган. 2004 елда Джо һәм Кристофер, ниһаять тәвәккәлләп, өч айлык баланы тәрбиягә алган. Бераздан тагын бер сабый өстәлгән. Шул рәвешле 19 ел эчендә Ньюбиларның зур йорты аша 92 бала үткән. Гадәттә гаиләдә берьюлы өчәр бала якынча өчәр ел тәрбияләнә, аннары аларга биредәгедән яхшырак шартлар тудырылган урын табалар яки уллыкка-кызлыкка бирәләр. Яшь ярымлык вакытта тәрбиягә алынган Каспер исемле малай гына биредә даими яши, чөнки сәламәтлеге буенча аңа даими игътибар таләп ителә. Мондый эшчәнлегенең һәр сәгате өчен Джога 0,5 фунт стерлинг акча түләнә, әмма аның әйтүенчә, акча әллә ни мөһим роль уйнамый, чөнки ул балаларны тәрбияләү һәм кайгырту белән вөҗданы кушканга һәм бик яратып шөгыльләнә. Гаиләнең төп керемен исә дәүләт хезмәткәре булган Кристоферның эш хакы тәшкил итә. Джо әйтүенчә, аларның өендә һәрвакыт чиста һәм тыныч, чөнки ул көндәлек мәшәкатьләрне һәркемгә хәлкадәри бүлеп бирә белә, балаларны өй эшләрен үтәргә, мөстәкыйль һәм пөхтә-тәртипле, намуслы һәм әхлаклы булырга өйрәтә.

(“Daily Mirror”).

Елмая торган йорт

Тере һәм бик шук йортлар мультфильмда гына түгел, чынбарлыкта да бар икән. Шулардан берсе – Rizzihaus – XXI гасыр башында Бруклин рәссамы Джеймс Рицци хыялында туган, дизайнерның кыю идеясен исә архитектор Конрад Клостер тормышка ашырган. Әлеге йорт Германиянең Брансуик шәһәрендә урнашкан. Бер яктан караганда, ул рәхәтләнеп көлә кебек, икенче яктан карасаң – шаян елмайганга охшаган. Шуңа да аны күргән һәркемнең шунда ук кәефе күтәрелә.

(“Интересно.cc”).



Дөньяда иң зур чәйнек

Әлбәттә, бу чын чәйнек түгел, ә йорт. Кытайның Гуйчжоу провинциясендәге биеклеге 74 метрлы бу бинада чәй клубы һәм гадәти булмаган чәй музее урнашкан.

(“Nation Geographic”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

19 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «Беренче театр». 6+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
17.00, 0.20 «Таяну ноктасы». 16+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Куньлунь Ред Стар». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Рыцари вечности». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.20 «Калеб». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Алексей Крылов.
8.00 Черные дыры. Белые пятна.
8.50 «ВАМ ТЕЛЕГРАММА...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Сегодня и ежедневно. Юрий Никулин и Михаил Шуйдин».
12.20 Цвет времени. Карандаш.
12.30 «ТРЕТИЙ В ПЯТОМ РЯДУ».
13.40 «Малайзия. Остров Лангкави».
14.05 К юбилею Элеоноры Шашковой. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
16.35 «СЛОН И ВЕРЕВОЧКА».
17.25 100-летие Московской государственной академической филармонии.
18.45 «Устинов об Устинове. Всего искусства мало».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Престольный праздник. День Николая Чудотворца».
21.25 «Сати. Нескучная классика...»
22.10 «НЕНАСТЬЕ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА». 16+
22.10, 0.00 «ПЁС». 16+

Сишәмбе

20 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 6+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «АЛМАШ». 12+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30 «Татар халык җырлары». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50 «Яшәргә дә әле, яшәргә». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Бомба. Наши в Лос-Аламосе». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Искатели. «Исчезнувший сервиз Фаберже».
8.20 Цвет времени. Николай Ге.
8.35 «ГОРОД НАД ГОЛОВОЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 0.00 XX век. «Мастера оперной сцены. Зураб Соткилава».
12.20 «ТАЛАНТ».
13.35 «Игра в бисер» «Брэм Стокер. «Дракула».
14.15 К 85-летию со дня рождения Юрия Авшарова. Эпизоды.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
16.35 «Подвиг разведчиков».
17.25 2022 г. Международный конкурс пианистов, композиторов и дирижеров имени С.В. Рахманинова.
18.45 «Константин Коровин. Палитра слов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».
22.10 «НЕНАСТЬЕ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА». 16+
22.10, 0.00 «ПЁС». 16+

Чәршәмбе

21 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.30 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 12+
14.15 «Туган авылым». 6+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. «Локомотив» - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Спортивная среда». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20, 0.45 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Без права на славу». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Искатели. «Под вуалью Незнакомки».
8.20 Цвет времени.
8.35 «ГОРОД НАД ГОЛОВОЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 Спектакль «Стариковское дело».
12.20 «ТАЛАНТ».
13.35 Искусственный отбор.
14.15 85 лет со дня рождения Наталии Журавлевой. Эпизоды.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
16.35 «ПАССАЖИР».
17.20 Выпускной спектакль Академии Русского балета имени А.Я. Вагановой.
18.45 «Русские в Ливане. Григорий Серов».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.25 «Запечатленное время».
21.55 «Забытое ремесло».
22.10 «НЕНАСТЬЕ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА». 16+
22.10, 0.00 «ПЁС». 16+

Пәнҗешәмбе

22 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 17.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15, 0.40 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Оныта алмыйм...»
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00 «Точка опоры». 16+
20.00 «АЛМАШ». 12+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
18.50, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Утырып уйлар уйладым». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛИНЫ». 12+
14.45 «Театральное закулисье». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.45 «КАЗАНОВА В РОССИИ». 16+

22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию.

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДАМА С СОБАЧКОЙ». 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Искатели. «Тайна архива 44».
8.30 «ГОРОД НАД ГОЛОВОЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Юрий Жданов. Страницы жизни артиста и художника».
12.10 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
12.20 «ТАЛАНТ».
13.35 Абсолютный слух.
14.15 «Забытое ремесло».
14.30 Юбилей Ольги Антоновой. «Театральная летопись».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Звучащий мир древнего Новгорода».
15.50 К юбилею Елены Шаниной. «2 Верник 2».
16.35 «ЛЕНОЧКА И ВИНОГРАД».
17.25 XXV конкурс итальянской оперной музыки в Большом театре.
18.45 «Даниил Соложев. Послесловие к биографии».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Алексей Варламов. «Имя Розанова».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Свадьба в Малиновке». Вашу ручку, битте-дритте».
21.25 «Энигма. Лука Пианка».
22.10 «НЕНАСТЬЕ».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА». 16+
22.10, 0.00 «ПЁС». 16+

Җомга

23 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.30 Хоккей. «Витязь» - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+
23.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Утырып уйлар уйладым». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15 «Родная земля». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 22.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
21.25 «Ихлас». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВЫ ВСЕ МЕНЯ БЕСИТЕ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЮ НЕ ВЕРЮ». 12+
11.30 «ЭФФЕКТ БОГАРНЕ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ НА ОСТРОВЕ». 16+
14.30 «Театральное закулисье». 12+
14.45 «Архивы истории». 12+
15.00 «Вокруг света во время декрета». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Кошечки-собачки».
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
23.00 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
23.50 «ТЕНЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.20 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию.

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Дуэты». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Искатели. «Загадочная смерть досточтимого мастера».
8.30 «Забытое ремесло».
8.45 «ГОРОД НАД ГОЛОВОЙ».
10.20 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ».
11.40 Открытая книга. Алексей Варламов. «Имя Розанова».
12.10 Цвет времени. Тициан.
12.20 «ТАЛАНТ».
13.35 95 лет со дня рождения Александра Ведерникова. Линия жизни.
14.30 К юбилею Ольги Антоновой. «Театральная летопись».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Лука Пианка».
16.15 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
16.25 «ДЛИННЫЙ ДЕНЬ КОЛЬКИ ПАВЛЮКОВА».
17.00 2022 г. Юбилейный концерт к 90-летию Владимира Федосеева.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Всероссийский конкурс юных талантов «Синяя птица».
20.50 Цвет времени. Караваджо.
21.10 Линия жизни. Дмитрий Губерниев.
22.05 «НЕНАСТЬЕ».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 «Дороги будущего». 12+
12.00 «ДедСад».
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА». 16+
22.10 «ПЁС». 16+

Шимбә

24 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30, 17.30 «Татар халык җырлары».
14.00 «АЛМАШ». 12+
15.00 Спектакль «Банкрот». 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «РОЖДЕСТВО В ШОКОЛАДЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 Спектакль «Артист». 12+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Алхимик». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Челтер чишмә буенда». Асаф Вәлиевнең юбилей концерты. 6+
22.50 Спектакль «Шулай булды шул». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Планета собак спешит на помощь». 12+
5.45, 14.45 «Архивы истории». 12+
6.00 «Не иностранец». 12+
6.30 «Вокруг света во время декрета». 12+
7.00 «Лео и Тиг».
7.45 «Три кота. Сезон 3».
8.00, 15.00 «Все как у зверей». 12+
8.30 «Театральное закулисье». 12+
8.45 «ЗИМНИЙ ВАЛЬС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА 3 ДНЯ». 16+
15.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МОСТЫ ОКРУГА МЭДИСОН». 16+
23.15 «ДРУГАЯ БОВАРИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Бог войны. Укротители огня». 12+
12.55 «Видели видео?»
15.00, 16.15 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию.
18.20 «Снова вместе. Ледниковый период».
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.55 «ЭВИТА». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НАРОДНЫЙ АРТИСТ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.40 «ПОВОД».
9.50 «Передвижники. Константин Коровин».
10.20 «СОЛОМЕННАЯ ШЛЯПКА».
12.30 «Эрмитаж».
13.00 «Животные защищаются! Костюм имеет значение».
13.50 «Космический рейс. Навстречу Солнцу».
14.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.15 «Путешествие к центру Земли».
17.00 «ОПАСНЫЙ ВОЗРАСТ».
18.25 Юбилейный концерт к 85-летию Эдуарда Артемьева.
20.45 «РЕБРО АДАМА».
22.00 «Агора».
23.00 «МЕШОК БЕЗ ДНА».

«НТВ»
5.05 «Спето в СССР». 12+
5.50 «БОЙ С ТЕНЬЮ-3. ПОСЛЕДНИЙ РАУНД». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «АФОНЯ».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Секрет на миллион». 16+
22.15 «35 лет на льду». 6+

Якшәмбе

25 декабрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Зебра полосатая».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.15 «Янам мәхәббәт дулкынында». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Видеоспорт». 12+
14.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
16.00, 0.50 «Ком сәгате». 12+
17.00 Хоккей. «Сочи» - «Ак Барс». 6+
19.30, 22.00 «Семь дней». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.00 «Профсоюз - союз сильных». 12+
21.15 «Батырлар». 6+
21.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
23.00 «ЗА ГРАНЬЮ РЕАЛЬНОСТИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Адымнар». 12+
7.30 «Җырларым-моңнарым тик сезнең өчен». Марсель Иванов җырларыннан концерт. 6+
10.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Мөсәгыйть Хәбибуллин турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Җилкәнсезләр». 12+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
22.00 Спектакль «Җизнәкәй». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Планета собак спешит на помощь». 12+
5.45 «Архивы истории». 12+
6.00 «Не иностранец». 12+
6.30 «Вокруг света во время декрета». 12+
7.00 «Лео и Тиг».
8.00, 15.15 «Все как у зверей». 12+
8.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МОСТЫ ОКРУГА МЭДИСОН». 16+
15.45 «ЗИМНИЙ ВАЛЬС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КАК ВЫЙТИ ЗАМУЖ ЗА 3 ДНЯ». 16+
22.45 «ЛЮБОВЬ НА ОСТРОВЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00, 6.10 «ЕГЕРЬ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.35 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию.
16.05 «МЭРИ ПОППИНС, ДО СВИДАНИЯ».
18.50 «Золотой граммофон». 16+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
6.15 «КИТАЙСКИЙ НОВЫЙ ГОД». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 16.00 Вести.
11.50 «И В СЧАСТЬЕ, И В БЕДЕ». 12+
17.00 «Песни от всей души». 12+
19.00 Вести недели.
21.00 «Красный проект». 12+
23.00 Москва. Кремль. Путин.
23.35 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.30 «ОПАСНЫЙ ВОЗРАСТ».
9.55 Тайны старого чердака. «Академия».
10.25 «РЕБРО АДАМА».
11.45 «Музей Мирового океана. Власть Воды».
12.30 Невский ковчег. Теория невозможного. Анатолий Кони.
13.00 «Игра в бисер» «Эрнст Теодор Амадей Гофман. «Щелкунчик и Мышиный король».
13.45 «Космический рейс. Притяжение Юпитера».
14.25 «Я - АЛЬБЕРТО СОРДИ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Лифт в историю».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «СОЛОМЕННАЯ ШЛЯПКА».
22.20 Станислав Ли, Дарья Терехова, Дмитрий Никаноров в опере Дж. Россини «Севильский цирюльник».

«НТВ»
5.15 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Суперстар! Возвращение». 16+
23.30 «Главный бой». 16+

Башкаларга карата дорфа, тупас кылану, усаллык, юньсезлекләр эшләү берәүгә дә килешә торган гамәл вә гадәт түгел. Бу җәһәттән погонлы кешеләр белән бигрәк тә сак һәм тотнаклы аралашырга кирәк. Юкса, бәлале булуың ихтимал.

Хокук сакчысын канун яклый

Әнә урта яшьләрендәге Марсель Хәбибуллин шундый юньсезлеге аркасында 2 ел да ике айга колониягә озатылды. Моны такыр юлда абынып егылу, ягъни көтмәгәндә килгән бәлагә тиңләп булмастыр, чөнки исеректән барысын да көтәргә була. Дөрес, 1975 елгы Әлмәт кешесе төрмәдә утырмаган. Полициядә, нарколог һәм психиатрда исәптә торган зат түгел, 16, 21 яшьләрендәге ике кызы бар, нефть чыгару оешмасында бораулаучы булып эшли. Аның кебекләр турында, гадәттә, эчү дигән бер генә кимчелеге бар, ягъни шул зәхмәте аркасында туган тәгәрәгән зат, диләр. Марсель дә шул сәбәпле 2021 ел азагында гаиләсеннән аерылган, үзе генә тора башлагач, тагын да ныграк сала, ешрак полиция күзенә чалына, административ җаваплылыкка тартыла башлаган.

Бәйләнергә кеше таба сәрхуш. Аерылышкан хатыны аның шалтыратып начар сүзләр әйтүеннән зарлана, күршедә яшәүче яшьрәк Ксения аерылышуларын, кычкырышуларын сөйләп тора. 5 июльдә ошбу ханым күршесенең «ватсап» кушымтасына аның фотосурәтен урнаштырып, хурлыклы сүзләр язуын белеп ала һәм участок инспекторы Марсель Шәрифуллинга шалтырата, полициягә гариза язачагын җиткерә.

Полиция капитаны килеп җитә, әлбәттә. Шул рәвешле ул көнне исерек М.Хәбибуллинга әрләшү-талашу өчен тагын бер кеше пәйда була. «Профилактик» әңгәмә өчен урамга чыгудан баш тартып, беренче каттагы балконында торып аралашуны кулай күрә ул. Күп тә үтми шул тарафтан погонлы хезмәткәргә таба бик юньсез, шуңа күрә газетага язарга ярамаган сүзләр кычкырырга тотына. Кыскасы, кисәтүләргә карамастан, форма кигән адашын кем әйтмешли, эттән алып, эткә сала салмыш Марсель. Бу инде аның закон чиген үтеп чыгуын белдерә, чөнки ошбу гамәл хезмәт вазыйфасын башкарган власть вәкилен гавам алдында (публично) мәсхәрәләү дигән җинаять санала. Капитан М.Шәрифуллин әлеге галәмәтне күреп торган Ксения һәм кызыксынып тамаша кылган тагын бер хатын-кыздан аңлатма алып китеп бара. Полиция хезмәткәренә карата эшләнгән хилафлык буенча тикшерү комитетының Әлмәт бүлеге җинаять эше кузгата. Ләкин сәрхүшне бу да айнытмый, ул сорау алуларга килмичә мәшәкать чыгара. 14 июльдә участок инспекторлары Э.Җиһаншин һәм М.Шәрифуллинга, аны табып алып килү бурычы куела. Җинаять кылуда гаепләнүче фатирында булмагач, ул Кичүчатта яшәүче эти-әнисе янында дигән фараз туа. Шулай булып чыга да.

Монда исә вакыйганың кискенрәге башлана. Повестка бөгәрләп ташлана, Марсель беркая да бармый, иртәгә эшеннән (Норлат районны –Н.В.) алып китәрсез дип, бигрәк тә, әни кеше каршы килә. Әлбәттә, төп рольне исерек малай уйный һәм кеше ышанмаслык гамәлләр кыла, мәсәлән, быелгы кызу җәйдә кыска җиңле күлмәк кигән Э.Җиһаншинның кулына басып тәмәкесен сүндерә, тешләк бурзай кебек терсәгеннән каптырып ала. Аны тәртипкә чакыру, кисәтүләрнең файдасы тимәгәч, М.Шәрифуллин йөгәнсезне богауламакчы була, ләкин тегенең каршылык күрсәтүе сәбәпле, аның берсен уң кулга эләктерергә өлгерә, икенчесе буш кала, шул мәлдә явыз бәндә аның маңгаена тондыра, тимер әйбер эләккән урыннан кан ага башлый, өстәвенә, котырынган кеше тагын капитанның кулын тешләп ала, чын мәгънәсендә бәрелеш-көрәш бара, эш өйалды идәнендә әүмәкләшүгә кадәр барып җитә, М.Шәрифуллинның хәтта погонлы күлмәге умырыла, Э.Җиһаншинга борычлы баллоннан сиптерергә дә туры килә. Бу вакытта ата-ана арага кереп аерырга, ыгы-зыгыны туктатырга маташып карый, ахыр чиктә өчесе дә өйләренә кереп бикләнә алар.

Капка төбендәге маңгае гына түгел, инде йөзе-бите бөтенләй канга буялган ертык күлмәкле капитанны күреп алган күрше Артур йөгереп килә, өеннән су, бинт алып чыгып, аңа ярдәм күрсәтә. Әти-әнинең улларын полициягә биреп җибәрәсе килмәвен аңлап була. Ләкин аларның каршы килеп телләнеп торуының әлеге вакыйгага тискәре йогынты ясавы кире кагыла алмый. Алар чакыруы буенча Әлмәттән килеп җиткән кызлары исә башкачарак эш итә. Өйдәгеләрне, иң әүвәл, абыйсын тынычландырырга тырыша. Хәер, ул чакта артыгын кылып ташлавын сәрхүш үзе дә төшенгәндер инде.

Шул рәвешле, М.Хәбибуллинга Әлмәткә барырга, күрсәтмәләр бирергә туры килә. Әмма хәзер инде ул бер түгел, өч җинаятьтә гаепләнә. Э.Җиһаншин кулындагы пешкән һәм тешләгән җәрәхәтләр сәламәтлеккә зарар китерерлек үк түгел дип табыла, димәк, бусы власть вәкиленә карата куркыныч булмаган көч куллану дип санала. Шулай ук М.Шәрифуллинны тешләү дә зыянсыз дип белдерә, ә менә маңгайга тимер богау эләгү нәтиҗәсендә саулыкка җиңел дәрәҗәдәге зарар китерелгән дип табыла. Бусы инде ун елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган 319 нчы маддә кысаларына эләгә.

Айнып һәм акылына килеп биргән күрсәтмәләре белән танышкач, әлеге ахмаклыкларны шушы ир-ат кылуына ышанасы да килми. Барысын да эзлекле итеп сөйләп бар гаепне үзенә ала, тәүбә итүен белдерә ул.

* * *

Алексеевский районындагы Биләр урманчылыгында эшләүче ике оста, 23 сентябрьдә һөнәри бәйрәмнәрен «юганнан» соң, үзләренә олы мәшәкать чыгара. Биләр ашханәсендә сыйланып, әйтүләренчә, самогон эчеп утыра да кичкә таба таралыша алар. Шул яклардагы Большие Полянки авылында яшәүче лесник Сергей Горохов та урамга чыга һәм күп тә үтми кирәкмәгән чакта пәйда була торган өлкән участковый В.Сәйфетдиновка юлыга. Ошбу очрашу дуслык вә аңлашу шартларында бармый, чөнки полиция майоры җәмәгать урынында исерек килеш йөргән 56 яшьлек абзыйга беркетмә төзергә җыена. Моның өчен 500 дән 1500 сумга чаклы штраф, хәтта 15 тәүлеккә кадәр зинданда тоту каралган бит. Гомер бакый мондый хурлыкны күрмәгән ир-ат карыша, качып китәргә дә маташып карый, ахыр чиктә, кулларына корыч беләзекләр кидертелеп машинага утыртыла. Димәк, В.Сәйфетдинов аны район эчке эшләр бүлегенә алып китәргә тели.

Кузгалып киткәч тә, Биләрдәге «Спутник» кибете каршында тагын бер салмыш урманчы күренә. 1978 елгы Алексей Афанасьев машинаның алгы утыргычындагы хезмәттәшен шәйләп алу белән, мөхтәрәм кешене богаулаган майорга ризасызлыгын белдерә, аны азат итүне таләп итә башлый һәм, тарткалаша торгач, үзе дә «Нива»ның арткы утыргычына урнаштырыла. Башка кул богавы булмаганга, аны эләктереп куярга да мөмкинлек табылмый.

Участковый, йомшаграк итеп әйткәндә, үзләрен бик тәртипле тотмаган ике сәрхуш белән юлга чыгарга шикләнә һәм «ТАИФ-НК» АЗСы янына туктап, машинаны видеокүзәтү җайланмасы тирәсенә куя һәм район эчке эшләр бүлегеннән киләсе ярдәмне шунда көтәргә ниятли. Аның артыннан урамга А.Афанасьев та чыга һәм тәмәке кабыза, полиция хезмәткәре заправкада тартырга ярамавын әйтә, теге тыңламагач, сигаретны тартып алмакчы да була, салмыш ир-ат качып китәргә маташа. Кыскасы, вәзгыять кыза бара һәм Афанасьев полиция хезмәткәренең яңагына тамыза. Шул рәвешле, заправкада чынлап торып бәрелеш башлана, ике кеше җиргә егыла, майор В.Сәйфетдинов йөзтүбән яткан хулиганны тотып торган мәлдә С.Горохов ярдәмгә килеп җитә, куллары богаулы булганга, аякларын эшкә җигә, ягъни дусты өстендәге майорның ике мәртәбә йөзенә тибә, бу инде өстенлек тегеләр ягына күчүне белдерә. Афанасьев суга, Горохов тибә, ләкин Ф.Сәйфетдинов барыбер аягына баса. Район үзәгеннән ике хезмәткәр килеп җиткәч, йөзе-бите җимерелгән, форма киеме ертылган өлкән участок инспекторын күрәләр.

Район полициясенә китерелгәч тә, урманчыларга административ беркетмәләр төзелә. Эш моның белән генә бетми, әлбәттә. Ярый әле полиция хезмәткәренең күзләр, ирен, яңак, муен һәм башка урыннарындагы күпсанлы җәрәхәтләрнең берсе дә сәламәтлеккә зыян китермәгән булып чыга. Шуңа күрә тикшерү комитетының Чистай районара бүлегеннән Рамил Исмәгыйлев саулык өчен куркыныч тудырмаган көч куллану очрагы буенча эш кузгата, урманчылар гаепләрен таный. Җинаять эше октябрь аенда Алексеевский район судына бирелде. Власть вәкиленә карата кылынган мондый явызлык өчен 5 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган. Ләкин эш авыл кешеләрен колониягә озату белән тәгәлләнмәс кебек.

* * *

Мөслим авылында яшәүче Ленар Вәзиев Ханты-Манси округында бер ай эшләп кайту белән, үзе әйтмешли, «ял итәргә» керешә, мәсәлән, 14 февраль көнне үз гаражында бер дусты белән литр ярым көмешкә эчәләр. Ләкин моның белән генә нәфесләр басылмый, Ленар «Шкода-Октавиа» машинасында кибеткә китә.

Көндезге сәгать 3 тә урам уртасында туктап торган машина участок инспекторы Илнар Салиховта шик уята, ә полиция машинасы якынлашуын күреп алган Л.Вәзиев газ педаленә баса, ләкин аны күрше урамда туктаталар, каршына патруль «Нива»сын куялар. Исерек килеш рульдә йөргән өчен нишләр буласын яхшы белгән 45 яшьлек ир-ат бирешергә уйламый, кече лейтенант килеп баскач та, кинәт артка чигенергә керешә, ерак китә алмыйча мотор сүнү сәбәпле туктап кала, аны яңадан кабызып, бернигә тапкыр полиция машинасын урап узарга һәм качып китәргә маташа, ниһаять, «Шкода» карга бата.

Шоферның исерек икәне күренеп тора, ләкин ул документларын күрсәтергә, кем икәнен әйтергә теләми, ягъни җаваплылыктан котылырга маташуын дәвам итә, качып китмәкче дә була, бусы да барып чыкмагач, РФ Җинаять кодексы кысаларына керә торган гамәл кылып ташлый, шәхесен ачыклау өчен машинага алып барганда, кинәт кече лейтенант И.Салиховның яңагына кундыра. Шуннан соң аның кулларына богау салына.

1976 елгы Ленар Вәзиев икәне мәгълүм булгач та, исерек килеш транспорт йөртү очрагы буенча тиешле беркетмәләр төзелә. Ә Салихов сырхауханәгә барып тикшеренү уза, җәрәхәт сәламәтлеккә зыян китермәгән булып чыга. Тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Данияр Мөхәммәдиев Җинаять кодексының 318 нче маддәсе буенча кузгатылган эшне ун көн дигәндә тәгәлләп, судка озата. Ә анда Л.Вәзиев 30 мең сум штраф түләргә тиеш дигән хөкем игълан итела.

Наил ВАХИТОВ.

Данлыклы ансамбльгә – 85 яшь

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә 85 яшь тулды. Бу коллектив милли музыкабыз, биюләребезне, костюмнарны, гореф-гадәтләрне кадерләп саклый һәм югары дәрәҗәдә тамашычыларыбызга ирештерә. Ул – милли кадрлар өчен бәһасез мәктәп тә: Галия Гафиятуллина, Разия Тимерханова, Әлфия Авзалова һәм тагын күп җырчыларыбыз җыр сәнгатендә беренче адымнарын ансамбльдә башлаган. Җыр һәм бию ансамбленә бик мөһим вазыйфа – дөнья халыкларын татарның музыкасы, биюе, гореф-гадәтләре белән таныштыру йөкләнгән һәм коллектив бу авыр да, мактаулы да бурычны күп еллар югары дәрәҗәдә башкарып килә. Кышның буранлы көнендә М.Җәлил бинасында артистларыбыз юбилейны зур концерт белән билгеләп узды.

Коллективта ветераннарга хөрмәт-ихтирам зур. Юбилей кичендә дә өч буын җырчы, биючеләр җыелган иде. Ансамбль белән бер яшьтәге балетмейстер, сәнгать җитәкчесе булып хезмәт иткән Геннадий Скалозубны һәм реквизит остасы, җырчы-биючеләрне байтак еллар матур костюмнарга киендергән Евгений Бабушкинны күрү аеруча сөенечле булды. Иҗат юлын хор җырчысы булып башлаган, анары мәгърифәтчелек юлыннан китеп, коллективның җырчы, биючеләрен саллы мәкаләләре аша данлаган, ахыр чиктә моңа кадәр берәүнең дә кулыннан килмәгән эшне башкарып, 70 еллыкка китап чыгарган Филүсә Арсланның да урыны түрдән иде, билгеле. Коллективның бер гаилә кебек яшәве сөендерә. Анда иҗат гаиләләре аеруча күп. Ветераннар арасында, мәсәлән, җырчы һәм биюче Фидания һәм Равил Габдрахмановларны, җырчы һәм дирижер Йолдыз һәм Шамил Шәмгуновларны күрү матур тәэсирләр калдырды. Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитовның үзенең дә бөтен гаиләсе сәнгать хакына аямыйча хезмәт итә. Ләйсән Хәмитова талантлы биюче генә түгел, 2020 елда торгызылган балалар бию студиясендә алмаш тәрбияли. Кече кызлары Сөмбел юбилей концертта матур биюе белән сокландырды.

Тамашачылар арасында биюче Таһир Латыйфуллин күренде. Бүген ул үзе – «Сәйдәш» бию коллективы җитәкчесе, өстәвенә Мәдәният һәм сәнгать университетында кафедра җитәкчесе. Кайчандыр ансамбльдә җырлаган Фәннүр Хәсәнов «Татарстан» телевидениесе өчен юбилей концерттан репортаж әзерли, ветераннар белән сөйләшә. Шамил Әхмәтҗанов, Рәшит Мостафин, Равил Хәлиуллин, Раилә Гарипова һ.б. кебек мөхтәрәм затларны күрү рәхәт иде.

Ансамбльнең директоры Юрий Жуков 2022 елда 32 мең чакрым юл үтеп, 125 концерт башкарулары, Волгоград, Самара, Саратов, Пермь, Чиләбе, Әстерхан, Троицк белән генә чикләнмичә, Якутиягә, Ханты-Манси – Югра автономияле округына кадәр барып җитүләре, күптән түгел исә Мәскәүнең Кремль сараенда шаулатып зур концерт куюлары турында горурланып сөйләде. Татарстан Министрлар кабинетының мәдәният һәм республикабыз халыкларының телләрен үстерү идарәсе башлыгы Ләйсән Низамова ансамбльгә күп еллык нәтиҗәле хезмәте өчен мактау кәгазе тапшырды. Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин җырчы Римма Әгъзәмова һәм биючеләр Ильмир Мөхәммәтҗанов белән Артур Хәбәбетдиновка президентыбыз Указы нигезендә «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелүен җиткерде. Бериш артистларга Мәдәният министрлыгының мактау кәгазьләре, «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе тапшырылды.

Юбилей концерт өчен ансамбль балетмейстер Гай Таһировның 1965 елда куелган «Сарман биюе»н торгызган, «Салкын чишмә» татар халык җырына яңа сулыш өргән. Концертта ансамбль каршындагы балалар бию студиясендә шөгыльләнүче нәни артистлар да катнашты. Җыр һәм бию ансамбле «Созвездие-Йолдызлык» фестивале җиңүчеләре өчен «Республикабыз казанышы» махсус бүләген гамәлгә куйган иде. Аңа Мамадыштан «Лаборатория» бию коллективы һәм Биектау районыннан Адилә Зиннәтуллина лаек булды. «Голос» проекты җиңүчесе, «Евровидение» финалисты җырчы Динә Гарипова ансамбльнең хорына кушылып «Гөлҗамал» җырын башкарды. Берничә буынның шулай берләшеп юбилей үткәрүе киләчәккә зур өмет уятты.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 16.12.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2620 данә

Заказ 2783

16+